Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

*Габдулла Буби*

# ЗАМАНЕ ИҖТИҺАД МӨНКАРЫЙЗМЫ, ДӘГЕЛМЕ?

## (ИҖТИҺАД ЗАМАНЫ ҮТТЕМЕ, ЮКМЫ?)

Казан – 2022

УДК 297
ББК 86.38
Б 75

*Болгарда Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлана*

*ТР Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Гыйльми советының карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррир:**
ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы *Р.С. Хәкимов*

**Рецензентлар:**
фәлсәфә фәннәре кандидаты *А.А. Закиров,*
фәлсәфә фәннәре кандидаты *А.Г. Хәйретдинов*

**Китапны басмага әзерләүче:**
филология фәннәре кандидаты *А.М. Гайнетдинов*

Б 75 **Буби Г. Замане ижтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме? (Ижтиһад заманы үттеме, юкмы?)** / Басмага әзерләүче *А.М. Гайнетдинов*. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2022. – 152 б.

ISBN 978-5-94981-373-7

«Замане ижтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» дигән әсәр – күренекле татар дин галиме, мәгърифәтче, педагог, җәмәгать эшлеклесе Габдулла Бубиның (1871–1922) ислам динен реформалаштыру өлкәсенә караган хезмәте. Анда галимнең алдынгы фикерләре, киңкырлы карашлары, кыйммәтле киңәшләре чагылыш тапкан. Ул күтәргән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль яңгырый. Китап татар халкының дини-фәлсәфи мирасы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-373-7 УДК 297
ББК 86.38

© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2022
© Гайнетдинов А.М., 2022

## *КЕРЕШ СҮЗ*

*Габдулла Буби (Габдулла бине Габделгаллəм бине Нигъмəтулла бине Монасыйп) – мəшһүр татар дин галиме, мəгърифəтче, педагог, публицист, язучы, тəрҗемəче, җəмəгать эшлеклесе. Ул 1871 елның 9 (21) ноябрендə хəзерге Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында мулла гаилəсендə дөньяга килгəн. Төпле белемне атасының мəдрəсəсендə алганнан соң, 1895 елда Г. Буби Иж-Бубый авылына имам һəм мөдəррис итеп билгелəнгəн. Мəдрəсəдəге укыту һəм тəрбия процессы тулысынча аның кулына күчкəч, Г. Буби төпле дини һəм дөньяви белем бирүче абруйлы мəгърифəт учагы булдырган. Аңа бу эштə бертуганнары Гобəйдулла (1866–1938) һəм Мөхлисə (1869–1937) Бубилар да нык ярдəм иткəн. 1905–1906 елларда Г. Буби, Мəккə, Мəдинə, Каһирə, Бəйрут, Истанбул һ.б. шəһəрлəргə сəяхəт кылып, белемнəрен камиллəштергəн. Кызганычка каршы, кадимчелəрнең яла ягулары аркасында, 1911 елда данлыклы Иж-Бубый мəдрəсəсе ябылган, шəкертлəре куып таратылган.*

*Шуннан соң 1913 елда Г. Буби гаилəсе белəн Кытайның Голҗа шəһəренə күченеп киткəн, анда татар мəдрəсəсе оештырган. Февраль инкыйлабыннан соң Русиягə кайткач, ул Троицк шəһəрендə кызлар мəдрəсəсендə укыткан, соңыннан 1918 елның җəендə исə туган авылындагы мəктəпне торгызган. Галим 1922 елның 7 февралендə туган авылы Иж-Бубыйда вафат булган. Шундагы зиратта җирлəнеп, газиз анасы Бəдрелбəнат абыстай белəн икесенə бер кабер ташы куелган. Тексты түбəндəгечə:*

*Алгы ягы (уеп язылган):*

*1) «Лиллəəһил-фəəтихəһ*
*2) Бəдрелбəнат*
*3) Иманкол кызы*
*4) Буби*
*5) вафат 1923 нче*
*6) йылда 85 йəшендə*
*7) Аллаһ рəхмəт кыйлсун».*

*Арткы ягы (уеп язылган):*
*1) «Бу тарафда*
*2) Габдулла*
*3) Габделгалләм углы*
*4) Буби*
*5) вафат 1922 сәнә*
*6) 51 йәшендә*
*7) гафәраллааһү зүнүүбәһ»*[1].

*Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:*

*Алгы ягы: «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсен укы. Бәдрелбәнат Иманкол кызы Буби 1923 елда 85 яшендә вафат. Аллаһ рәхим кылсын».*

*Арткы ягы: «Бу тарафта Габдулла Габделгалләм улы Буби 1922 елда 51 яшендә вафат. Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».*

*Г. Буби байтак кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган: «Мөкяләмәи гарәбия» («Гарәп телендә сөйләшү»), «Фәраиз» («Мирас бүлү»), «Логия яхуд Мантыйк фәне» («Логика, яки Мантыйк фәне»), «Тәгаддеде зәүҗати хифзы сыйххәти тәтъбикъ» («Күпхатынлылыкны сәламәтлек саклауга килештерү»), «Мохтасар нәхү гарәби» («Кыскача гарәп теле синтаксисы»), «Тәзәүвеҗдә сәгадәт» («Никахлашуда бәхет»), «Тәрәкъкые фөнүн вә мәгариф динсезлеке мөҗибме?» («Фәннәрнең һәм мәгарифнең алга китүе динсезлеккә сәбәпчеме?»), «Хакыйкать, яхуд Тугрылык» («Хакыйкать, яки Дөреслек») (8 кисәктән тора), «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» («Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?»), «Татарча хөтбә уку дөресме?», «Гыйльме хәл» («Ислам гыйлеме»), «Сарф гарәби» («Гарәп теле морфологиясе»), «Бубый мәдрәсәсенең кыскача тарихы», «Зиндан», «Хатыннар» һ.б. Ләкин аның «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» дигән китабы башкаларыннан аерылып тора, чөнки анда, ул заманда гына түгел, хәтта хәзерге заманда да бик актуаль булган дини проблемалар күтәрелгән. Галимнең әлеге*

[1] Кайбер төзәтмәләр белән: Мәрданов Р.Ф. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре / Р.Ф. Мәрданов, И.Г. Һадиев. – Казан: «Тамга» нәшр., 2008. – Б. 47.

*бибәһа хезмәте 1909 елда атаклы «Милләт» типографиясендә басылып чыкканнан соң, бик күп мөселманнарның күзләре ачылуына һәм йөрәкләре фикер коллыгыннан азат ителүенә сәбәпче булган. Бу китап тулысынча иҗтиһад һәм тәкълид мәсьәләләренә багышланган.*

*Иҗтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән хөкем, нәтиҗә чыгару, ә тәкълид дин галимнәренең фикерләренә сукырларча иярүне аңлата. Ислам динендә дүрт хокукый юнәлеш яки дүрт мәзһәб барлыкка килеп, алар ныклап тамыр җәйгәннән соң, X–XI гасырларда ислам дөньясында, хәзер беркем дә үзлегеннән, турыдан-туры Коръән һәм хәдисләргә мөрәҗәгать итеп, теге яки бу дини сорауга җавап эзләргә тиеш түгел, барысы да мәзһәб галимнәре тарафыннан өйрәнелгән, шуңа күрә аларга иярү мәҗбүри, дигән караш хасил булган һәм шул рәвешле «иҗтиһад ишекләре» ябылган. Әмма байтак акыл ияләре, шул исәптән татар галимнәре, моның белән килешә алмаганнар, әлбәттә. Беренчеләрдән булып Габденнасыйр Курсави XIX йөз башында ук дини фикердә инкыйлаб ясаган: бөтен татар-ислам дөньясын тәкълид бәласеннән коткарырга ниятләгән, кәлям әһелләре булган матүридиләрнең өйрәтмәләренә каршы чыккан, «иҗтиһад ишекләре»н ачарга чакырган, халыкның акылына салынган богауларны өзәргә омтылган. Г. Курсави юлын күренекле галим Шиһабетдин Мәрҗани дәвам иткән һәм аның идеяләрен тагын да үстергән, популярлаштырган. Шиһабетдин хәзрәт үзенең хезмәтләре белән бөтен ислам галәмен диярлек тетрәндергән, уйланырга мәҗбүр иткән. Ул да халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка, схоластика һәм тәкълидтән арынырга, Коръән һәм хәдисләргә мөрәҗәгать итеп, акылы булган һәр кешене шәригать мәсьәләләрендә хөкем чыгарырга, элекке галимнәрнең ялгыш фикерләреннән арынырга, мөстәкыйль рәвештә фикер йөртергә өндәгән. Шулай ук Ризаэтдин Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Зыяэтдин Камали, Муса Бигиев кебек башка дин галимнәребез үзләренең хезмәтләрендә иҗтиһад һәм тәкълид*

*проблемасын шул рухта яктыртканнар. Гомумән, җәдидчеләрнең күпчелеге мәзһәбләрне кире каккан*[2].

*Г. Буби да «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәтендә бу мәсьәләләрне энәсеннән җебенә кадәр җентекләп аңлаткан, үзенең сүзләрен куәтләү өчен бик күп дәлилләр китергән һәм бернинди шик-шөбһәләргә урын калдырмаган. Аны язганда, автор түбәндәге төп чыганакларны кулланган: Коръән, хәдисләр, мәшһүр гарәп галиме Ибне Каййим әл-Җәүзиянең (1292–1350) «Игъләм әл-мөвәкъкыйгыйнә ган Рабби әл-галәмин» («Галәмнәрнең Раббысы исеменнән имза куючыларга белдерү») китабы, гарәп дин һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Рашид Риданың (1865–1935) «Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе» хезмәте. Ни өчендер 1909 елгы басмада Ибне Каййим китабының исеме «Игъләм әл-мөвәффәкыйн» дип бирелгән*[3]*, бу – типография хатасы булса кирәк. Шулай ук Г. Буби Шатыйбиның «Мүвәфәкать» («Муафыйклыклар»), Тафтазаниның «Хашия-и Гадудия» («Гадуди хашиясе»), Мәргыйнаниның «Әл-Һидая» («Туры юл»), Мәхбубиның «Мохтасар әл-Викая» («“Саклау” хезмәтенең кыскача аңлатмасы»), Хәләбинең «Мөлтәка әл-әбхүр» («Диңгезләр кушылуы»), Шәехзадәнең «Мәҗмәгъ әл-әнһәр» («Елгалар җыелмасы»), Ибне Һөмамның «Фәтх әл-Кадыйр» («Кодрәтле Аллаһның [хакыйкатьне] ачуы») хезмәтләренә дә мөрәҗәгать иткән.*

*Кайбер тарихчылар, «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәтен Г. Буби үзе язмаган, фәкать мәшһүр гарәп галиме Ибне Каййимнең «Игъләм әл-мөвәкъкыйгыйн» («Имза куючыларга белдерү») исемле китабын татарчага тәрҗемә иткән, дип ялгышалар. Бу сүзләре белән алар әлеге китап белән тулысынча танышып чыкмаганнарын, аны игътибар белән укымаганнарын күрсәтәләр. Чынлыкта исә, әлеге олуг хезмәтнең өчтән бере – Г. Бубиның үз сүзләре, үз иҗат җимеше. 69 битле*

---

[2] Хакимов Р.С. Традиционный ислам у татар / Р.С. Хакимов. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 28.

[3] Буби Г. Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме? / Г. Буби. – Казан: «Милләт» электро-типографиясе, 1909. – Б. 23, 63.

*китапның 23 нче битендә ул болай дип язган: «Шул ук вакытта, бу тарихтан бик күп соң, ягъни һиҗрәттән 751 елда вафат булган Ибне Каййим, шәригать дәвам ителгән кебек, иҗтиһадның дәвам ителүен сөйләгән һәм тик бу турыда «Игъләм әл-мөвәкъкыйгыйн» исемле бер китап язган. Менә минем бу дәрәҗә-максатым шул китапны тәрҗемә итеп, милләт улларыма күрсәтү һәм, иҗтиһад бетте, дигән заманнан соңгы галимнәр һәм бөек адәмнәр ни сөйләгәннәр – шуны мәйданга кую. Хәтта иҗтиһад заманы бетмәде, дигән сүз яңа сүз түгел, бәлки иске сүз икәнлек билгеле булсын! Менә минем максатым – бу. Әгәр тәкълиднең ислам һәм мөселманнар башына китергән бәлаләре минем йөрәгемне бу кадәр яндырып куырмаса, мин туп-туры бу китапның тәрҗемәсенә керешер һәм төрле китаплардан хәтеремдә калган бу озын кереш өлешне язып маташмас идем. Менә шул хәсрәтләр, менә шул ачы хакыйкатьләр минем каләмемне бу сүзләрне язарга мәҗбүр итте. Инде максатка килим дә Ибне Каййимнең сүзләрен тәрҗемә итүгә тотыныйм». Димәк, хезмәтнең 23 битендә Г. Бубиның үз фикерләре, уйланулары урын алган, 23 нче биттән алып 62 нче биткә хәтле өлешендә исә Ибне Каййимнең «Игъләм әл-мөвәкъкыйгыйн» әсәренең кыскача тәрҗемәсе бирелгән. 62 нче биттән 69 нчы биткә кадәр тагын Г. Буби сүзләре һәм «Әл-мәнар» («Маяк») журналында басылган Сәед Мөхәммәд Рашиднең «Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе» исемле китабының кыскача тәрҗемәсе китерелгән. Шулай итеп, «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәтен Г. Бубиныкы итеп санарга тулы нигез бар, Ибне Каййим китабыннан өзекләрне ул фәкать үзенең фикерен куәтләү өчен генә тәрҗемә иткәнлеге аның түбәндәге сүзләреннән аңлашыла: «Әгәр: «Иҗтиһад заманы үтмәде һәм билгеле бер имамның сүзенә тәкълид тиешле түгел», – дип әйтү сез [әйткән] кебек, көферлек һәм адашу булса, бездән элек кяфер, бездән элек азгын Ибне Каййим һәм дүрт имам үзләре булырга тиешле иде, азрак инсафлык кылыгыз!»*

*«Иҗтиһад заманы уздымы яки юкмы?» дигән мәгънәсез сорауга җавап бирүне хурлык дип санаса да, Г. Буби, үз халкына хакыйкатьне ачу һәм күрсәтү өчен, бу эшкә алынган. Аның фикеренчә, ислам диненең асылы – акыл һәм фикер, тәкълид исә акылга мөрәҗәгать итүне тыя, шул рәвешле, ислам бинасын җимерә, шәригатьне нигезеннән чыгара. Г. Буби, иманның максаты – хайванны бәйләгән кебек, кешене бер мәзһәбкә бәйләп кую түгел, бәлки кешеләрнең акылларын гыйлем һәм мәгърифәт дәрәҗәләреннән югары менгерү, дип санаган. Тәкълидкә ябышучыларны Г. Буби сарык көтүе белән чагыштырган. Көтүче бер сүз яисә тавыш бирсә – куйлар килә, башка бер аваз бирсә – китәләр, әмма моның килү-китү сәбәпләрен белмиләр; шуның кебек, мөкаллидләр дә, фәкыйһләренең сүзләренә сукырларча ияреп, һичбер нәрсә аңламыйча, диннәрен тоталар. Г. Буби юкка гына мондый чагыштыру китермәгән, чөнки Коръәннең «Бәкарә» сүрәсенең 171 нче аятендә хак сүзне аңларга теләмәүче кешеләр хайванга тиңләнә. «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» китабының ахыргы өлешендә автор: «Димәк, хайванлыктан һәм тәкълид дәрәҗә-сеннән чыгып, кешелек һәм мәдәният дәрәҗәсенә җитү өчен, әлбәттә, акыл һәм фикерне файдаланырга кирәк», – дигән нәтиҗә чыгарган.*

*Г. Буби тәкълиднең алга киткән башка милләтләрне ислам диненә чакыруда киртә булуын ассызыклаган. Әгәр дә аларга «Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафыннан төзелеп беткән, Коръән белән хәдисне аңлау вакыты узган-лыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән хәдискә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм зама-ныгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз» дип әйтсәк, әлбәттә, ул милләт вәкилләренең исламны кабул итүдән баш тартачаклары көн кебек ачык, чөнки, Г. Буби язганча, алар үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш ияргә риза булмаячаклар. Әгәр динне мондый тар кысалар эчендә күрсәтсәк, ул вакытта чит милләтләрне исламга кызыктыру түгел, үз арабызда булган*

*мәгърифәтле кешеләр дә исламнан бизәчәкләр, дип санаган ул. Шуңа күрә галим бер генә юл күргән, ул – исламны тикшереп, аны пәйгамбәр заманындагы гадилегенә кайтару һәм һәркемгә үз акылынча аңларга рөхсәт бирү. Дөрес, бу вакытта Г. Буби төрле каршылыкларның күбәюен таныган, ләкин, аның каравы, мөселманнар арасында низаглар бетәчәк, чөнки сәхабәләр һәм табигыйннар заманында каршылыклар һичбер фанатизмсыз булган.*

*Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин һ.б. татар галимнәре язып калдырганча, дүрт мәзһәбкә нигез салучылар үзләренә тәкълид кылудан катгый рәвештә тыйганнар. Г. Буби да «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәтендә бу турыда хөрмәтле имамнар Әбү Хәнифә, Шафигый, Мәлик һәм Әхмәднең сүзләрен китергән. Автор мәзһәбләргә ияручеләрнең күплеге һәм электән үк булганлыгы белән алданмаска чакыра, чөнки, аның фикеренчә, дөреслек борынгылыкта һәм күплектә түгел.*

*Кайбер галимнәр иҗтиһад кылырга лаек булу өчен төрле шартлар куялар, мәсәлән, Коръәнне, меңләгән хәдисләрне, гарәп телен һ.б. камил дәрәҗәдә белү. Ләкин Г. Буби, имам Шатыйбига таянып, моның өчен гарәп гыйлемнәренең текстын һәм стилен аңлап, шәригать максатларын белү җитә, ди. Иҗтиһад кылыр өчен бөтен шәригать хөкемнәрен белүче мөҗтәһид булу шарт түгел икәнлеге хакыда Мәрҗани дә язган. Мәсәлән, галим Т. Ильяс аның «Назурател-хак» китабыннан «Бер адәмнең барлык шәригать хөкемнәрен чыгаруга көче җитмәсә дә, Коръән һәм пәйгамбәрнең хәдисләрен тикшереп, кайбер хөкемнәрне чыгаруы ярый»[4], «Ягъни кайсы заманда гына булмасын, Кыямәт көненә кадәр һәрбер мөэмингә Коръән һәм пәйгамбәрнең хәдисе белән тотыну һәм иҗтиһад юлында булырга тиешле»[5] дигән фикерләрен китергән. Г. Буби да иҗтиһад дигәндә, ниндидер авыр мәсьәләләрдә хөкем чыгаруны, катлаулы сорауларга җавап эзләүне түгел, ә гади дини мәрасимнәрне үтәр*

[4] Ильяс Т. Фикыһ даирәсендәге хезмәтләре / Т. Ильяс // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 283.

[5] Шунда ук . – Б. 284.

*алдыннан, бу эшләргә Коръәннән яки хәдисләрдән дәлил эзләүне күздә тоткан. Фәлән имам шулай әйткән, төгән мулла болай әйткән, дип кенә аларның коры сүзләренә иярмичә, гыйбадәт белән бәйле булган һәр гамәлгә үзлегеңнән Коръән һәм хәдисләрдән дәлил эзләү, Г. Буби фикеренчә, үзенә күрә иҗтиһад була. Шул рәвешле, кайсы галимнең сүзләре Коръән-Сөннәткә якынрак – ул шуны алырга куша. Г. Буби язганча, дини хөкемнәрне караган һәрбер акыл иясе шәригать дәлилләреннән үзе нәтиҗә чыгарырга тиеш, әгәр ул дөреслеккә ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы була. Әлеге сүзләрне галим атаклы бер хәдискә нигезләнеп әйткән. Шулай ук ул, кешенең, хөррият һәм ихтыяр хикмәтләрен саклап, хөкем чыгару белән шөгыльләнүе үз-үзен хаталы булу мөмкинлеге белән әсир итүдән хәерлерәк һәм иҗтиһадның киләчәге тәкълиднең киләчәгеннән иминрәк, дип санаган.*

*XIX гасырда татарлар арасында бу тәкълид шулкадәр тамыр җәйгән булган ки, әгәр бер кеше теге яки бу дини мәсьәләдә Корән һәм хәдисләрдән җавап эзләргә чакырса, аны фанатик муллалар хаксыз рәвештә имансызлыкта гаепләгәннәр, хәтта олуг галимнәребез Г. Курсави һәм Ш. Мәрҗанигә дә кадимчеләр тарафыннан «кяфер мөһере» сугылган. Әгәр дә ислам тарихына күз салсак, нәкъ менә толерантлык җитмәү аркасында, мөселманнар арасында тарткалашулар һәм сугышлар чыккан, фетнәләр кубарылган, һәркем үз мәсләген таратырга һәм башкаларныкын юк итәргә керешкән, кешеләргә бик күп зарар һәм хәсрәт килгән. Ислам өммәте, исламның башлангыч чорында бик нык алга китсә дә, соңыннан тәкълид аркасында түбәнлеккә төшкән, ләкин Г. Буби ышанган ки, бер вакыт килер, тәкълид камыты мөселманнар муеныннан салыныр, алар Коръән кушкан саф иҗтиһад һәм дөрес фикерләү юлына басарлар, шул вакытта мөселманнарга рәхәт көннәр җитәр.*

*Г. Буби язганча, Европа халкы, тиз арада уянып, тәкълид караңгылыгыннан чыгып, иҗтиһадка, фикерләүгә тотынган һәм шул рәвешле гыйлем-мәгърифәт ягыннан югары дәрәҗә-*

*ләргә ирешкән. Шул ук вакытта, ул, аларның һәр яктан үсеш кичерүе белән алданып, Европага иярүдән дә тыйган. Моны Г. Буби, бер тәкълидне ташлап, икенче тәкълидкә керү, дип санаган. Галим М. Бигиев та 1913 елда бу турыда җентекләп язган һәм бу күренешне ул яңа тәкълид дип атаган*[6]*. Гомумән, Г. Буби әйткән фикерләрне шул заманда яшәгән башка татар галимнәре дә кабул иткәннәр һәм, үзләренең китапларында тагын да ныграк үстереп, халыкка тәкъдим иткәннәр.*

*Һәр милләттәшебез «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәте белән танышып чыгу бәхетенә ия түгел, чөнки, беренчедән, ул гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган рәвештә язылган. Шуңа күрә аны кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен, барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып эшләргә булдык, ягъни мөмкин кадәр хәзерге гамәлдәге телгә якынайттык. Гарәп телендәге җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде, аңлашылмаган сүзләргә яки терминнарга астөшермәләрдә аңлатма бирелде.*

[6] Бигиев М.Д. Избранные труды / Муса Джаруллах Бигиев; сост. и пер. с осман. яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – С. 336.

# БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

Кешеләрнең акыллары көннән-көн үсеш тапкан һәм бу үсешнең әсәрләре дә иң надан һәм иң ахмак адәмнәрнең дә күзләрен камаштырыр дәрәҗәдә күренеп торган бер заманда бу сорауны бирү һәм «Коръәнне аңлау фәкать элекке кешеләргә махсус, алар беттеләр, Кыямәт заманына кадәр [Аллаһ] мондый адәмнәрне яңадан тудырмас» дип әйтү никадәр түбәнлек булса, аңа җавап бирү максаты белән алтыннан кыйммәтле гомерне әрәм итү дә, хакыйкаттә, шулкадәр ахмаклык. Ләкин эшнең ни вакытта хакыйкать көенчә торганы бар? Әгәр хакыйкать төрле хыяллар арасына кереп югалмаса, гыйлем исеменнән бу кадәр фикерләр язылмас һәм без дә бу китап карауны мәҗбүри күрмәс идек. Асылы акыл белән фикердән гыйбарәт булган һәм һәрбер хөкемендә акыл белән фикергә мөрәҗәгать иткән исламны иҗтиһад[7] хөрриятеннән тәкълид[8] боендырыгына [камытына] атарлар һәм Китап [Коръән] белән Сөннәт[9] бөтенләй җимерелеп, болар урынына фәлән-фәләннең сүзе торыр, дип кемнең хәтеренә [башына] килер? Әгәр эш хәтергә килер дәрәҗәсендә генә калса, ул вакытта бер дә кайгырмас [идек], мөселманнар башына бу бәлаләр дә килмәс [иде], сабыйлар аталарының хәтта аракы эчүгә кадәр һәрбер кабәхәт эшләрен күркәм санаганнары кебек, безнең дә соңгыларыбыз элекке [кешеләрнең] максат һәм уйларын бер дә аңламыйча, һәрбер эшләгәннәрен, хәтта һәлакәткә китерә торган хөкемнәрен дә күркәм санап, тәкълид [кылырга] һәм иярергә тырышмаслар иде. Ләкин, бик зур кызганычка каршы, эш ул дәрәҗәдә генә калмаган. Бәлки мөкаллидлек[10] бәласе дәһшәтле сортта мәйданга чыккан, ислам бинасын җимергән, изге

---

[7] Иҗтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән хөкем, нәтиҗә чыгару.

[8] Тәкълид – дин галимнәренең фикерләренә, дини мәзһәбләргә сукырларча иярү.

[9] Сөннәт – Мөхәммәд пәйгамбәрнең өйрәтмәләре, гамәлләре һәм сүзләре (хәдисләре).

[10] Мөкаллидлек – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярү.

шәригатьне нигезеннән чыгарган һәм бу мөкаллидләрнең[11] золым камчылары астында ислам нуры бөтенләй сүнүгә якынлашкан. Соңгы фәкыйһләрнең[12], Коръәндә юк [булмаган] хәез-нифас[13] хөкемнәренә караган йөзләрчә сәхифә язган хәлдә, Коръәннең эче тулы кирәкле хөкемнәргә карамауларына сәбәп тә – менә бу тәкълид. Болар фикыһ[14] хөкемнәренә сарыф иткән заманнарының [вакытларының] уннан берен Коръән Кәримнең бик күп җирдә әмер иткән кирәкле хөкемнәрен карауга сарыф итсәләр, бәлки мөселманнар бу кадәр наданлык һәм ахмаклыкка төшмәсләр иде. Әгәр болар, [һиҗри белән] беренче гасыр мөҗтәһидләре[15] кебек, фәкать хаклыкка ирешүне таләп итсәләр [эзләсәләр], билгеле [булган] бу адашуда һәм көферлектә гаепләүләр, нәфрәт-ләгънәтләрнең һичберсе булмас иде. Аллаһның рәхмәтен шайтан гына кызгана. Сезгә Аллаһның җәннәте тар булган кебек тоела, мине, кыйбла әһеленнән булган кардәшегезне, тик сезгә яисә элекке [замандагы] бер кешегә бер фикердә каршы булган өчен, адашуда һәм көферлектә гаепләргә тотынасыз? Хөрмәтле сәхабәләр[16] һәм бөек имамнар[17] иҗтиһадта бер-берсе белән каршы фикердә булырлар иде, ләкин һичберсе башка берәүне адашуда һәм көферлектә гаепләмәс, аны дошман санамас иде. Шуның өчен Әбү Хәнифә[18] белән Шафигый[19] арасындагы фикер каршылыкларына караганда Әбү Хәнифә

[11] Мөкаллид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярүче.

[12] Фәкыйһ – ислам хокукы һәм шәригать мәсьәләләре белгече.

[13] Хәез-нифас – күрем һәм бала тапканнан соң кан килү вакыты.

[14] Фикыһ – ислам хокукы.

[15] Мөҗтәһид – үз тырышлыгы белән ислам чыганакларыннан хөкем һәм нәтиҗәләр чыгаручы галим.

[16] Сәхабә – Мөхәммәд пәйгамбәрне күргән мөселман кеше.

[17] Бу китапта «имам» сүзе кулланылганда, элекке замандагы мәшһүр дин галимнәре күздә тотыла.

[18] Ногман Әбү Хәнифә бине Сабит әл-Куфи (699–767) – бөек дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, хәнәфи мәзһәбенә нигез салучы.

[19] Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Идрис әш-Шафигый (767–820) – бөек дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, шафигый мәзһәбенә нигез салучы.

белән ике шәкерте – Әбү Йосыф[20] һәм Мөхәммәд[21] – арасындагы каршылыклар күбрәк [булган], дигәннәр.

Менә боларның каршылыклары фикер хөррияте һәм сүз хөррияте мәгънәсендә булганлыктан, Мөхәммәд (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) өммәтенә рәхмәт иде. Әмма соңра бер заман килде, Аллаһ Тәгаләнең Коръән Кәримдә яһүд һәм нәсараларны гаепләгән урынында: **«Алар, Аллаһны ташлап, үзләренең галимнәрен һәм заһидләрен Раббы итеп алдылар»** [Коръән, 9:31] дигән сүзенә карышып, шәригать дәлилләрен куеп, элекке кешеләрнең сүзенә дәлилсез тәкълид кылына башлануы, һәрбер фирка бер имамны ияртүче [итеп] тотып, мәзһәбтә[22] фанатизм куәтләнде. Һәрбер төркем үз мәзһәбенә каршы фикердә булган башка төркемгә дошманлык кыла башлады. Һичбер төркем башкасының дәлилен белмәс һәм хаклыкка ирешүне теләмәс бер хәлгә төште. Һәрбер фирка башкасын сүгеп һәм хур итеп, үз фикердәшләрен күбәйтү исәбенә керде, бер-береңне күралмау күбәйде, ызгыш-талаш артты. Һичберсенең максаты хаклыкка ирешү һәм ялганнан котылу түгел, бәлки каршы фикердә булган көндәшне җиңү һәм кеше арасында галим исемен чыгару иде. Димәк, фикердәге бу каршылыклар ислам милләтенә кая рәхмәт, киресенчә, ләгънәт булып китте. Гүя Аллаһ Тәгаләнең: **«Кешеләрнең ислам динен үзгәртеп бозулары Аллаһтан аларга китап иңмәгәннән һәм рәсүл килмәгәннән түгел, бәлки китап иңдерелеп, рәсүл күндерелеп, ислам дине тулысынча ачык итеп аңлатылганнан соң инсафсыз галимнәр бер-берсенә хөсетләнеп, дошманлашып, Аллаһ хөкемнәренә хилафлык кылдылар, ислам динен бозып бетерделәр»** [Коръән, 3:19], – дигән сүзе болар хакында иңде. Аллаһ Тәгалә һәрбер урында акылга мөрәҗәгать иткәнлектән, исламча мөстәкыйль фикер һәм тәклид

---

[20] Ягъкуб Әбү Йосыф бине Ибраһим әл-Куфи (731–798) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, казый.

[21] Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Хәсән эш-Шәйбани (749–805) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, казый.

[22] Мәзһәб – мөселман хокук системасына нигезләнгән юнәлеш.

белән ислам капма-каршы куелган иде. Әгәр эш шул хәленчә барса, акыллар куәтләнер, хаклык ялганнан аерылыр һәм тәкълидтән дә качу булыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, эш шул хәленчә бармады. Коръән-Кәрим «Китап әһелләре[23] китапларын үзгәрттеләр, куйдылар һәм, дин исемендәге кешеләрнең сүзләренә сукырларча тәкълид кылып, хәрамны хәләл, хәләлне хәрам иттеләр» дип әйтә торып, безнең дә соңгы дин исемендә булган кешеләребез, үз шәехләренең сүзләренә сукырларча тәкълид кылдылар. Боларның: «Имамнар сүзләренә тәкълид важиб[24] һәм аларның фәтваләрен шәригать текстларына тәкъдим итү тиешле», – дигән сүзләре белән гамәл кылдылар. Шул ук вакытта, үзләре башка тарафтан имамнар сүзләренә каршы булса да, бу шәехләрнең сүзләренә тәкълид кылалар һәм әйтәләр ки: «Болар безгә караганда Аллаһ сүзен һәм имамнар сүзләрен белүчерәк, шуның өчен болар сүзенең Аллаһ сүзе һәм имамнар сүзләренә каршы төсле күренүе безнең үз акылларыбызның җитешсезлегеннән». Менә шулай һәрбер фирканың иярүе: фәкать шәехләре дөрес күргән хөкемнәрдә генә имамнарына тәкълид кылдылар, иҗмаг[25] буенча ялган булган мөкаллидкә[26] тәкълидне ихтыяр кылдылар һәм Аллаһ Тәгалә **«Аллаһ сезгә тарлыкны теләми»** [Коръән, 5:6], **«Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми»** [Коръән, 2:185] дип әйтә торып, ислам шәригатен теләгән кадәр тарайттылар, иҗтиһад хакында бик күп мөшкел мәсьәлә турында Аллаһ китабы һәм Рәсүл[27] сөннәтендә табылачак киң ишекләрне караңгы тәкълид пәрдәсе белән капладылар. Болар һичбер акыл йөртмәгәнлектән һәм һәрбер дәлилне наданлыклары белән кабул иткәнлектән, алар белән сөйләшергә дә мөмкин түгел, бәлки аларны тотып, туп-туры сырхауханәгә җибәрергә [кирәк]. Чөнки болардан, мөселманнар башына килгән зарар, файдаларына кара-

[23] Китап әһелләре – христианнар һәм яһүдиләр.
[24] Важиб – мәҗбүри.
[25] Иҗмаг – ислам галимнәренең бердәм фикерләре һәм карашлары.
[26] Мөкаллид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярүче.
[27] Рәсүл – Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе булсын).

ганда, берничә мәртәбә күбрәк. Фәкать боларның залим солтан һәм әмирләргә файдалары тигән.

Чөнки залимнәр һәрвакыт наданлыктан файдаланырлар һәм болганчык суда балык тотарга теләрләр. Залимнәрнең дөньяда иң курыккан нәрсәләре – гыйлем һәм мәгърифәт. Тәкълид кебек гыйлем һәм мәгърифәтне юк иткән башка һичбер нәрсә юк. Халыкны тунар һәм теләгән золымны йөртү өчен иң беренче юл – ижтиһад һәм хөррият фикерне бетерү. Шуның өчен дә залимнәр: «Ижтиһад заманы үтте», – дигән фәтване үз заманнарындагы галимнәрдән я куркытып, я сатып алганнар.

Бүген бу тәкълид бәласе шулкадәр гомумиләшкән һәм шулкадәр тамыр җәйгәндер ки, әгәр бер адәм Коръән белән Сөннәткә кайтуга чакырдымы, аннан нәфрәтләнәләр, качалар һәм төрле көферлекләр белән гаеплиләр. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә: «Сез: “Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягькуб һәм башка пәйгамбәрләр яһүд динендә яки насара динендә иделәр”, – дип әйтерсезмени», – дип аңлаткан ки, хөрмәтле пәйгамбәрләрнең һичберсе тәкълид боендырыгына кермәгәннәр, бәлки тик дәлилдән аңлашылган хаклыкка ияргәннәр. Тәкълид, ияру һәм бер кешедән ишеткән яисә бер китапта күргән нәрсәләрне фонограф[28] кебек сөйләп тору – һәммәсе пәйгамбәрләрдән (галәйһимис-сәлам) соң барлыкка килгән бидгатьләр[29]. Менә әфәндебез [Мөхәммәд] саллалаһү галәйһи вә сәлләм шул бидгатьләрне бетереп, дәлилләргә кайтару өчен торгызылган һәм: **«Шул вакытта ияртүчеләр үзләре ияргән кешеләрдән бизәрләр һәм ерак булырлар»** [Коръән: 2:166], – дип дәлилсез ияручеләр гаепләнәләр һәм хурланалар. Аллаһ Тәгалә **«Шайтан өндәгән ялган юлларга иярмәгез. Дөреслектә, ул шайтан – сезнең өчен ачык булган дошман. Шайтан сезгә явыз, гөнаһ эш белән, шәригатьтә һәм акыл буенча кабәхәт булган эшне кылырга өндәр. Шулай ук шайтан сезгә Аллаһ Тәгалә**

[28] Оригинал басмада ялгыш «фотограф» дип язылган.

[29] Бидгать – догмат һәм гыйбадәт мәсьәләләрендә Коръән һәм пәйгамбәр өйрәтүләренә туры килмәгән фикерләр, гамәлләр, йолалар һәм сүзләр.

**хозурына сез белмәгән нәрсәгезне, ягъни потларга табыну, хәләл ризыкларны һәм киемнәрне хәрам дип әйтергә боерыр»** [Коръән: 2:168–169] дип дәлилсез, гыйлемсез сөйләгән адәмнәрне, ягъни мөкаллидләрне шайтанга иярүчеләр дип гаепли торып, ахыргы буыннарның Коръән-хәдистән баш тартулары һәм, бер мәзһәбкә керделәрме, каршыларына тау кебек дәлилләр китерелсә дә, фикерләрендә һаман нык торулары – бик каты гаҗәпләндерә торган хәл. Болар, тулы ахмаклыкларыннан, тәкълид белән динне саклыйбыз, дип уйлыйлар. Шул ук вакытта, әгәр тәкълид белән һәм Аллаһ белән кол арасында арадашчы ясап, аять-хәдисләрдән баш тартулары һәм колларның йөрәкләрен ул Рәхимлеләрнең рәхимлесеннән [Аллаһтан] суыту белән динне саклау хасил булса, Аллаһ Тәгалә **«Һәркайчан аларга: “Аллаһы Тәгалә иңдергән нәрсәгә иярегез”, – дип әйтелсә, мөшрикләр әйтерләр: “Аллаһы Тәгалә иңдергән нәрсәгә иярмибез, бәлки аталарыбыз нәрсәгә гыйбадәт кылдылар – без дә шул нәрсәләргә гыйбадәт кылабыз”»** [Коръән: 2:170] дип тәкълиднең ялганын һәм тәкълид юлының бозыклыгын сөйләмәс һәм моннан соң **«Аталары дин эшеннән бернәрсәне белмәсәләр дә, туры юлда булмасалар да, аларга иярерләрме?»** [Коръән: 2:170] дигән сүзләрне аңламаган һәм дәлилләргә карамаган адәмнәрне хайван урынына иңдермәс иде. Әгәр мөкаллидләрнең аңлый торган йөрәкләре булса, менә бу аять берүзе дә тәкълидтән, иске гадәтләрне изге санаудан нәфрәтләндерүдә һәм Аллаһ китабы белән Рәсүл сөннәтеннән баш тартуның хәрам икәнлеген күрсәтүдә җитә.

Бу аять аңлатадыр ки, боларның тәкълид кылган затлары, хаклыкка ирешү өчен һичбер дәлилгә карамаганлыктан, һәммәсе хатада. Хаклыкны белү өчен дәлилгә карый торган кешенең, бервакыт хатага төшсә дә, икенче вакыт тагын фикерләп, дөреслеккә кайту ихтималы бик якын. Шуның өчен акыллы адәмнең һәрберсе, ялган гозерләр күрсәтеп, Аллаһ иңдергән нәрсәләрне ташлап, башка бер кешегә, акылы никадәр камил булса да, тәкълидне, сукырларча иярүне дөрес күрмәс һәм бик ачык белер ки, кеше никадәр акыллы һәм никадәр үз-үзен тотышы яхшы

булса да, бервакыт фикерендә хата кылмыйча калмас. Шуның өчен [нәрсә дә булса] сөйләүчегә рухсыз тәкълид кылырга түгел, бәлки дәлилгә карап сүзенә ияреpгә тиешле.

«Нәрсә сөйләгәннәренә кара, кем сөйләгәненә карама». Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә хөрмәтле китабында: **«Шундый колларыма сөенеч бир, ул колларым сүзне ишетерләр дә, ул сүзнең күркәмрәгенә иярерләр, бу сыйфаттагы коллар – Аллаһның хаклыкка күндергән коллары. Шулай ук бу сыйфаттагы коллар – саф акыл ияләре»** [Коръән: 39:17–18], – дигән. Шуның өчен дә имам Газали, тәкълидтән чыгып, һәрбер мәзһәбнең дәлиленә карап сүз алуны мөкаллидләрнең тәлфыйк[30] дип әйтүләренә каршы, «Мәнкад минәд-даләл» исемле китабында тәкълид түбәнчелегеннән тикшерү урынына менүен бик шатланып, рәхмәт белдереп язган. Дөрес, бик мәгълүм мөкаллидләр тәлфыйкны хәрам диләр. Ләкин аның хөрмәтенә нинди дәлил бар? Әгәр бер кеше дәгъва кылса, рәхим итсен! Безгә күрсәтеп карасын. Боларның һичбер дәлилләре юк, фәкать болар Аллаһ Тәгаләнең **«Яһүдләрдән Тәүратны белмәүчеләр дә бар. Алар ата-бабадан калган ялган хорафат сүзләрне генә беләләр. Алар хакны белмиләр, мәгәр ялган, ясалма динне хак дин дип төшенәләр һәм шул сукыр төшенүләре белән эш кылалар»** [Коръән: 2:78] дигән адәмнәр кебек. Китап әһелләренең галимнәре дә китапларын үзгәрттеләр, төрле ялгыш аңлатулар белән Аллаһ хөкемнәреннән чыктылар. Үз хыялларын барлыкка китереп, шуны китаплары каршысында игътибар иттеләр. Туры юл вакытындагы элекке изге буын кешеләре белән мактандылар һәм шуны үз бәхетләренә җитә, дип уйладылар. Шул сәбәпле, аларның диннәре нигезеннән чыкты, бозылып бетте. Без менә бу хәбәрләрне укыйбыз, аларны мыскыл итеп көләбез, бик гаҗәпләнәбез. Әмма үзебезнең аларга тәмам ияргәнебезне һәм әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең: **«Сез һичшиксез үзегезгә хәтле яшәгәннәрнең гадәтләренә хәтта һәр карыш, һәр терсәк буе кадәр ияреячәксез»** дигән сүзенә дәлил

[30] Тәлфыйк – төрле мәзһәбтәге карашларны бергә кушу, җыю, куллану.

булуыбызны бер дә сизмибез. Бу аятьләрнең ялган тәкълидкә дәлиллекләрен, әүвәлгеләр йөрәгенең шуңа туплануын, ул вакытта наданнан, галимнән ышануны фәкать дәлил белән хөкемнәрне тик риваять белән алуларын һәм, дәлилсез диелсә, ничек [аңа] һич тәкълид кылмаганнарын бер дә акылыбызга китермибез. Дөрес, шәригать туры юлда булучы акыл иясенә иярүдән тыймыйдыр, ләкин үз артыннан ияртүченең дәлилен белмичә торып, аның туры юлда булучы акыл иясе икәнен каян белергә кирәк? Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә югарыдагы аятьләрдә ата-бабаларына дәлилсез иягән адәмнәрне гаепләгәннән һәм хурлаганнан соң: **«Коръәнгә ышанмаучы яки аның хөкемнәрен тотмаучы кяферләрнең мисалы: бер кеше тарафыннан кычкырып чакырылган хайван кебек. Ул хайван тавышны ишетеп, чакыруны белсә дә, башка сүзнең мәгънәсен белми. Шул хайван сыман кешеләр хак сүзне ишетүдән саңгыраулар, хак сүзне сөйләүдән телсезләр һәм гыйбрәтләрне күрүдән сукырлар – шуның өчен Коръәнне һич аңламаслар»** [Коръән: 2:171], – дип, бу чагыштыруны китергән.

Ягъни бу мөкаллидләрнең хәле куй белән көтүче хәле кебек. Көтүче бер сүз, бер тавыш бирсә – куйлар килгән, башка бер аваз белән [бирсә] – киткән һәм бу тавышлардан һичбер нәрсә аңламаган, килү-китү сәбәпләрен һич белмәгән кебек, дәлилсез бер ышануны таныган һәм аңлатмасыз бер фикыйһны кабул иткән адәмнәр дә килү-китүдән [башка] бернәрсә дә аңламаслар. Бу аять бик ачык күрсәтә ки, акылсыз тәкълид – кяферләр эше; динне дәлил белән белмәгән, бәлки коры тану белән кабул итеп алган адәм бу аять буенча мөэмин түгел. Иманның максаты – хайванны бәйләгән кебек, адәмне бер багана, бер мәзһәбкә бәйләп куюю түгел, бәлки кешеләрнең акылларын гыйлем һәм мәгърифәт дәрәҗәләреннән югары менгезү. Димәк, менә бу адәм хәерлекне – хәерлек дип белеп эшләр һәм начарлыкны – начарлык дип, начар тәмамлануын белеп, кире кагар.

Димәк, бу вакытта безгә алга киткән милләтләрне исламга чакыру да мөмкин булыр. Әгәр без бүген алга киткән милләтләргә: «Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафын-

нан төзелеп беткән, Коръән белән хәдисне аңлау вакыты узганлыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән хәдискә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм заманыгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз! Менә сезнең мөселманлыгыгыз шушында һәм адашуыгыз моның капма-каршысында», – дип әйтсәк, боларның исламга мәхәббәтләре төшәрме? Болар үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш ияргә һәм үзләрен ахмак һәм юләр дияргә риза булырлармы? Боларны Күһистаниларга[31], Вәлвәлиҗиләргә[32] ничек ышандыру кирәк? Юк, болар элекке фәкыйһләр сүзе белән түгел, бәлки акылга сыешлы юл белән йөриячәкләр. Әгәр динебезне, тәкълид ияләре уйлаган кебек, болай тар бер рам эчендә күрсәтсәк, ул вакытта кая алга киткән чит милләтләрне үзебезгә, исламга якынлаштыру; киресенчә, үз арабыздан мәгърифәтле адәмнәребезне дә (Аллаһ күрсәтмәсен) исламнан биздерәчәкбез һәм үз аягыбызга үзебез балта орачакбыз. Димәк, боларны ислам даирәсендә җыю һәм милли көчебезне куәтләү өчен безгә тиеш булган нәрсә – исламны тикшереп, асылындагы гадилегенә кайтару һәм һәркемгә үз акылынча аңларга рөхсәт бирү. Менә бу вакытта мөселманнар Аллаһ Тәгаләнең **«Без китап биргән кешеләр Аллаһ китабын хак уку белән укыйлар, һәр сүзенә ышанып гамәл кылалар, алар хак мөэминнәр»** [Коръән: 2:121] дип мактаганы кебек, тышкы ягына катмаслар, тәкълидләргә ябышмаслар, хыяллар һәм карашлар белән канәгатьләнмәсләр, серле Коръәнне аңларлар, йөкләмәләр файдасын һәм кануннар хикмәтен белдерерләр, иске фикерләрне изгеләштермәсләр. Димәк, боларның иманнары куәтләнеп, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырлар, болар Аллаһ Тәгаләнең **«Аллаһ китабына ышанмаучылар – һәлак булучылар»** [Коръән: 2:121] дип гаепләгәне кебек, диннәрен аңламыйча, төрле тәкълид һәм уйдырмалар белән измәс-

---

[31] Шәмседдин Мөхәммәд әл-Күһистани (1546 елда вафат) – дин галиме, ислам хокукы белгече.

[32] Заһиреддин Әбү әл-Фәтех әл-Вәлвәлиҗи (1145–1146 елларда вафат) – дин галиме, ислам хокукы белгече.

лəр, бидгать төрлəре һəм гадəтлəр тоташтырып, бозмаслар, үзлəре фикерлəрлəр, лəкин башкаларны үз фикерлəренə чакырып, фикер хөрриятенə каршы төшмəслəр. Бəлки һəркем Аллаһ китабы, Рəсүл сөннəтенə кайту максатында булыр, элекке имамнарның сүзен нигез [итеп] тотылып, Коръəн белəн хəдис төрле ялгыш аңлатулар белəн аларга яраклаштырылмас, бəлки аларның сүзе Китап белəн Сөннəткə муафыйк булса – кабул ителер, юк икəн – кире кагылыр һəм сəхабəлəр белəн табигыйннарның, мөҗтəһид имамнарның: «Каршылыклы иҗтиһад мəсьəлəлəрендə һəркемгə хөррият», – дигəн сүзлəре белəн дə гамəл булыр. Дөрес, бу вакытта, ихтимал, мəзһəб һəм каршылыклар күбəер, лəкин əүвəлге гасыр мөҗтəһидлəре кебек фанатизмсыз булган вакытта низаг һəм аралар өзүдə һич мəгънə булмас. Димəк, бер адəм акыл иясеннəн булдымы, иҗтиһад мəсьəлəлəрендə үз фикере белəн гамəл кылыр, Коръəн һəм Сөннəткə чакырган адəмнəрдəн нəфрəтлəнеп качмас һəм аны бозыклыкта, көферлектə [гаеплəп], сүкмəс. Фəкать мөмкин кадəр һəрбер нəрсəне аңларга тырышыр, булдыра алганча көч куяр һəм шəригать дəлиллəреннəн шəригать хөкемнəрен чыгару өчен кодрəтен сарыф итəр. Элеккелəрне олылауда һəм соңгыларны күтəрүдə арттырып җибəрмəс; тəфсир гыйлеме, хəдис гыйлемендə элеккелəр ирешкəн дəрəҗəгə ирешү мөмкин түгел, димəс; һəм белер ки: кайберəүлəр мөҗтəһид булу өчен тəфсир гыйлемендə, хəдис гыйлемендə һəм болар туктаган гарəп гыйлемнəрендə тирəн белем иясе булуны һəм кешелəр гадəтлəреннəн хəбəрдар булуны шарт дисəлəр дə, Мохтар Шатыйбиның[33] «Мүвəфəкат»ында[34] əйтелгəн кебек, гарəп гыйлемнəренең текстын һəм стилен аңлап, шəригать максатларын белү җитəдер. Шуның өчен дə мөҗтəһид [китергəн] бер хəдиснең сахих[35] һəм зəгыйфь булганлыгы кебек, иҗтиһад чыганагы булган фəннəрдə дə мөҗтəһид булмаучыга иярүне дөрес күргəннəр.

[33] Ибраһим Əбү Исхак бине Муса əш-Шатыйби (1388 елда вафат) – дин галиме, ислам хокукы белгече, гарəп теле белгече.

[34] Əш-Шатыйбиның ислам хокукы мəсьəлəлəренə багышланган «Мүвəфəкат» («Муафыйклыклар») хезмəте.

[35] Сахих – дөрес.

Хәтта имам Әбү Хәнифә дә бердәм рәвештә танылган мөҗтәһид була торып, аның заманында, аеруча Гыйракта хәдис риваятьләре күп булмаганлыктан, хәдисләрдән бик азын гына белергә бәхетле булган. Аллаһ Тәгаләнең бар иткән нәрсәләрендә булган сөннәте [кануны] көн саен прогресста, шуның өчен дә, диннәрнең ахыры булган ислам иң камил дин булганлыктан, бу заманда элеккеләр дәрәҗәсендә, бәлки алардан галимрәк кешеләрнең бар булуы бик мөмкин һәм Аллаһ Тәгаләнең кодрәтенә һәм сөннәтенә бик муафыйк. Шуның өчен әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам: «Кем безнең әмеребез булмаган нәрсәләрне сөйләсә, шулар кире кагылыр», – дип, дин турысында Аллаһ белән Рәсүленнән башкага таяныч юк икәнлекне аңлаткан кебек, дүрт имам үзләренә тәкълидтән тыйганнар. Әбү Хәнифә белән иярченнәре: «Безнең сүзләребез белән, аларны без кайдан алганны белмичә, фәтва бирергә беркемгә дә рөхсәт ителми», – дигәннәре кебек, икенче бер урында Әбү Хәнифә тагын: «Әгәр минем сүзем Китап һәм Сөннәткә каршы булса, сез аны ташлагыз!» – дип аңлаткан. Мәлик бине Әнәс[36] әйткән: «Мин адәм булганлыктан, савабым да, ялгышым да булыр, шуның өчен сез минем карашым хакында фикерләгез! Әгәр Китап белән Сөннәткә муафыйк булса – тотарсыз, юк икән – ташларсыз». Шулай ук бер мәртәбә имам Мәлик Хәрам мәчетендә хәдис сөйләгән вакытында Пакь бакчага [пәйгамбәр җирләнгән урынга] ишарә ясап: «Фәкать бу кабер иясенең сүзе кире кагылмас. Башкаларның һәммәсенең сүзе кире кагылыр», – дигән. Имам Шафигый да: «Хәзрәти Рәсүлдән башка һичкемгә дәлилсез иярү дөрес түгел», – дигән кебек, имам Әхмәд[37] тә: «Динеңдә һичкемгә тәкълид кылма! Рәсүлебез белән сәхабәләреннән риваять кылынган нәрсәләрне генә тот!» – дигән һәм шулай ук бер урында:

[36] Мәлик Әбү Габдулла бине Әнәс әл-Әсбәхи (711–795) – бөек дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, хәдис белгече, мәлики мәзһәбенә нигез салучы.

[37] Әхмәд Әбү Габдулла бине Хәнбәл әш-Шәйбани (780–855) – бөек дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, хәдис белгече, хәнбәли мәзһәбенә нигез салучы.

«Миңа да, Мәликкә дә, Шафигыйга да, Әүзагыйга[38] да һәм Сәүригә[39] дә тәкълид кылмагыз, бәлки алар алган җирдән (дәлилдән) алыгыз!» – дип аңлаткан.

Менә дүрт имам үзләренә тәкълиднең дөрес булмавын бердәм рәвештә белдергәннәр. Болар иҗтиһад кылырлар һәм, карашыбыз шушы, дип бәян итәрләр, ләкин һичкемгә, моны алу тиешле, дип әйтмәсләр иде. Теләгән кеше алыр, теләмәгән кеше – юк, һәркем ихтыярлы иде. Әбү Хәнифә: «Бу минем карашым, әгәр бер адәм моннан хәерлене китерсә, мин аны кабул итәчәкмен», – дигән кебек, имам Мәлик тә, Һарун әр-Рашид[40] адәмнәрне «Әл-мөваттаъ»[41] белән гамәлгә көчләү турысында киңәшендә: «Рәсүл сәхабәләре мәмләкәтләрдә таралдылар, һәрбер кавем алдында башкалар ишетмәгән хәдисләр бар», – дип аннан тыйды. Имам Шафигый да: «Әгәр бер адәмгә Рәсүл сөннәте билгеле булса, ул Сөннәтне һичкемнең сүзе белән кую – дөрес түгел», – дип, хәдис кабул итүендә үз сүзен ташларга киңәш итәр һәм үз шәкертләрен үзенә тәкълидтән тыяр иде. Имам Әхмәд тә үзенең фәтваләрен язудан һәм җыентык төзүдән баш тартыр иде. Болар үзләренең кайбер хөкемнәрдә хата кылачакларын бик ачык белерләр һәм бик ачык әйтерләр иде, болар һичбер вакытта үз фәтваләрен: «Менә бу хөкем катгый рәвештә Аллаһ белән рәсүленең хөкеме», – дип әйтмәсләр иде. Әгәр Әбү Хәнифәнең хөкеме билгеләнгән Аллаһ хөкеме булса, аңа Шафигый да, Мөхәммәд тә, Әбү Йосыф та һәм башкалар да – һичберсе каршылык кылмаслар иде. Әгәр ахыргылар уйлаган кебек, остазны олылау дип әйтү аның һәрбер сүзен һәм һәрбер фигылен дәлилсез, хәтта дәлилгә каршы булып, тәкълидтән гыйбарәт булса, иң элек сукырларча тәкълид кылган [кешеләр]

---

[38] Габдрахман Әбү Гамр бине Гамр әл-Әүзагый (704–774) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид.

[39] Суфъян Әбү Габдулла бине Сәгыйдь әс-Сәүри (716–778) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, хәдис белгече.

[40] Һарун Әбү Җәгъфәр бине Мөхәммәд әр-Рашид (766–809) – габбасилар династиясеннән булган гарәп хәлифе, дәүләт башлыгы.

[41] «Әл-мүвәттаъ» – имам Мәлик бине Әнәс төзегән хәдисләр җыентыгы.

Мөхәммәд белән Әбү Йосыф булырлар иде. Сез, мөкаллидләр! Остазыгызны олылауда арттырып: «Изге ул, хата кылмас» – дип, сез дә иң надан бер ахмакка сукырларча тәкълид кыласыз һәм пәйгамбәрләрдән башка һичбер изгенең хатадан азат түгеллеген хәтерегездән чыгарасыз һәм кыйбланы, күзе күргән вакытта да күзенә ышанмыйча, йолдыз белән нәтиҗә чыгарган адәм кебек кыланасыз. Аңлы күзегез белән шәригать дәлилләрен күрә торып, аннан качасыз һәм фәкыйһләр сүзенә тәкълид кыласыз! Шул ук вакытта, фәкыйһләр сүзен күргәндә шул үз күзегез иде, сез ышана торган кәлям[42] китапларының һәрберсендә акыл гыйлем сәбәпләреннән санала торып, сез шәригать дәлилләрен аңлау турысында акылның гыйлем сәбәбе булуын инкяр итәсез! Бу сәбәпле, үзегез дәгъва кылган бу китапларга һәм бу хатасыз адәмнәргә тәкълидтән чыгасыз, сез үзегез бу имамнарга тәкълид тиешле дисез. Шул ук вакытта, боларның, элекке заман изгеләренең: «Һичкемгә тәкълид дөрес түгел», – дип бердәм рәвештә кабул ителгән фикерләренә һәм иҗмагларына каршы киләсез! Үзегез бу дүрт мәзһәбтән чыгу дөрес түгел, дисез, үзегез исә: «Алардан соң [һиҗри белән] бишенче гасыр ахырына кадәр иҗтиһад бар иде», – дип әйтеп торасыз! Хәтта бишенче гасырдан соң да бик күп галимнәрнең иҗтиһадлары тапкырлык дәрәҗәсендә нык булган нәрсәләрдән: Тафтазани[43] «Хашия-и Гадуди»дә[44] әйткәндер ки: «Кавем сүзеннән, фәкыйһ мөҗтәһид булмыйча һәм мөҗтәһид фәкыйһ булмыйча, күз алдына китермәү аңлашыла, мөфти фәкыйһ булырга тиеш иде. Димәк, мөҗтәһид булуы да мәҗбүри булырга тиеш. Хәтта шафигыйлар казыйга да мөҗтәһид булуны шарт иткәннәр, хәнәфиләрдә[45] иҗтиһад иясеннән булмаган казыйны, иҗтиһад иясе булган мөфтинең кул

[42] Кәлям – фәлсәфә һәм акыл белән шәригать текстларын аңлатуга нигезләнгән схоластик дин белеме системасы. Кәлям ияләре булып могтәзилиләр, матуридиләр, әшгариләр һ.б. санала.

[43] Сәгъдеддин Мәсгудь бине Гомәр әт-Тафтазани (1322–1390) – гарәп философы, дин галиме.

[44] Тафтазаниның дини фәлсәфәгә, кәлямгә багышланган «Хашияи Гадудия» («Гадуди хашиясе») хезмәте.

[45] Хәнәфи – имам Әбү Хәнифә мәзһәбенә иярүче.

астында булса гына, билгеләү дөрес, дигәннәр, «Һидая»[46] [китабы] казыйның иҗтиһад иясеннән булуын шарт иткән. «Шәрхе Һидая» «Мохтасар әл-викая»[47] һәм «Мөлтәка әл-әбхүр»[48] [китаплары] иҗтиһадны фәкать яхшырак шарт дисәләр дә, «Фәтх әл-кадыйр»[49] [китабы]: «Мөҗтәһид булмаган кешенең хөкеменә иярү Шафигый, Мәлик, Әдһәм[50] мәзһәбләре һәм безнең галимнәребездән Мөхәммәд алдында дөрес түгел», – дип аңлаткан. «Мәҗмәгыль-әнһәр»[51] [китабы] «Фәтх»тән: «Карар кылынган кануни караш нигезендә: мөфти – ул мөҗтәһид», – дигән сүзне тапшырган. Димәк ки, мөҗтәһид булмаган кеше казый итеп билгеләнүнең дөреслегендә капма-каршы фикерләр булса да, мөҗтәһид булмаган кешене мөфти итеп билгеләү бердәм рәвештә дөрес түгел. Димәк, әгәр шулай икән, мөфтиләр һәм казыйларны хезмәткә билгеләү һичбер вакытта бетмәгән иде. Шуңа күрә иҗтиһад заманы да һичбер вакытта бетмәскә тиеш. Шуның өчен дә «Фәтхел-кадыйр» [китабы]: «Фикыһны белүче, Китап һәм хәдис иясе, сәләтлелеге яхшы, кешеләр гадәтләрен белгән адәмнең иҗтиһад итүе вәҗиб, һичкемгә тәкълиде дөрес түгел», – дип катгый [рәвештә] әйтелгән.

Сез, мөкаллидләр! «Дүрт имам бик борынгы һәм үзләренә иярүчеләр бик күп, димәк, аларның сүзләренә ышану тиеш», – дип, күплек һәм борынгылык белән дәлил эзлисез! Шул ук вакытта, әгәр дөреслек күплек һәм борынгылык белән булса,

---

[46] Борһанеддин Гали бине Әбү Бәкер әл-Мәргыйнаниның ислам хокукына багышланган «әл-Һидая» («Туры юл») хезмәте.

[47] Гобәйдулла бине Мәсгудь әл-Мәхбубиның ислам хокукына багышланган «Мохтасар әл-викая» («“Саклау” хезмәтенең кыскача аңлатмасы») хезмәте.

[48] Ибраһим бине Мөхәммәд әл-Хәләбинең ислам хокукына багышланган «Мөлтәка әл-әбхүр» («Диңгезләр кушылуы») хезмәте.

[49] Мөхәммәд Камаледдин бине Габделвахид Ибне Һөмамның ислам хокукына багышланган «Фәтхел-кадыйр» («Кодрәтле Аллаһның [хакыйкатьне] ачуы») хезмәте.

[50] Ибраһим Әбү Исхак бине Әдһәм әл-Гыйҗли (718–776) – дин галиме, аскет.

[51] Габдрахман бине Мөхәммәд Шәехзадәнең ислам хокукына багышланган «Мәҗмәгъ әл-әнһәр» («Елгалар җыелмасы») хезмәте.

насаралык һәм аннан күбрәк мәҗүсилек дөрес булырга тиеш иде. Ихтимал, сез әйтерсез: «Табиб дару үләннәренең табигатьләрен [сыйфатларын] тәҗрибә кылырга йөкләнгән булмаган кебек, без дә өлешчә хөкемнәрдә иҗтиһад белән йөкләнмәгәнбез», – дип, ләкин табиб тәмам аңлашылган һәм табибларның бердәм фикере белән хасил булган нәрсәләрне генә яңадан тәҗрибә кылырга йөкләнмәгән; әмма тәмам аңлашылып җитмәгән нәрсәләрне, хаклыкка ирешү өчен, кабат тәҗрибә кылып карарга, анысына тырышу һәрбер табибка тиеш. Безнең имамнарыбыз исә бик күп каршылыкларга кергәннәр, тәһарәт, гаурәт каплау мәсьәләләрендә дә бер бердәм фикергә килмәгәннәр; хәтта Шафигый иярченнәре: «Шафигый элекке мәзһәбен куеп, яңа мәзһәбкә кайтты», – дигәннәре, хәнәфиләрнең Әбү Хәнифәдән бер мәсьәлә турысында капма-каршы сүзләрен сөйләгәннәре кебек, бу имамнарның һәрберсе бер вакытта бер хөкемне кылып, икенче вакытта аңа бөтенләй башка икенче хөкемне биргәннәр. Димәк ки, болар хөкемнәрне кылып, катгый дип карау дәрәҗәсенә һич якын килмәгәннәр.

Шуңа күрә дини хөкемнәрне караган һәрбер акыл иясе шәригать дәлилләреннән үзе нәтиҗә чыгарырга тиешле. Дөреслеккә ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы булыр. Димәк, кешенең, хөррият һәм ихтыяр хикмәтләрен саклап, хөкем чыгару белән шөгыльләнүе үз-үзен хаталы булу мөмкинлеге белән әсир итүдән хәерлерәк. Димәк, мөкаллидләрнең «Заман ерак киткән, тикшерергә безнең кодрәтебез юк. Шуның өчен дөрессезлекне бездән артык белгән һәм хатасы бездән азрак булган элекке бер имамга тәкълид дөреслеккә якынрак» дип әйтүләре – ялган сүз һәм ялгышлыгы да үз-үзләренә мәгълүм. Чөнки элеккеләр каршылыклы фикерләргә кергән нәрсә дә – бер тарафны, сезнең әйтүегезчә, дәлилсез, хәтта шәригатьнең ачык текстына каршы булса да, алуга өстенлек бирү, хәтта кире кагылган өстен күрү һәм Аллаһ йөкләмәгән нәрсәне йөкләү.

Ихтимал, сез мөкаллидләр тагын әйтерсез: «Әгәр без Китап, Сөннәт һәм иҗмагтан дәлилен тапмаган бер нәрсәне шәригатебездән санамасак, гыйбадәтебездә дә, мөгамәлә итүебездә дә

шәригать хөкемнәре бик тараерга [мөмкин] һәм хокукый эшләребез дә шәригать җавабы белән бәйләнгән булмыйча, һәрберебез гыйбадәт һәм мөгамәләләр өлешләрендә фикеребез белән гамәл кылырга мәҗбүр булырга тиешле булабыз. Шул ук вакытта, мөгамәләләр тәртибе тәртип булмаудан хәерлерәк», – дип, ләкин сез үзегез дә, бәлки аңларсыз ки, тәртип кәгазьгә тәкълид кылуда түгел, бәлки иҗтиһад һәм хөррияттә. Гыйбадәт һәм мөгамәләләрдә, бер мәзһәбтә булмаса, дүрт мәзһәб арасында каршылыксыз бер мәсьәләгез юк ки, хәтта тәкълидегездә тәртип-фәлән күз алдында булсын. Әгәр иҗтиһад һәм хөррият юлын тотсагыз, шәригать дәлилләрен карар, заман хәлләрен һәм урын табигатенә муафыйк булган якны ихтыяр кылыр [идегез] дә, бу тәртип юклыктан котылыр идегез. Дөрес ике-өч адәмнең сүзләренә туры килгән гамәл чикләнмәгән адәмнәрнең сүзләренә туры килгән гамәлдән асатрак төсле күренә, шул ук вакытта, хакыйкатьтә, ике капма-каршы булган сүз арасын җыю нәкъ үзе шикелле үк капма-каршы сүз арасын җыю кебек мөмкин түгел. Шул ук вакытта, сезнеңчә дә иҗтиһад заманы [һиҗри белән] бишенче гасыр ахырына кадәр үтмәгәнлектән, сез ияру дөрес күргән мөҗтәһидләр дә чикләнмәгән. Шул ук вакытта, бу әмер турысында һичкем гади фикере белән эш йөртүе мөмкин түгел, бәлки Китап белән Сөннәткә һәм яхшы кешеләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу вакытта мөҗтәһидләр бер урында җыелып, күпчелекнең карашлары белән хөкем һәм карар бирүләрендә, кая капма-каршы сүзләр, бәлки ике капма-каршы сүз чыгарга да мөмкин түгел. Менә бу вакытта ун гасыр элек узган кешеләрнең исәпләре белән йөрү ахмаклыгы ихтыяр кылынмас, халык һәм җәмгыятьнең югары катлавы карашында изге шәригатьнең кадер-хөрмәте китмәс, Бохара халкы кебек, Мәхкәмәи шәргыя-дән качып, Иван хөкеменә бару булмас.

Сез Аллаһ йөкләмәгән нәрсәләр белән үзегезне йөкләп маташасыз! Әгәр исламда мәгълүм йөкләмәләрдән күбесе хәерле булса, Аллаһ Тәгалә аны игътибарсыз калдырмас һәм сезне аннан тыймас иде. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә бер урында дингә караган эшләр турында **«Китапта һичнәрсәне язмыйча**

**калдырмадык»** [Коръән: 6:38] дип дини әмерләрне тәмамлаганын сөйләгән хәлдә, тагын бер урында: **«Менә бүген динегезне, төзеп бетереп, тулы иттем, бирәсе нигъмәтләремне дә ислам дине белән бергә биреп бетердем һәм риза булып ислам динен сезгә ихтыяр кылдым»** [Коръән: 5:3], – дип Аллаһ йөкләмәгән нәрсәне йөкләүдән тыйган.

Менә Аллаһ Тәгалә сезгә булган хәерлекне өйрәтте. Заман белән урынның каршылыгы сәбәпле, төрле булган хөкемнәрне сезнең өйрәнүегезгә һәм ихтыярыгызга куйды, хәтта кеше тормыш гамәлләрен мөбах[52] дип белеп эшләсен! Тәкълид тәкъдирендәге кебек, Аллаһ әмеренә ирештемме, юкмы дип дулкынламасын! Һәрбер заман һәм һәрбер урынга мөнәсәбәт булган хөкемнәр кылып, катылык һәм тарлыклардан котылсын! Ләкин сез болай кылмадыгыз! Бәлки бөтенләй Аллаһ әмеренә каршы [булдыгыз], тәкълид сәбәпле харап булдыгыз! Нәкъ яһүд һәм насара юлларына иярдегез! Боларның да папа һәм монахлары, дин исеменнән төрле катылыклар кылдылар да, кешеләрне изеп, хайваннан ким бер дәрәҗәгә төшерделәр, болар нишләсәләр – [кешеләр] шуңа иярделәр. Халыкка фарыз һәм илаһи китапларны карау, хәрам һәм өчаллалык мәгънәләрен исәпләү көферлек иде. Европага Әндәлүс мөселманнары аркылы гыйлем, мәгърифәт керә башлагач, гыйлем белән берләшүе мөмкин булмаган насаралыкның югары катлау янында кадере бетте, гыйлем ярдәмчеләре һәм насаралык ярдәмчеләре арасында бик дәһшәтле, канлы вакыйгалар узды, ахырдан, гыйлемнең насаралыкны җиңүе белән тәмам булды. Менә хәзрәти Гайсә галәйһиссәламнең дине, үзгәртелеп, гыйлемгә каршы бер хыянәткә сугылганы өчен, шушы кызганыч хәлгә очрады. Сез! Менә боларны белергә һәм тәкълидтән, ислам гыйлемгә каршы, дип әйтүдән тәүбә кылырга кирәк иде! Ләкин, кызганычка каршы, сез шул юлда һаман дәвам итәсез, сез! Шушы бозык юл белән исламны сакламакчы буласыз, әгәр сез бу юлда дәвам итсәгез, насаралык башына килгән бәлане (Аллаһ күрсәтмәсен) ислам башына

---

[52] Мөбах – тыелмаган һәм боерылмаган эш; андый гамәлне үтәсәң дә, үтәмәсәң дә ярый.

китерәчәксез! Ислам нигезләрендә гыйлемгә каршы һичбер сүз юк, бәлки ислам һәрвакыт акылны мактаганлыктан, бүген игътибар белән өйрәнүчеләрнең аңлаганнары кебек, ачылган хакыйкый гыйлемнең һәрберсе Коръәндә ачык я ишарә [белән] искә алынганлыктан, гыйлем арткан саен ислам куәтләнәчәк, аңа иман артачак һәм Коръән мәхлук [кеше] эше түгел, бәлки Аллаһ сүзе икәнлеге тәмам аңлашылачак. Менә Коръәннең һәрбер заманда могҗизалы булуының сере – бу. Чыннан да, грек философлары аңлаткан, кешеләрнең акыллары меңнәрчә ел раслаган, хакыйкать дип белгән кагыйдәләренең бик күбесенең хорафат икәнлеге бүген тәмам мәйданга чыккан хәлдә, Коръән һәм Сөннәтнең көн саен ачылган нык хакыйкатьләргә муафыйк булып баруы, әлбәттә, иң зур галимнәр каршында бик кабул ителгән, гыйльми булган могҗизалардан. Элекке һәм хәзерге философлардан иң галим бер адәмнең хикмәткә караган сүзләреннән фәкать бармак белән санарлык бик азы хакыйкать булган хәлдә, әхлак һәм канунга, сәясәт һәм өйрәтүгә, моннан башкаларга караган санап бетерүе мөшкел [булган] Коръән һәм Сөннәт кагыйдәләренең һәрберсе муафыйк гыйлем һәм белем булып чыгуы, әлбәттә, философларның акылларын шаштырачак һәм алар каршында Коръән белән Сөннәтнең кадер-хөрмәтен бик арттырачак хәлләрдән. Ләкин бу хакыйкатьләр һәм бу могҗизалар тәкълид белән түгел, фәкать иҗтиһад белән мәйданга чыгачаклар, мәдрәсәләр тулы укый торган шәкертләребезнең мөселманлыклары да тәкълид белән түгел, бәлки әүвәлге исламга каршы хорафат, бидгать һәм басымнары бетү белән сакланачаклар. Андый хорафатлар ки, габбаси хәлифәләре заманында башланып, бүгенгә кадәр арта-арта килгәннәр.

Кайсыдыр вакытта ки габбаси хәлифәләре кәлям гыйлеменә тирән карый башладылар һәм бу турыда чит ил кешеләре дә бик күп хезмәт иттеләр. Менә шул вакытта «әйтелде», «әйттеләр» күбәйде, кәлямдә башланган бәхәсләр фикыһка да керде: кайсы мәзһәб беренче? Шуннан бәхәскә тотындылар. Әбү Хәнифә белән Шафигый арасындагы каршылыклар турында бәхәсләр башланды, фетнәләр кубарылды, сугышлар ачылды, һәркем үз

мәзһәбен тарату һәм башкаларны бетерергә кереште. Хәтта гарәп утравында Зәйд белән Әхмәд, көнбатышта Мәлик, Бохара һәм Төркестанда сыйнфый мәзһәбләреннән башка мәзһәбләр калмады. Бу мәзһәбләрдә китаплар һәм әсәрләр күбәйде, һәрбер адәм: «Мин шәригать нечкәлекләрен ачам һәм кимчелекләрне, мәзһәбләрне аңлатам», – дип, эш башлады, һәрбер язучы үз фазыйләтен күрсәтергә тырышты. Бәхәсләр, каршылыклар күбәйде; хәтта галим, изгеләрдән дә кайберләре, үзләре сизмичә, боларга катышкалады. Бу мескеннәр төзеклек шунда диделәр; ләкин аның бөтенләй тулысынча бозыклык икәнлегеннән ваемсыз булдылар да, Аллаһ Тәгаләнең **«Җир өстендә фетнә чыгарып, кешеләр арасын бозмагыз, диелсә аларга, «Юк, без бозмыйбыз, бәлки төзәтәбез», – диләр. Аң булыгыз! Шул монафикълар – кешеләр арасын бозып, җир өстендә бозыклык кылучылар, ләкин шуны үзләре сизмиләр»** [Коръән: 2:11-12] дигән сүзләренә дәлил булып киттеләр. Чыннан да, болар **«Әйт: “Мин сезгә хәбәр биримме гамәлдә алданучырак, каты хәсрәткә тиешлерәк кешеләр турында? Ул алданучы кешеләрнең дөньяда гамәлләре ялган булды, ягъни барча эшләре Аллаһка каршы булды, шулай булса да, яхшы эш эшлибез, изге гамәл кылабыз, дип уйлыйлар”»** [Коръән: 18:103-104] дигән хөрмәтле аять дәлил кылган кебек, гамәлләре белән үзләренә генә түгел, бәлки бөтен мөселманнарга зарар һәм хәсрәт китергән адәмнәр.

Менә шушылай шәригать хөкемнәренең даирәсе төрле хыяллар белән киңәйтелде дә соңгылар, кая нигезгә мөрәҗәгать, хәтта нигез булмаган нәрсәләрдән дә, илтифаттан да гаҗиз калдылар. Димәк, өммәт тәкълидкә карарланды, галим исемендәгеләр шул дин исемендәге хыялларда тирәнгә ябышты. Һичкемнән дәлил таләп итмәгәнлектән, мөфәссирләр[53] тәфсир китапларын гаҗәеп вакыйгалар һәм җен хикәяләре белән тутырды. Сәнәд[54] сорау гадәте киселгәнлектән, мөхәддисләр[55], теләсә

[53] Мөфәссир - Коръәнгә аңлатма язучылар.
[54] Сәнәд – хәдисләрнең кемнән кемгә тапшырылу чылбыры.
[55] Мөхәддис – хәдис белгече.

мәүдугта[56] булсын, һәрбер кызыклы хикәяләр-хәбәрләрне җыяр-га тотынды. Хөкем чыгару рәвешен сорау формасы күптән бет-кәнлектән, фәкыйһләр дә төрле-төрле шөбһәләр белән хөкем чыгарырга тотынды. Димәк, дәртләр кимеде, бетте. Шул кадәр [бетте] ки, хәтта иман белән көферлек арасын аеручы һәм ислам нигезе булган тәүхид[57] мәсьәләсендә дә тәкълид ихтыяр кы-лынды. Адашу нурдан, хаклык ялганнан аерылмады. Китаплар катыргысы арасында ни күренсә, шул яхшы дип табыла башла-ды. һәрбер наданлык тәкълид һәм каршылыксыз тану белән өретелде, һәрбер фирка үзенең элекке шәехе чыгарган китап-ларга, ачык текстка [Коръән һәм хәдисләргә] каршы булса да, фанатизм кыла башлады, каршылыкларны [нәфес-]һаваларына [яраклаштырып] куллануны нигез итте, һичберсе адәмнәргә дин өлкәсендә ясаган авырлыкларны муенына алудан курыкмады. Болар: «Өммәттәге төрле карашлар – рәхмәт», – диделәр. Дөрес, рәхмәт, ләкин әгәр дөрес кулланылса; әмма, әгәр бүген Казан һәм Бохара халкы белән Иран халкы арасында булган кебек, диндә бүленү һәм бер-берсен күрәлмауга сәбәп булса, ул вакытта, кая рәхмәткә сәбәп булсын, киресенчә, ләгънәт һәм һәлакәт сәбәбе. Болар һәрберсе үзләрен котылган фирка һәм башкаларны яңалыклар кертүче дип [гаепләп], бәхәсләр генә түгел, хәтта сугышлар кылыштылар. Димәк, Аллаһ Тәгалә хөр-мәтле Китабында һәрбер урында берләшергә куша һәм сәхабәләр йөрәкләренең өлфәтен Аллаһның рәхмәтеннән саный торып, кайсы акыл бу бүленүне рәхмәт дип әйтер?

Дөрес, элеккедәге каршылыклар һичбер фанатизмсыз һәм Китап белән Сөннәттән башка һичбер нәрсәгә бәйләнусыз бул-ганлыктан, бик файдалы һәм өммәткә бик бөек рәхмәт иде. Чөнки һәрбер фәкыйһ үзенең тарафындагы халыкның хәлләренә һәм хәерлегенә карап хөкем йөртер иде. Һичкем бер мәзһәбкә бәйләнып, ул мәзһәбнең хөкемнәре бер кавемнең әхлакына яки тормыш хәлләренә яисә илләрнең табигатенә муафыйк, мөлаем килсен-килмәсен, хөкеме бирмәс иде. Һәрбер фәкыйһ һәрбер

[56] Мәүдуг – ялган хәдис.
[57] Тәүхид – ихласлык белән бер Аллаһка гына табыну.

мәзһәбнең дәлиленә карар, тикшерер һәм кайсысының дәлиле куәтле булса, шуның белән хөкем бирер иде. Соңра бер заман килде, һәрбер кавем я өстен күрү яки варислык яисә гади фанатизм белән мәгълүм мәзһәбләрдән бер мәзһәбне ихтыяр [итте] һәм шул мәзһәбнең һәрбер хөкеменә, теләсә – мөлаем, теләсә – мөлаем булмасын, сукырларча тәкълид кылдылар. Бер хөкем үзләренә зарар, аны йөкләү бик авыр булса да, икенче мәзһәбтә аның киресенә бик ачык дәлилләр күренсә дә, бер мәзһәбкә, мөкаллиднең икенче мәзһәбтән кайбер хөкемнәр алуын – тәлфыйк[58] һәм тәлфыйк – дин белән уйнау мәгънәсендә хәрам, диделәр. Болар аңламадылар ки, дәлилләрне дикъкатьләп караудан күчереп һәм гомуми файдаларны саклап, төрле мәзһәбтән төрле хөкем алу бер дә дин белән уйнау түгел, бәлки тулысынча дөреслек. Шул ук вакытта, боларның «тәлфыйк» дигән нәрсәләре һәрбер яктан бөтенләй тәкълид иде. Бер адәм мөкаллид булдымы – мәзһәбләрне бергә кушучы булмыйча мөмкин түгелдер, чөнки һәрбер мөселман ки бер дини мәсьәләдә үзе туры юл табудан гаҗиз булдымы, аны галимнән соравы, ягъни ул турыда бер мөҗтәһидкә тәкълид кылуы ваҗиб. Табигый, мөҗтәһидләрнең берсен башкасыннан өстен күрүне булдыра алган һичбер мөкаллид юк ки, шуңа күрә һәрбер мөкаллид үзе белмәгән бер дини мәсьәлә турысында нинди мөҗтәһид туры килсә, шуңа тәкълид кылырга мәҗбүр.

Әгәр бер мөкаллид, мәлики[59] [мәзһәбендәге] галим әйткәнчә, ике савыттан ким суга бер тамчы хәмер төшсә, аны таза [чиста] дип, шуның белән коенса; хәнәфи галим әйткәнчә, ышкымаса; шафигый[60] галим әйткәнчә, тәһарәте бозылганнан соң, башының кайбер чәчләренә мәсех кылса; хәнбәли[61] галим әйткәнчә, бераз кан чыкканнан соң, иртәнге намазны укыса; зәйди галим әйткәнчә, бу намазны кояш чыкканнан соң укыса;

---

[58] Тәлфыйк – төрле мәзһәбтәге карашларны бергә кушу, җыю, берләштерү.

[59] Мәлики – имам Мәлик мәзһәбенә иярүче.

[60] Шафигый – имам Шафигый мәзһәбенә иярүче.

[61] Хәнбәли – имам Әхмәд бине Хәнбәл мәзһәбенә иярүче.

җәгъфәри галим әйткәнчә, әүвәлге фарыздан чыкмыйча, икенче намазга кушса, бу мөкаллиднең намазы Аллаһ каршында дөрес түгел, дип кем исбат итәр? Һичкем [исбат] итә алмас. Хәтта бу намазның беренче каршылыгына да дәлил табу мөшкел; чөнки һичбер мөкаллид дини әмерләренең һәммәсен билгеле бер галимнән алырга шәригатьчә беркайчан да мәҗбүр түгел. Хөрмәтле сәхабәләр дә иҗтиһад һәм хөкемнәрдә каршылыкларга керделәр һәм, шулай була торып, берсе башкасына оеп намаз укыды. Шул ук вакытта, болар, үз иҗтиһадларына нигезләнеп, имамның намазы дөрес түгел һәм аның дөреслеге имамга оючы намазының дөреслегенә шарт, дип хөкем итәләр иде. Димәк, бөек сәхабәләрнең, гомумән, болай эшләүләреннән соң, Әбү Хәнифә имам Мәликкә оюдан, Җәгъфәрнең суйган малын ашаудан сакланыр, шушындый фанатизм-наданлыкка капланыр иде, дип әйтергә кем батырчылык итәр? Шул ук вакытта, бу мәзһәбләрдән һәрбер мәзһәбтә өстенлек бирүче исеме белән танылган бик күп фәкыйһләр бар ки, аларның һәрберсе мөҗтәһид һәм һичберсе тәмам үз имамының мәзһәбе белән чикләнмәгән, азмы-күпме хөкемнәрдә аңа каршы килеп, икенче мөҗтәһиднең дәлиле яисә үз имамы тапкан бер дәлилне алыр иде. Чөнки ислам һәрбер мәсьәләдә имамга түгел, шәригатькә иярү һәм иҗтиһад урынында, үзеннән артык булса да, башканың иҗтиһады белән түгел, үз иҗтиһады белән гамәлгә кушу. Шуның өчен Әбү Хәнифә дә һәм башка һәммә фәкыйһләр дә, Әбү Бәкер[62] һәм Гомәр[63] кебек, бөек сәхабәләрнең зурлык һәм фазыйләтләрен ачык белә һәм таный торып, үзләре аларга бик күп иҗтиһад хөкемнәрендә каршы киткәннәр. Шул ук вакытта, һәрбер мәзһәбтә булган фәкыйһләр бүгенгә кадәр һәм бүген дә кайбер хөкемнәрдә имамның, мәсәлән, Әбү Хәнифәнең үз сүзе һәм кайберләрендә ул имамның иярчене, мәсәлән, Әбү Йосыф

[62] Әбү Бәкер әс-Сиддыйк Габдулла бине Әбү Кухафә (572–634) – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дусты, иярчене, беренче тугры хәлиф, бөек дин галиме.

[63] Гомәр Әбү Хәфс бине әл-Хаттаб (585–644) – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дусты, иярчене, икенче тугры хәлиф, бөек дин галиме.

яки Мөхәммәд сүзе белән алуны дөрес күрүдә һәм алуда. Менә моннан артык тагын нинди тәлфыйк кирәк? Димәк, әгәр шулай икән, сезнеңчә, бу тәлфыйк дөрес, чөнки сез үзегез дә Әбү Хәнифә иярченнәрен Шафигыйлар, имам Мәликләр һәм ибне Габбаслардан артык, дип әйтмисез! Димәк, Әбү Хәнифә, Шафигый, имам Мәлик һәм ибне Габбас сүзләре арасында беренче юл белән тәлфыйк дөрес булырга тиеш. Дөрес максат белән булган вакытта тәлфыйкта нинди зарар булсын? Шул ук вакытта, тәлфыйк, фәлән хәрам дип, диндә катылык һәм надан фанатизм сәбәпле, мөселманнар арасында бүлгәләнү, хәтта Мәккәнең Хәрам [мәчетендә] дүрт имамга дүрт урын һәм Мәдинәнең Хәрам [мәчетендә] дүрт михраб ясап, зур бүленү галәмәтләре кую – Аллаһ Тәгаләнең **«Динне тотыгыз һәм төрле фиркаларга бүленмәгез»** [Коръән: 42:13] дигәне кебек, сүзләренә каршы бик зур гөнаһ. Чәч һәм мыек кебек бик вак һәм әһәмиятсез эшләрдә һәрбер төрле тикшерүләргә, элекке ислам галимнәренең хәзрәти Рәсүлдән һәм тугры хәлифәләрдән бирле бер михрабта бер имам артында укылып килгән намазны дүрт михрабта дүрт имам артында укып җибәрүләре һәм Хәрам [мәчете] эчендә дүрт урын һәм дүрт михраб ясауга кадәр батырчылык итүләре ни кадәр гаҗәп хәл булса, бу дүрт урын һәм дүрт михрабны фәкать дүрт имам өчен ясап, алардан бөек һәм алардан хөрмәтле тугры хәлифәләр, фәкыйһ сәхабәләр өчен ясамаулары да – шул кадәр гаҗәп булачак бер эш. Диндә уйнау, тәлфыйк түгел, бәлки менә бу – тәлфыйк.

Шул ук вакытта, тәлфыйкның зарурлыгы фәкыйһләрнең хуплаулары һәм хакыйкать белән исламга бик зур гарьлек булган шәригать хәйләсенең зарурлыгыннан мөһимрәк. Болар Аллаһ Тәгаләнең хәзрәти Әюп хакында антын үтәү өчен, **«Бер уч салам алып хатыныңа сук, Аллаһ исеме белән әйткән антыңны үтәмичә гөнаһлы булып калма»** [Коръән: 38:44], дигән сүзе белән дәлил сорап, рибаны хуплау һәм зәкятне төшерүгә кадәр шәригать хәйләсен дөрес күрәләр һәм шушылай итеп шәригатьне бетерүгә кадәр баралар. Шул ук вакытта, тулысынча бер шәхескә кагылышлы булган гөнаһ белән гомум

халыкка кагылышлы бер шәригатьне юк итү арасында чагыштыру – аерма белән чагыштыру. Аллаһ Тәгалә яһүдләрнең хәйлә белән шимбә көн балык тотуларына шул кадәр ачуланган хәлдә, безнең фәкыйһләрнең моның кебек мең хәйләне дөрес күрүләре бик артык гаҗәп хәл. Әгәр бу бозык тәкълид урынына дөрес тәлфыйк ихтыяр кылынса; мөгамәләләргә кагылышлы иҗтиһад мәсьәләләрендә һәрбер заман һәм һәрбер хәлнең кирәклегенә карап, иҗтиһад дөрес күрелсә; күпчелек фикере һәм элекке солтан белән бер билгеләнгән хөкем кабул ителсә; икенче заман икенче хөкем мәслихәт икән, аның өчен тагын бу шәригатькә һәм хикмәткә муафыйк чарага мөрәҗәгать булса; һәрбер мәзһәб тигез каралып, фәкыйһләр арасында бу фанатизм һәм бу бүленүләр булмас; шәригать хәйләсе исемендәге бу «дин белән уйнаулар»га хәҗәт төшмәс; изге шәригатебез бу каршылыкларга һәм казыйлык белән фәтва бирүдә бу кадәр дошманлыкка иярттелергә [юл] куелмас иде.

Ләкин ни кыласың? Башка диннәр башына килгән каза ислам башына да килде, күзләр сукырайды, тарафларны тәкълид золымлыгы басты, хәтта [һижри белән] бишенче гасырдан соң иҗтиһад бетте, дип әйтүгә кадәр барылды. Шул ук вакытта, бу тарихтан бик күп соң, ягъни һиҗрәттән 751 елда вафат булган Ибне Каййим[64], шәригать дәвам ителгән кебек, иҗтиһадның дәвам ителүен сөйләгән һәм тик бу турыда «Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн»[65] исемле бер китап язган. Менә минем бу дәрәҗә-максатым шул китапны тәрҗемә итеп, милләт улларыма күрсәтү һәм, иҗтиһад бетте, дигән заманнан соңгы галимнәр һәм бөек адәмнәр ни сөйләгәннәр – шуны мәйданга кую. Хәтта иҗтиһад заманы бетмәде, дигән сүз яңа сүз түгел, бәлки иске сүз икәнлек билгеле булсын!

[64] Ибне Каййим әл-Җәүзия (тулы исеме Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әбү Бәкер бине Әюб бине Сәгъд әд-Димәшкый) (1292–1350) – бөек дин галиме, хәдис белгече, Коръәнне тәфсир кылучы, ислам хокукы белгече. Аның йөздән артык хезмәте билгеле.

[65] Оригинал басмада ялгыш «Игълям әл-мөвәффәкыйн» дип язылган.

Менә минем максатым – бу. Әгәр тәкълиднең ислам һәм мөселманнар башына китергән бәлаләре минем йөрәгемне бу кадәр яндырып куырмаса, мин туп-туры бу китапның тәрҗемәсенә керешер һәм төрле китаплардан хәтеремдә калган бу озын кереш өлешне язып маташмас идем. Менә шул хәсрәтләр, менә шул ачы хакыйкатьләр минем каләмемне бу сүзләрне язарга мәҗбүр итте. Инде максатка килим дә Ибне Каййимнең сүзләрен тәрҗемә итүгә тотыныйм.

## [Ибне Каййимнең «Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн» хезмәте]

Мөкаллидләргә әйтәм: «Әгәр сез тәкълидегезгә дәлил белән барсагыз, мөкаллид түгел, дәлилләүче буласыз! Әгәр дәлилсез бердәмлек юлы белән барсагыз, сезнең тәкълид яклы торган дәлилләрегезнең мәгънәсе калмый. Моның өстенә, әгәр шулай икән, сез дәлил белмәссез, сезнең тәкълидегез дә фәкать анык булмаган уй һәм чамалау дәрәҗәсендә кала. Димәк ки, сездә тәкълиднең хаклыгын дәгъва кылырга да көч юк; әмма сездән башка һәрбер төркем, хаклык бездә, дип дәгъва кылуда. Димәк, сез нинди йөз белән үзегезнең анык булмаган уй дәрәҗәсеннән узмаган фикерегезгә ышануларында катгый булган адәмнәрне өндисез? Шул ук вакытта, сезнең ияртүчегезгә тәкълидегез үзе тәкълидне хәрам кыла; чөнки сез тәкълид кыла торган имамнар үзләренә һәм башкаларга тәкълидтән бердәм рәвештә тыйдылар һәм каршысына дәлил торган сүзләрен куярга куштылар. Шуның өчен тәкълиднең ялган һәм тыелганлыгы белән үз китапларыгыз да туп-тулы. Хәтта, мөфти белән казыйның мөҗтәһид булулары шарт, дип һәрбер китабыгызда аңлатылган. Димәк, әгәр шулай икән, үзегез бу имамнарга җыйган мәзһәбләрендә тәкълидне дәгъва кыласыз! Нигә аларга асыл һәм нигез булган бу сүзләрендә тәкълидне кире кагасыз?! Хәтта аңа бар котыгыз белән каршы торасыз? Шул ук вакытта, сез дә һәм без дә беләбез ки, сәхабәләр һәм табигыйннар һәм тәбгы-табигыйннар заманында бер адәмнең һәрбер сүзенә тәкълид [кылган] һәм башкаларның сүзеннән

бөтенләй баш тарткан һичкем булмаган һәм бу бозык бидгать фәкать әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам хурлаган [һиҗри белән] 4 нче гасырда чыккан. Мөкаллидләр! Сез бу сүземнең ялганын дәгъва кылсагыз, бу хөрмәтле гасырлардан тәкълид турында берәр мисал күрсәтегез! Һәрберегезнең дә һичбер мисалыгыз юк; бәлки болар Китап белән Сөннәттән башкага иярмәделәр, Аллаһ белән Рәсүленең сүзен сәхабә хәбәренә, сәхабә хәбәрен башкаларга тәкъдим иттеләр һәм фәлән-фәләннең сүзләренә һич иярмәделәр. Менә бу сезнең фәләннәрегездән элек килеп кичкән өммәтнең олуг кешеләре, әлбәттә, туры юлда иделәр, боларның юлын дөрес түгел, адашу дип, табигый, сез дә әйтәчәк түгелсез! Димәк, әгәр шулай икән, боларның юлы – туры юл, әгәр шулай икән, туры юлның капма-каршысы – адашу; димәк, сезнең тәкълидегез дә адашу булып чыга. Шул ук вакытта, сезнең башлыкларыгыздан Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Ибне Мәсгудь, Ибне Габбас, Ибне Гомәр[66] һәм Гайшә[67] хәзрәтләре, билгеле, гыйлемлерәк, хәтта Сәгыйдь бине Мөсәййиб, Шәгъби, Гата, Тавус[68] кебекләр дә яхшырак иделәр. Димәк, нигә сез дин, гыйлем һәм хәбәр нәрсәләренең һәммәсен җыелган бу бөекләргә иярмисез һәм аларның сүзләреннән йөз чөерәсез дә алардан ким [булган] башка адәмнәргә тәкълид кыласыз?

Ихтимал, сез әйтерсез, нигездә, һәрбер мөкаллид әйтәчәк ки: «Безнең иябез борынгы изгеләр юлыннан йөргән һәм алар юлына кергән», – дип. Бу тәкъдирдә, башка имамнар бу эштә сезнең ияртүчегезгә катнашмаган, дисәгез, үзегезнең хайваннан да ким бер дәрәҗәгә төшүегезне исбатлаган булачаксыз! Әгәр катнашуларын танысагыз, ни өчен сез бу вакытта гүя ияртүчегез бөтен дөреслекне җыйганда, бөтен хата башкаларга калган кебек, ияртүчегезнең һәрбер сүзен кабул [итәсез] һәм аның кебек, бәлки

[66] Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Ибне Мәсгудь, Ибне Габбас, Ибне Гомәр – Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзеннән гыйлем алган хөрмәтле мөселманнар, аның иярченнәре (сәхабәләре).

[67] Гайшә бинте Әбү Бәкер – Мөхәммәд пәйгамбәрнең хөрмәтле хатыны.

[68] Сәгыйдь бине Мөсәййиб, Шәгъби, Гата, Тавус – сәхабәләрдән гыйлем алган мөселманнар (табигыйннар), бөек дин галимнәре.

аннан гыйлемле [булган] башкаларның һәммә сүзләрен кире кагасыз? Әгәр без тәкълид кылган затның гыйлеме күп һәм дине куәтле булганлыктан, әгәр борынгы изгеләргә каршы китсә, билгеле, бик куәтле дәлил тапканы өчен булырга тиеш, дисәгез, ул вакытта моның дәлиле куәтле; әмма моннан яхшырак булган хөрмәтле борынгы изгеләрнең дәлилләре зәгыйфь икәнлеген кайдан беләсез? Әгәр тәкълид белән, дисәгез, дөреслек – түбәнгә түгел, бәлки яхшыракка тәкълид кылу. Әгәр дәлил белән, дисәгез, тәкълидтән чыгып, капма-каршы дәгъвагыз – дәлилгә таяну юлына керәсез! Әгәр безнең иябез бер яшерен ысул белән өстенлек таба, дисәгез, ул вакытта сезнең ияртүчегезгә нисбәт белән шәригатьне төзүчегә [пәйгамбәргә] якынрак һәм шуңа күрә шәригатьнең сере азрак булган Гомәр, Гали һәм ибне Мәсгудь кебек хөрмәтле сәхабәләр беренче юл белән өстенлек табарга тиеш, сез начарракның сүзе белән яхшырак һәм гыйлемлерәккә каршылыкны дөрес күргәнче, гыйлемлерәк һәм яхшыракның сүзе белән начарракка каршылыкны дөрес күрсәгез, бәлки тәкълидегезгә бик яраклы эш кылган булыр идегез! Чөнки сезнең ияртүчегез белән аңа каршы булган мөҗтәһиднең берсе Гомәр яки Гали сүзен алган хәлдә, башкасы ибне Габбас яисә Гайшә сүзен алуда. Шуңа күрә, әгәр шулай икән, болар сәхабәләр сүзеннән чыкмаганнар. Димәк, безгә дә алар мөрәҗәгать иткән урынга мөрәҗәгать итәргә тиешле, дип, хөрмәтле сәхабәләргә иярүегез, бик дөрес һәм бик муафыйк. Шул ук вакытта, кайбер мәсьәләләр бар ки, сезнең ияртүчегез ул турыда Гомәр, Гали һәм Гайшә кебек сәхабәләрнең һәммәсенә каршы булган хәлдә, аңа каршы ахыргы мөҗтәһид аларга каршы булмауда. Димәк, әгәр шулай икән, бу ике зур галимнең берсенең сүзе сәхабәләргә муафыйк һәм башкасының сүзе сәхабәләргә каршы, әлбәттә, сәхабәләргә муафыйк булган сүзгә иярү тиешле һәм мәҗбүри.

Әфәнделәр! Бераз инсафлык кирәк, сез фәкать үз ияртүчегезнең сүзен таратасыз! Аның сүзенә каршы булган сәхабәләр һәм табигыйннар сүзләренә һич илтифат итмисез! Аның сүзенә яраклаштырабыз, дип, Китап белән Сөннәтне төрле-төрле ялгыш аңлатулар белән ачык билгеле булган [нәрсәдән] чыгарасыз!

Шул ук вакытта, Коръән Кәрим сезнең ияртүчегезнең фикеренә туры килү өчен түгел, бәлки аннан хөкем чыгару өчен иңдерелгән. Сез бу эшегез белән – үзегез беләсезме, юкмы – Аллаһ китабын, Рәсүл Сөннәтен, хөрмәтле сәхабәләр һәм бөек табигыйннар хәзрәтләренең һәммәсен хурлыйсыз һәм мыскыл итәсез! Шул ук вакытта, каршыгызда бу ияртүчегезнең замандашларыннан иң гыйлемлесе булуына һәм аннан соң аннан гыйлемлерәк кеше килмәячәгенә дә дәлилегез юк. Димәк, сезнең ияртүчегезгә тәкълид дип кешеләр хокукларындагы хөкемнәрегез һәм каннарны, малларны хәләл һәм хәрам кылуыгыз бик дәһшәтле, бик куркыныч бер нәрсә; чөнки сез бу хөкемнәрегез өчен Кыямәт көнендә, әлбәттә, соралачаксыз!

Сез дөньяда алдап котыласыз, әмма ахирәттә алдау мөмкин булмаганлыктан, ул җәза йортында бу хөкемнәребез Аллаһ һәм рәсүлләренең әмеренә муафыйк дип, тоткан ялган бер сүзне, әлбәттә, сөйләмәячәксез! Бәлки: «Бу хөкемнәребез Аллаһ һәм Рәсүленең әмеренә каршы», – дип, үз зарарыгызга үзегез шаһитлек итәчәксез! Әгәр: «Без аны Әбү Хәнифә яки Шафигый яисә Әбү Йосыф сүзеннән яисә соңыннан килгән берәрсенең китабыннан алдык», – дисәгез, ул вакытта: «Сез аны Минем әмерем беләнме яисә Минем әмеремнән башка алдыгызмы», – дип соралачаксыз! Менә шул вакытта, әгәр сез: «Без аны Синең һәм Рәсүлеңнең әмере белән алдык», – дип белсәгез, бик хуш булыр иде. Ләкин, әгәр шулай икән, моны исбатлау өчен Китап белән Сөннәттән һичбер дәлилегез юк. Шуның өчен сез, бу сүзне: «Ул бары [Аллаһ] Тәгалә алдында», – дип әйтмәячәксез! Димәк, сез дөреслекме, хатамы икәнен аңлы белмәгән бер нәрсә белән Аллаһ коллары арасында хөкем кылганыгыз өчен, Аллаһның хөкем һәм газабына очраячаксыз! Әмма ияртүчегез үзе Шафигыйның: «Дәлилсез гыйлем алган адәм, кулында фонаре булган хәлдә, яндырмыйча, караңгыда елан өстенә басып, үз-үзен чактырган адәм шикелле», – дигәне кебек, «Дәлилсез һичкемгә тәкълид кылмагыз», – дип әйтеп куйганлыктан, сезгә үз яхшылыкларыннан [савапларыннан] берәр нәрсәне бирү яисә сезнең гөнаһларыгыздан берәр нәрсәне алу ихтималы юк. Сез, мөкал-

лидләр, бик гаҗәп бер төркем! Әгәр Аллаһ китабыннан яисә Рәсүл хәдисләреннән ияртүчегезнең фикеренә муафыйк берәр сүз тапсагыз, аны аласыз һәм аның белән дәлил китерәсез; әгәр аятьләр, хәдисләр ияртүчегез сүзенә каршы булса, ун аять һәм йөз сахих хәдис күрсәгез дә, аңа иярмисез, бәлки аятьләрне ялгыш аңлатып, хәдисләрне бөтенләй илтифатсыз куясыз! Хәтта бер хәдиснең эчендә ияртүчегезнең сүзенә муафыйк булган хөкемне алып, каршы булганын кире кагасыз: **«Йокыдан торгач, берегез дә кулын, өч тапкыр юмыйча, савытка тыкмасын»** хәдисе белән очрашулар сәбәпле, суның нәҗесләнүенә дәлил ала торып, үзегез: «Юмыйча тыкса да, су нәҗесләнми, кулны юу важиб түгел», – дисез! **«Берәрегезнең савытыннан эт яласа, аны ул савытны җиде мәртәбә юыгыз»** хәдисе белән, эт ялаган савытның нәҗесләнүенә дәлил ала торып, үзегез: «Өч мәртәбә чайкау җитә, җиде мәртәбә мәҗбүри түгел», – дисез! (*Ибне Каййим шул турыда бу нәрсә өчен алтмыш алты шаһит [мисал] китергән, без, кыскартыр өчен, фәкать икесен тәрҗемә иттек).* Димәк ки, сезнеңчә нигез аять-хәдис түгел, бәлки ияртүчегез сүзе. Болар фәкать ияртүчегез сүзенә муафыйк булсалар, хәҗәт, әгәр муафыйк булмасалар, хәҗәт түгел. Моннан да аңлашылды ки, сез: «Без Аллаһ сүзе белән Рәсүл сүзеннән хаклыкны аңлый алмыйбыз, шуның өчен каршыбызда намусы һәм гыйльми куәте нык булган бер адәмгә тәкълид кылабыз», – дигән сүзегездә дә ялганлыйсыз! Сез ияртүчегез сүзенә муафыйк булган аять һәм хәдисләрне бик аңлыйсыз, хәтта омтылган нәрсәгезне исбатлау өчен аларга нык тотынасыз! Фәкать, әгәр ияртүчегез сүзенә каршы хакыйкать булса һәм аятьләр, хәдисләр белән төрле тарафтан кысылсагыз, менә шул вакытта сез аларны аңламаганга салынасыз һәм үз-үзегезне наданга һәм ахмакка чыгарырга тотынасыз!

Менә шушылай сез үзегезгә җай килгән җирдә иң галим һәм иң өстен киселә торып, бераз җайсыз килдеме, шунда ук койрыгыгызны борасыз, һичбер нәрсә белмәгәнгә салына башлыйсыз! Сез гаҗәп бер фирка! Иң матур һәм шуңа күрә иң ачык Аллаһ сүзе белән Рәсүл сүзеннән максатны аңламыйча, хаталар

белән, каршылыклар һәм каршы килүләр белән тулы башка бер кеше сүзеннән максат аңлавыгыз ни кадәр ерак һәм ни кадәр хакыйкатькә каршы булганлыгын азрак исәпләп карасагыз, үзегез дә белерсез! Аңа иярүчең мәҗбүрилегенә һәм сүзенең дөреслегенә һичбер дәлил тормаган бер кешегә ияребез, дип, башка һәрбер сүздән баш тартуыгыз, хәтта иң куәтле дәлил – Аллаһ сүзе белән Рәсүл сүзен дә ташлавыгыз – сезнең ахмаклыгыгыз һәм наданлыгыгызга иң куәтле дәлилләрдән. Шул ук вакытта, сез үзегез дә Әбү Хәнифәнең хатасын дөрес күрәсез, хәтта фарсыча Коръән уку дөрес, дигән сүз кебек, кайбер мәсьәләләрдә, чыннан да, хата кылып, соңра хатасын белеп, ике имам сүзенә кайтканлыгын да әйтәсез! Димәк, бик ихтимал ки, әгәр Әбү Хәнифә дөньяда озак торса, бәлки электән хөкем кылган тагын бик күп эшләрендә хатасын аңлап, икенче имамнарның сүзләренә кайтыр иде. Әмма Аллаһ сүзе белән Рәсүл сүзендә һич хата ихтималы юк. Димәк, сезнең хата ихтималы белән тулы бер сүзгә ияреп тә, һич хата ихтималы булмыйча, иң катгый бер сүзне куйганлыгыгызны **«Саңгыраулар, телсезләр һәм сукырлар, шуның өчен һич аңламаслар»** [Коръән: 2:171] җөмләсенә кертүдән башка һичбер мөрәҗәгать итү мөмкин түгел. Димәк, чөнки эш бу рәвештә. Сез бу тәкълид һәм бу хөкемнәрегезне, әлбәттә, Аллаһ һәм Рәсүленең шәригате, димәячәксез! Чөнки шәригать сезнең иярүчегезнең сүзе түгел, бәлки Китап белән Сөннәттән гыйбарәт. Табигый, сез бу хөкемнәрегезне шулай ук шәригатькә каршы димәячәксез! Димәк, өченче бер як калды ки, анысы шәригатьчәме, түгелме икәнен белмәүдән гыйбарәт. Шул ук вакытта, кешеләр хокуклары һәм шәригать эшләрендә белмичә хөкем кылуның бик начар һәм бик зур гөнаһ икәнлеген сез үзегез дә бик гүзәл беләсез.

Шулай ук әйтәбез: сез тәкълидчеләр, Аллаһ һәм Рәсүленең әмеренә, хөрмәтле сәхабәләрнең туры юлына, имамнарыгызның хәленә, гыйлем әһелләре юлына каршы киттегез! Сезнең эшегез Аллаһ әмеренә каршы, чөнки Коръән, мөселманнар бер нәрсәдә низаглашсалар, ул нәрсәне Аллаһ белән Рәсүленә кайтаруга куша. Шул ук вакытта, сез аны иярүчегез сүзенә кайтарасыз! Һәм Рәсүл

әмеренә каршы, чөнки әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам бер мәсьәләдә каршылык чыкса, үзе һәм тугры хәлифәләр сөннәтенә [гадәтенә] ябышырга, аны азау тешләр белән тешләргә кушты. Сез исә бер нәрсәдә каршылык булдымы, аны тик ияртүчегез сүзенә кайтарып, башка сүзләрнең һәммәсеннән баш тартасыз. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә: **«Әгәр аларга: “Аллаһ иңдергән Коръәнгә һәм рәсүлнең хөкемнәренә килегез”, – дип әйтелсә, шул вакытта күрерсең: алар синнән нык баш тартырлар»** [Коръән: 4:61], – дип, сезнең кебек, Аллаһ һәм Рәсүленең сүзенә риза булмыйча, башка хөкемгә ияргән адәмнәрне монафикъ исеме белән атап, гаепләгән. Һәм сәхабәләрнең туры юлына каршы, чөнки сәхабәләр арасында, башкаларның һәммәсеннән баш тартып, бер адәмнең бөтен сүзләрен муенына таккан һичкем юк иде. Бәлки алар Аллаһ Тәгаләнең **«Арагызда сезне хәерле эшләргә чакыручылар, яхшы эшләрне кылырга әмер итүчеләр һәм начар гамәлләрдән тыючылар булсын. Нәкъ менә шулар өстенлек табар»** [Коръән: 3:104] дигән сүзе белән гамәл кылып, фәлән-фәләннең фикеренә түгел, бәлки тулы хәерлек булган Аллаһ сүзе белән Рәсүл сөннәтенә өндәрләр иде. Менә котылу шушында. Сезнең тәкълидләрегездә, бидгатьләрегездә түгел. Һәм имамнарыгыз хәленә дә каршы, чөнки алар үзләренә һәм башкаларга тәкълидтән бик каты тыярлар, куркытырлар иде. Болар Аллаһ Тәгаләнең **«Ий, рәсүлләр, Без биргән ризыкларның хәләл, пакь булганын ашагыз һәм изге гамәлләр кылыгыз, Мин, әлбәттә, сезнең кылган гамәлләрегезне беләмен. Сезнең динегез – бер дин, ә Мин – сезнең Раббыгыз, Миннән куркыгыз»** [Коръән: 23:51–52] дигән сүзе буенча йөрерләр: яхшыны ашарлар, изгелекне кылырлар һәм тик бер Аллаһка буйсынырлар, вак каршылыкларны диндә бүленүгә һәм төрле фиркалар ясауга юл куймаслар, бәлки тик хаклыкны эзләрләр, аны башкаларның һәммәсенә тәкъдим итәрләр, хакны таптылармы, хәзер [үк] ул турыда бердәмлеккә килерләр иде. Кыскасы, боларның максатлары бер һәм юллары да бер иде. Сезнең кебек, җитмеш юлга һәм җитмеш фиркага аерылмаганнар иде, болар кебек башка гыйлем иясе дә галимнәр

сүзләрен тикшерерләр һәм аларны Аллаһ китабы белән Рәсүл сөннәтенә тәкъдим итәрләр. Димәк, әгәр муафыйк булса, алырлар, муафыйк булмаса, куярлар иде. Әгәр яраклы дип танулар, ачык каршы килүләр булмаса, аны иҗтиһад мәсьәләләреннән санарлар һәм аңа иярүне һичкемгә важиб, димәсләр һәм бу – хаклык, моннан башка һәммәсе ялган, дип һич әйтмәсләр иде. Соңра бер заман килде, мөкаллидләр дәвере ачылды, болар элекке юлны ташладылар, билгеләнгән динне үзгәрттеләр, Аллаһ китабы белән Рәсүл сөннәтен бер тарафка ташладылар һәм Аллаһ Тәгаләнең **«Алар диннәрен бүлгәләп бетерделәр, һәрбер адашкан фирка үзенең ялган дине белән мактаныр һәм аны хак дип белер»** [Коръән: 23:53] дигәне кебек, эшләрен фәкать язмаларга, ягъни язылган китапларга сөяделәр. Һәрбер мәсьәләне фәкать ияртүчеләренең сүзләренә тәкъдим иттеләр. Димәк, аралар аерылды, фиркалар күбәйде, һәрбер фирка үз ияртүчесенең сүзенә каршы аятьләрне, хәдисләрне кире кагарга тотындылар, аларны кире кагу өчен һәрбер төрле хәйләләргә төштеләр; ләкин бу хәйләләр дошманнарыннан чыкса, ул вакытта шәригать текстларын моның кебек ихтималлар белән кире кагу дөрес түгел, дип мыгырдый. Менә алар бу хәйләне үзләре кылдылар. Әгәр дошманнары кылсалар, аны төрле юллар белән кире кагарга тырыштылар. Шул ук вакытта, бу хәйләләрнең һичберсе ислам нигезләрендә һәм сәхабәләр заманында юк иде. Хөрмәтле сәхабәләр ул хөрмәтле Хәзрәттән [Мөхәммәд галәйһиссәламнән] ишеткән сүзләрне һичбер адәмнең фикеренә яраклаштырып карамаслар һәм аны кабул [итү] турысында һичбер муафыйкның яраклы булуына тукталып тормаслар иде. Менә аларга важиб бу иде. Әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең чакыруы, ул Хәзрәткә замандаш булган һәм Кыямәткә хәтле аның замандашы булмаган һәркемгә, сәхабәләргә мәҗбүри шикелле үк, соңгыларга да мәҗбүри булганлыктан, Кыямәткә кадәр безгә дә важиб бу иде. Билгеледер ки, бу эш аларга махсус түгел һәм алардан соң гамәлдән чыгарылган да түгел иде, ләкин сез боларның һичберсен карамадыгыз!

Аллаһ һәм Рәсүле важиб кылган юлдан чыгып, башыбызны бубларга суктыгыз! Аллаһ Тәгаләнең: **«Әгәр бу Коръән Аллаһтан башка бер кешенең сүзләре булса иде, әлбәттә, кешеләр анда бер-берсенә каршы булган сүзләрне күп табар иделәр»** [Коръән: 4:82] дигәне һәм имамнарыгызның бердәм рәвештә «Низаг урынында хаклык бер» дип аңлатулары кебек, бу каршылыклы сүзләр һәммәсе Аллаһ дине булуы мөмкин түгел иде, сез мөселманнарны шул бер-берсен бетергән каршылыклар эченә дин дип аттыгыз! Коръән белән Сөннәттән һәм ачык акылдан чыктыгыз! Динне наданнар фикеренә иярүче бер уенчык кебек иттегез! Шул ук вакытта, ислам Китап белән Сөннәттә бер әмер бәян ителгән: мөҗтәһид дөреслеккә ирешсә – ике әҗерле, әгәр хата кылса – бер әҗерле иде. Бу хакыйкать белән хаклыкны теләү, аңа ирешү өчен мөмкинлек дәрәҗәсенә иҗтиһадның мәҗбүрилеген һәм көч дәрәҗәсенә тәкъвалыкның да мәҗбүрилеген сез үзегез дә таный идегез. Тәкъвалыкның Аллаһ әмерләрен тоту һәм Аллаһ тыюларыннан тыелудан гыйбарәт булганлыгы, бер нәрсәне кылу яисә кую өчен белүнең билгеле мәҗбүрилеге, белүнең дә иҗтиһадсыз мөмкин түгеллеге сезнеңчә дә ышанычлы мәсьәлә булган хәлдә, бу саваплы иҗтиһадны куюыгыз һәм бер-берсен ныгыткан Аллаһ китабы һәм Аллаһ Рәсүленең сөннәтеннән йөз чөереп, каршылыклар һәм каршы килүләр белән тулган китапларга, фәлән-фәләннең сүзләренә мөрәҗәгатегез бик артык гаҗәпләнү булачак бер мәсьәлә. Бу кадәр төрле сүзләрне, фәкыйһләрнең кайсысы дөрес икәнлеген Китап белән Сөннәткә мөрәҗәгатьсез ничек белергә кирәк? Безне бу кадәр капма-каршы сүзләр арасына атудан һәм дә хатадан «сез мөкаллидләрчә дә» кимчелексез булмаган бер адәмнең бар сүзләренә иярергә әмер итүдән Аллаһ белән Рәсүле пакь. Менә эш шушылай була торып, сез тәлфыйкны дөрес күрмәсәгез дә, Әбү Хәнифә белән Шафигыйдан, имам Мөхәммәд белән Әбү Йосыфтан теләсә кайсысына тәкълидне дөрес күрәсез һәм билгеле берсенә тәкълид важиб түгел, дисез! Билгеле ике капма-каршының һәр икесе [дә] дөрес түгел, димәк, әгәр беренчесе дөрес булса, хаклыктан ялганга күчүне, әгәр икенчесе дөрес булса,

хаклыкка каршы нәрсәдә дәвамлыкны дөрес күрәсез; соңра сез, боларның берсенә, әлбәттә, дөрес дип иярәсез, сез моның дөреслеген кайдан беләсез? Әгәр дәлил белән белдек, дисәгез, мөкаллид түгел, дәлил эзләүче сез! Әгәр тәкълид белән белдек, чөнки аның гыйлеме куәтле һәм диндарлыгы бик мәшһүр булганлыктан, хаклыктан башканы, билгеле, сөйләмәс, дисәгез, ул вакытта, әгәр аны кимчелексез, дисәгез, аның «Мин кимчелексез түгел» дигән үз юлын ялган кыласыз, әгәр аңа хатаны дөрес күрсәгез, бу билгеле мәсьәләдә фәкать аның сүзе дөрес, башка каршыларның һәммәсенең сүзе хата, дип кайдан белдегез? Ихтимал, сез ул, хата кыйлса да, саваплы бит, димәк, бу саваплы эштә иярүебездән без дә саваплы, диячәксез! Дөрес, ул саваплы, ләкин хатасы өчен түгел, аңа әмер ителгән булган иҗтиһадны кылганы өчен саваплы, сез исә бу әмер ителгәнне кылмаганыгыз өчен саваплы түгел, бәлки гөнаһлы. Әгәр мәгърифәт-хаклыкка ирешү өчен сез дә иҗтиһадыгызны сарыф итсәгез, ул вакытта сез дә саваплы булыр идегез; ләкин сез көчегезне сарыф итмәдегез! Хәтта ачык фанатизмга чумып, иярттүчегез сүзенә каршы булган Китап белән Сөннәтне дә кире кагуга кадәр батырлык иттегез! Турысы, сез иярттүчегезнең сүзенә сукырларча иярдегез, аның хөкемнәрен сөйләдегез, җаваплылыгы сөйләүчедә, дип уйладыгыз, шушы гозерегез белән хөкем итүчеләрнең иң гадел хөкем итүчесе [Аллаһ] каршында котылмакчы булдыгыз?! Шул ук вакытта, иярттүчегез: «Дәлилсез миңа иярмәгез», – дип, бу җаваплылыкны үз өстеннән төшергән иде; шуңа күрә сез адәмнәр арасында белмичә кылдыгыз, бу хөкемнәрегез өчен Аллаһ каршында соралачаксыз һәм газапланачаксыз!

Шулай ук сез мөкаллидләргә әйтәбез: иярттүчегезнең сүзе тик үз сүзе булу ягыннан һич шәригатьчә түгел, димәк, бу сәбәпле, аның белән һич гамәл кылмаячаксыз! Әгәр бу сүзне: «Әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнән сөйләнелә», – дисәгез, бу сүзне һич әйтмәгән хәзрәти Рәсүлгә дә, «Моны хәзрәти Рәсүл әйтте» димәгән иярттүчегезгә дә яла яккан булачаксыз! Әгәр шулай икән, хәзрәти Рәсүл үзебездән гыйлемлерәккә иярү, белмәгәнебезне белгән кешеләрдән сорау һәм гыйлем ияләренең

хөкем чыгаруына мөрәҗәгать [итү] белән әмер итте. Димәк, без бу тәкълидебездә Рәсүл әмеренә ияргүче дисәгез, бик тугры, без дә Рәсүл әмеренә ияру тиешле, дип дәгъва кылабыз. Ләкин, әгәр бер урында Рәсүл әмере белән ияртүчегез сүзе кара-каршы килсәләр, бу вакытта сез кайсысын алачаксыз? Әгәр Рәсүл әмерен алып, ияртүчегез сүзен диварга суксагыз, ул вакытта тәкълидтән чыгып, дәлил эзләүче булып китәсез! Әгәр ияртүчегез сүзен алсагыз, Рәсүл әмерен Аллаһка тапшырсагыз һәм: «Безнең иябез Рәсүл әмерен бездән яхшырак белүче, әгәр Рәсүл әмере гамәлдән чыккан яки башка бер куәтлерәк дәлил каршы [булса] яисә аның алдында дөрес булмаса, әлбәттә, ул аңа каршылык кылмас иде», – дисәгез, бу вакытта сез ияртүчегезнең сүзен нык һәм Рәсүл сүзен зәгыйфь [санап], кире каккан булачаксыз! Дөрес, гыйлем әһелләреннән сорау тиешле; ләкин ул коры гыйлемнән гыйбарәт түгел, бәлки Аллаһ Тәгаләнең **«Өегездә укылган Аллаһның аятьләрен һәм хөкемнәрен зекер итегез»** [Коръән: 33:34] дип, Рәсүл хатыннарына әмер ителгән гыйлем кебек, Коръән һәм хәдистән гыйбарәт. Менә без шушы гыйлемгә ияргә әмер ителгәнбез. Димәк, әгәр бер кеше үзе белмәсә, гыйлем ияләренә, ягъни хәзрәти Рәсүлгә иңгән гыйлемне белгән адәмгә мөрәҗәгать итәр һәм ул хәбәр биргән нәрсәгә ияргер, билгеле бер кешене максат итеп тотмас. Борынгы изгеләр һәммәсе бу юлда иделәр, аларның һәрбер сүзенә ияргә торган билгеле бер ияртүчеләре юк иде. Габдулла бине Габбас хөрмәтле сәхабәләрдән фәкать хәзрәти Рәсүлнең сүзеннән, эшеннән, сөннәтеннән сорар, башка һичбер нәрсәдән сорамас иде. Сәхабәләр дә мөэминнәр аналарыннан [пәйгамбәр хатыннарыннан], аеруча хәзрәти Гайшәдән ул Хәзрәт салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең өендәге эшләрен генә сорарлар һәм табигыйннар, фикыһ имамнары да шушылай эшләрләр иде. Шафигыйның Әхмәдкә: «Син хәдисне миннән артык беләсең, әгәр бер хәдис синең алдыңда сахих булдымы, теләсә Шамнан, теләсә Куфидан, теләсә Басрадан булсын, син аны миңа белдерә күр! Мин аңа барачакмын», – дигән кебек, гыйлем ияләренең һичберсе билгеле бер адәмнең карашыннан һәм мәзһәбеннән сорамас һәм башка-

ларның һәммәсеннән йөз чөереп, билгеле берсенә багланмас иде. Шул ук вакытта, тәкълид, бердәм рәвештә кабул ителгәнчә, гыйлем түгел һәм гыйлемсез фәтва биргән адәм хакында әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам: «Алар аны үтерде, Аллаһ аларны үтерсен», – дип бәддога кылган иде, берәр нәрсәгә Рәсүл бәддога кылдымы – ул нәрсә билгеле хәрам. Димәк, бу Рәсүл әмере буенча да тәкълид хәрам булып чыга.

Әгәр сез: «Хәзрәти Гомәр килялә[69] хакында: «Мин Әбү Бәкернең каршысына барудан Аллаһ Тәгаләдән ояламын», – дип, Әбү Бәкергә тәкълид кылган бит», – дисәгез, әйтербез: моның белән хәзрәти Гомәрнең хәзрәти Әбү Бәкергә фәкать бер мәсьәләдә тәкълиде нык була. Моннан исә сезнең әйткәнегез кебек, бер адәмнең һәрбер сүзенә шәригать текстларына да илтифат итмәү һич тиеш түгел». Барсын, хәзрәти Гомәрнең хәзрәти Әбү Бәкергә һәрбер сүзендә тәкълиде нык та булсын! Бу вакытта да сезнең өчен һичбер файда юк. Чөнки сез сәхабәләргә һич тиң булмаган кешеләргә тәкълид кыласыз, ияртүчелә-регезнең сүзенә ияреп, бер дә оятсыз [рәвештә] Әбү Бәкер белән Гомәргә каршы китәсез, хәтта, Шафигыйның кайбер нигез китапларында күренгән кебек, кайберләрегез бар ки, Әбү Бәкер белән Гомәргә тәкълид хәрам һәм Шафигыйга тәкълид ваҗиб, дисез, Шафигыйга һәм башка имамнарга тәкълид турысында һичбер сүз булмыйча, бу икесенә иярү хакында күп хәдисләр барлыгын бөтен хәтерегездән чыгарасыз! Сез менә хәзрәти Гомәрне үрнәк итеп тотыгыз! Ул оялган нәрсәдән оялыгыз да Әбү Бәкергә тәкълид кылыгыз! Бәлки ул вакытта сездән Аллаһ та һәм Рәсүле дә риза булыр. Шул ук вакытта, сез бу хәдисне кыскарттыгыз һәм үзегезгә җайсыз җирен алып ташладыгыз! Хәдиснең ахыры болай: Әбү Бәкер, киляләә турысында: «Мин [үз] фикерем белән хөкем кыламын, дөрес булса, Аллаһтан, хата булса, миннән һәм шайтаннан. Киляләә дию – бала һәм ата-анадан башка нәрсә дип әйтү», – дигән хөкеменнән соң, хәзрәти Гомәр: «Мин Әбү Бәкернең каршысына барудан Аллаһ Тәгаләдән ояламын», – дигән. Димәк, бу хәдис буенча Гомәрнең Әбү

[69] Киляләә – ерак туганлык.

Бәкергә каршылыгыннан ояты бу хөкемне кылу турысында үзенә түгел, бәлки сүзенең һәммәсенең дөрес түгеллеге һәм эшләргә яраклы хата белән әйтү турыларында. Шуның өчен дә хәзрәти Гомәр вафат алдыннан: «Мин киляләә турысында һичбер нәрсә аңламадым», – дигән һәм яшәгән вакытында хәзрәти Әбү Бәкергә бик күп җирдә каршы киткән. Әбү Бәкер диннән чыккан мөртәдне әсир иткән иде, Гомәр, өмме вәләдтән[70] башкаларын азат итеп, иярәренә кайтарды. Әбү Бәкер басып алынган җирне бүлде, Гомәр вакыф итте. Әбү Бәкер бүләк итеп бирүдә тигезләр, Гомәр сайлауны дөрес күрер иде. Әбү Бәкер берәүне үз урынына билгеләгән иде, Гомәр исә, хәзрәти Рәсүлгә ияреп, аннан баш тартты һәм Әбү Бәкер сүзен, хәзрәти Рәсүл сөннәте каршысында, диварга сукты. Менә борынгы изгеләр сезнең кебек түгел, бәлки Рәсүл сөннәте каршысында һичбер нәрсәне кабул кылмаслар иде. Фәкать бу зарарлы бидгатьләрне соңра сез чыгардыгыз да мөселманнарның башын бу кадәр бәлаләргә суктыгыз!

Дөрес, Гомәр Әбү Бәкергә: «Безнең карашыбыз синең карашыңа бәйле» дигән, ләкин бу сүзне «Сахих Бохари»да Тарикъ бине Шиһабтан риваять кылынган озын бер хәдис арасында искә алган ки, ул хәдиснең үзеннән Гомәрнең Әбү Бәкергә кайбер җирләрдә каршы булуы бик ачык аңлашыла. Чөнки ул хәдистә Әбү Бәкер, диятне[71] алмауны хөкем кылган хәлдә, Гомәр диятне алуны сөйләгән иде. Димәк, хәзрәти Гомәрнең бу сүзендәге иярү тәкълид мәгънәсендә түгел, бәлки «Синең карашыңны, дәлиленә карап, дөресрәк итеп таптык та шуңа ияртдек» мәгънәсендә. Мәсрукның: «Мин Ибне Мәсгудь сүзләрен башка кеше сүзләре кебек кире какмадым» дигән сүзенең дә мәгънәсе – бу. Ибне Мәсгудь белән Ибне Гомәрнең, үз сүзләрен куеп, Гомәр сүзе белән һәм дә Зәеднең, үз сүзен куеп, Гали сүзе белән алулары да тәкълид түгел, бәлки фикерләр берләшкән вакытта галимнең галимгә туры килгәнлеге турысында иде. Шуның өчен дә болар, бер сөннәт билгеле булса, аның каршысында һичкемнең сүзен кабул итмәсләр иде,

[70] Өмме вәләд – үз хуҗасыннан бала тапкан кол хатын.

[71] Дият – берәүнең үтерелгәне өчен түләнгән мал.

каршысындагы кешенең дәлил куәте билгеле булса, сезнең кебек, надан фанатизмга барып, аны кабул итүдән баш та тартмаслар иде. Шуның өчен дә Зәед белән Ибне Гомәр дәлил каршысындагы Гомәр сүзен кабул итмәгәнлекләре кебек, Ибне Мәсгудь тә Гомәрнең бер талак дип әйткән хәрам сүзен ант дигән. (*Ибне Каййим бу күләмдә Ибне Мәсгудьнең Гомәргә йөз мәсьәләдә фикер каршылыгы барлыгын искә алган).* Ибне Габбас та бер сөннәт каршысында: «Әбү Бәкер һәм Гомәр әйтте», – дигән кешегә: «Башыгызга таш явар, мин: «Рәсүлүллаһ әйтте», – дигән хәлдә, сез Әбү Бәкер һәм Гомәр сүзләрен каршы куюда!» – дип ачуын белдергән. Шул ук вакытта, сез мөкаллидләр! Сөннәт каршысында сәхабәләрдән бик күп дәрәҗә түбән кешеләрнең дә сүзләрен кабул итүдә! Бу бозык юлыгызга хәзрәти Рәсүлнең: **«Мөгаз сезгә нәрсә боерса, шуңа иярегез»**, – дигән сүзе белән дә дәлил эзләүдә. Шул ук вакытта, бу хәдиснең мәгънәсе «Мөгазга һәрбер эшендә иярегез» дигән сүз түгел, бәлки әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең белгән билгеле бер эшендә иярегез, дип әйтү ки, хәдис сүзе шуны таләп иткән кебек, бу иярүнең тиешлеге дә Мөгаз эшләгәнлек өчен түгел, бәлки ул хәзрәти салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең әмере белән нык. Шуның өчен дә хәзрәти Мөгаз үзе: «Динегезне туры юлда булган галимнән дә тәкълид белән алмагыз, Коръәннең, юлкүрсәткеч кебек, бик ачык аңлаешлы җирләре бар, аларны һичкемнән сорамагыз, белмәгән җирләрен галименә тапшырыгыз!» – дип, тәкълидтән тыйган һәм ачык аңлаешлы Коръәнгә ияргә һәм авыр булганда туктарга әмер иткән.

Әгәр сез: «Аллаһ Тәгалә башлыкларыгызга буйсынырга кушты, алар галимнәр иде, димәк, аларның фәтваләренә тәкълид ваҗиб», – дисәгез, җавап: башлыклар фәкать галимнәр түгел, бәлки галимнәр белән әмирләр. Дөрес, боларга буйсыну ваҗиб, ләкин Аллаһ һәм Рәсүле кушкан эшләрдә ваҗиб. Элекке галимнәр Аллаһ һәм Рәсүле кушкан эшләрне ирештерүдә һәм вазыйфаларын үтәгән әмирләр дә бик ирештерерләр иде. Моннан, сез уйлаган кебек, кешеләрнең уйларын Рәсүл сөннәтенә тәкъдим итү һәм аларга тәкълиднең тиешлеге бер дә аңлашылмый. Хәтта,

киресенчә, бу аять тәкълиднең бик ачык ялган икәнен күрсәтүдә. Чөнки бу аять Аллаһ һәм Рәсүленә буйсыну, ягъни әмерләрен тоту һәм тыйганнарыннан тыелырга киңәш бирә. Димәк, Аллаһ һәм Рәсүленә буйсыну өчен Аллаһ әмерен һәм Рәсүл әмерен белергә кирәк. Шуңа күрә, әгәр бер кеше, сез мөкаллидләр кебек: «Мин Аллаһ һәм Рәсүленең әмерләрен белмимен, бәлки фәкать гыйлем ияләренә тәкълид кыламын», – дисә, ул кешенең Аллаһка буйсынуының һәм Рәсүлгә буйсынуының дөреслеге мөмкин түгел. Шуның өчен Мөгаз бине Җәбәл, Габдулла бине Мәсгудь, Габдулла бине Гомәр, Габдулла бине Габбас, Әбү Хәнифә, Шафигый, Мәлик, Әхмәд кебек сәхабәләр һәм имамнар, үзләре башлык була торып, үзләренә тәкълидтән тыюлары нык булган. Инде әгәр боларның бу сүзләренә буйсыну важиб булса, тәкълидегез ялган, әгәр важиб булмаса, дәлил китерүегез бозык. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә, моның өстенә: **«Әгәр бер дини мәсьәләдә бәхәсләшсәгез, ул вакытта Аллаһка һәм рәсүлгә мөрәҗәгать итегез! Әгәр Аллаһка һәм ахирәт көненә ышансагыз»** [Коръән: 4:59], – дип, бәхәсләшү, иҗтиһад белән табылган мәсьәләләрне Аллаһ сүзе һәм Рәсүл сөннәтеннән башка һәрбер фикер һәм һәрбер мәзһәбне кире каккан һәм тәкълидтән тыйган. Шуңа күрә башлыкларга Аллаһ һәм Рәсүле хәбәр биргән нәрсәләрдә генә буйсыну тиешле. Димәк, бу вакыт боларга буйсыну нигезле, Аллаһ һәм Рәсүленә буйсыну булып чыга. Шуның белән бергә, бу вакытта да сез уйлаганча, башлыкларга буйсыну мәгънәсе калмый түгел, бәлки һаман кала, бу шәригать текстына иң муафыйк [итеп] ияреп буйсыну мәгънәсе кала, чөнки бу текст боларга нигезле түгел, бәлки ияреп буйсынырга әмер иткән һәм шуның өчен, гамәл кылучыны кайтармыйча, Рәсүлгә буйсынуына чагыштыру китергән. Әмма Рәсүлгә иярү башлыкларга иярү кебек, ияреп түгел, бәлки нигезле икәнлеген аңлату өчен анысын гамәл кылучы белән аерым итеп китергән һәм Коръәндә булсын-булмасын, Рәсүл әмеренә буйсынуның мәҗбүрилеген аңлаткан.

Әгәр сез: «Аллаһ Тәгалә мөһаҗирләр[72] белән әнсарларга[73] ияргәннәрне **«Һәм алар артыннан иярүчеләр»** [Коръән: 9:100] дип мактады, боларга яхшылык белән ияру – тәкълид бит», – дисәгез, җавап: юк, бер дә тәкълид түгел, бәлки аларның юлларына керү. Чөнки алар тәкълидтән тыйдылар, мөкаллидне акыл иясеннән түгел, диделәр. Алар арасында бу мөкаллидләр мәзһәбендә булган бер кеше дә юк иде, алар шәригать текстларын кешеләрнең фикерләренә кайтарудан бик ерак иделәр. Димәк, боларга яхшылык белән иярүчеләр шундый галимнәр ки, алар Аллаһ китабы һәм Рәсүл сөннәтенә һичкемнең сүзен алдан куймаслар һәм һичкемгә сукырларча тәкълид кылмаслар. Димәк, бу аять, сез әйткәнчә, тәкълиднең файдасына түгел, бәлки аңа каршы дәлил. Әгәр бу аятьтәге ияру, сез әйткәнчә, сукырларча тәкълидтән гыйбарәт булса, Әбү Йосыф белән Мөхәммәд Әбү Хәнифәгә, Бохари белән Мөслим кебек Әхмәд иярченнәре Әхмәднең үзенә бик күп җирдә каршы булганнар. Димәк, надан һәм сукырларча тәкълид дәгъвасында булган сезнең Әбү Хәнифә белән Әхмәдкә иярүегез аларның иярүләреннән куәтлерәк булса кирәк. Сез моны әйтергә, табигый, үзегез дә батырчылык итмәячәксез!

Әгәр сез: «Әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең: «Минем сәхабәләрем йолдызлар шикелле: аларның кайсына иярсәгез дә, туры юлны табарсыз», – дигән сүзе тәкълиднең дөреслегенә ачыклык бит», – дисәгез, җавап: бу сүзнең әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнән [ирешүе] дөрес түгел. Дөрес булган тәкъдирдә, сез үзегез йолдызларны куйдыгыз да алардан бик күп мәртәбә ким булган кешеләргә тәкълидне ихтыяр иттегез, дүрт имамга тәкълидне дүрт хәлифәгә тәкълид кылудан олы күрдегез һәм шушылай итеп хәдис бик ачык дәлилләгән нәрсәгә каршы киттегез. Шул ук вакытта, сәхабәләр арасында бик күп хөкемнәрдә каршылыклар бар иде, кайберләре өч талакны бер дигән-

---

[72] Мөһаҗир – пәйгамбәр галәйһиссәлам заманында Мәдинә шәһәренә күченеп килгән мөселманнар.

[73] Әнсар – пәйгамбәр галәйһиссәлам заманында шәһәрләренә күченеп килгән мөселманнарга ярдәм итүче Мәдинә халкы.

нәре хәлдә, кайберләре өч дигәннәр иде. *(Ибне Каййим бу күләмдә тагын уналты каршылыклы һәм капма-каршы хөкемнәрне санаган. Без кыскартып, аларны калдырдык)*. Инде сез, әгәр боларның һәммәсенә ияргүне дөрес күрсәгез, ул вакытта теләсә кем теләсә кайсы сүзне алсын, ихтыярлы булырга һәм мәзһәбегезгә каршы киткән кешеләрне ачуланмаска кирәк. Әгәр боларның һәммәсенә ияргүне дөрес күрсәгез, ул вакытта бу хәдисне бозган һәм аңа каршылык кылган кеше иң элек үзегез буласыз. Шуңа күрә бу хәдиснең дөреслеге дә сезгә файда түгел, бәлки зарар.

Әгәр сез Габдулла бине Мәсгудьнең: «Әгәр дә сезнең берәрегез кемдер артыннан ияргергә теләсә, үлгән кешеләр артыннан иярсен, алар – Мөхәммәд сәхабәләре», – дигән сүзе белән дәлил эзләмәкче булсагыз, җавап: бу сүз дә сезнең файдагызга түгел, бәлки зарарыгызга дәлил, чөнки бу сүз исәннәргә ияргүдән тыйган иде, сез исә исәннәр һәм үлгәннәрегезнең һәммәсенә тәкълид кыласыз, моннан башка Ибне Мәсгудь аларга ияргү белән кушкан адәмнәр яхшы холыклы һәм өммәтнең иң гыйлемлеләре булган хөрмәтле сәхабәләр иделәр. Сез исә, аларга тәкълид урынына, алардан бик күп дәрәҗә ким булган фәлән-фәләннәргә тәкълид кылуда! Шул ук вакытта, ияргү дип әйтү – сәхабәләргә ияргү булган, алар кылган нәрсәнең үрнәген эшләү белән алар һичкемнең сүзен дәлилсез кабул итмәделәр, хәтта башка сәхабәләр кебек, Ибне Мәсгудь үзе дә тәкълидтән бик ачык [итеп] тыйган иде. Димәк, аның бу сүзендәге ияргүнең максаты, әлбәттә, сукырларча тәкълид түгел. Шуңа күрә сәхабәләр кебек, сезгә дә һичкемнең сүзен дәлилсез кабул итмәүлек тиеш. Әгәр сез әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең: «Сез минем сөннәтемне һәм миннән соң туры юлдан барган тугры хәлифәләр сөннәтен тотыгыз», һәм: «Миннән соң килгәннәрне үрнәк итеп алыгыз», – дигән сүзләре белән дәлил эзләүче булсагыз, бу хәдисләр дә сезнең файдага түгел, бәлки сезгә каршы. Чөнки алар арасында бер билгеле Сөннәт булган вакытта аңа каршы булган сүзгә тәкълид кылган һичкем юк иде, димәк, сезнең тәкълидегез аларның сөннәтенә каршы. Моннан башка әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам мәҗбүри ияргүдә тугры хәлифәләр сөннәтен үз

сөннәте белән чагыштырды. Димәк, боларның сөннәтен алу боларга сукырларча тәкълид түгел, бәлки ул хөрмәтле Рәсүлнең сүзенә иярү. Шул ук вакытта, сез бу хәдистә ачык искә алынган тугры хәлифәләргә түгел, бәлки шафигыйларга, хәнәфиләргә тәкълид кылуда, хәтта кайбер галимнәрегез болар каршысында тугры хәлифәләргә тәкълид дөрес түгел, дип әйтүдә сез! Димәк, сез бу сукырларча тәкълидләрегездә бу хәдисләргә муафыйк түгел, бәлки каршы. Бу хәдис фикер каршылыкларының күплеге вакытында әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам белән тугры хәлифәләрнең сөннәтләренә ябышырга кушкан хәлдә, сез фәләннең фикеренә һәм фәләннең мәзһәбенә ябышырга кушасыз. Бу хәдис эшләрнең яңалыкларыннан куркытып, һәрбер яңалык – бидгать һәм һәрбер бидгать – адашу дигән хәлдә, сез тәкълид итеп һәм фәләннең сүзен Китап белән Сөннәткә дә тәкъдим итеп, иң зур һәм иң кабәхәт бидгатьләргә төштегез. Бу хәдис эчендә: «Чынлыкта, сезнең арагызда миннән соң яшәүчеләр бик күп фикер каршылыклары күрәчәк», – дип төрле фикерле кешеләрне гаепләгән хәлдә, сез сукырларча тәкълидегез белән каршылыкларны күбәйттегез, динне аердыгыз, төрле-төрле фиркалар ясадыгыз. Үз юлыгызны мактарга һәм башкаларны орышырга тотындыгыз, китапларыбыз, динебез, пәйгамбәребез һәм Раббыбыз бер була торып, икенче мәзһәб сүзе белән гамәл дөрес түгел, дип, аларны бөтенләй ахыргы милләт кебек санадыгыз. Әгәр сез тәкълид һәм фанатизмны куеп, арабызда Китап һәм Сөннәтне хаким итсәгез һәм арабызда бертигез булган бу сүздә җыелсагыз һәм кайберләрегез кайберләрегезне Аллаһтан тыш тагын бер Хуҗа итеп тотмасагыз, билгеле бу низаглар азаер һәм бу кадәр бүлгәләнүләр калмас иде.

Дөрес, хәзрәти Гомәр Шөрәйхкә: «Аллаһ китабы белән, анда булмаса, Рәсүл сөннәте белән, анда да булмаса, изгеләр хөкем кылган нәрсә белән хөкем кыл!» – дип язды. Ләкин бу сүздә Китап белән Сөннәттә табылмаса гына, сәхабәләр сүзләренә һәм башкаларга баруның дөреслеген бик ачык аңлатканлыгыннан, кая тәкълиднең файдасына булсын, киресенчә, тәкълидкә каршы бик ачык дәлил. Менә сәхабәләрнең юлы – бу, хәзрәти Гомәрнең

бу сүзе шул хөрмәтле борынгы изгеләр юлын билгели. Соңра бер заман килде, кайберәүләр бер хәл булса, Китап белән Сөннәткә мөрәҗәгать итмичә һәм сәхабә сүзләренә күптән карамыйча, хәтта Китап белән Сөннәткә каршы булса да, фәлән-фәләннәрнең сүзләрен ала башладылар һәм кайберәүләр: «Әгәр мөфтигә бер-бер хәл күренсә, иң элек бу мөфти шул хәлдәге мөҗтәһидләр сүзләрен карар, әгәр каршылыклары булмаса, Китап белән Сөннәткә карамас, бәлки иҗмагны алып, шуның белән фәтва бирер. Әгәр каршылыклы булса, кайсы сүз дәлилгә якынрак, шуны алыр һәм хөкем кылыр», – дип аңлаттылар. Шул ук вакытта, бу сүз Мөгазның хәдисенә, Гомәрнең язуына, бөтен сәхабәләр сүзләренә һәм ачык Китап белән аңлаешлы Сөннәткә каршы. Болар адәмнәргә тәкъдир кылынган юлны күрсәткән хәлдә, бу мөкаллидләр һич мөмкин булмаган бер юлны күрсәтүдә. Чөнки мөҗтәһиднең Китап белән Сөннәттән максатны аңлавы бу хөкемгә көнчыгыш һәм көнбатыш галимнәре – һәммәсе бердәм фикердә булган, дип белүдән мең мәртәбә ансатрак. Ихтимал, бу хөкемдә каршылыклар булыр; ләкин мөҗтәһидкә ирешмәгән юк гыйлемне дәлил итеп тоту һич мөмкин түгел. Аллаһ Тәгалә ирешүе авыр булган мондый эшләр белән йөкләүдән, әлбәттә, пакь. Мөкаллидләр, мондый шикле бер нәрсәгә мөрәҗәгать иткәнче, бик ачык булган Китап белән Сөннәткә ябышсалар, билгеле, бик күп мәртәбә артык файда алырлар иде. Шул ук вакытта, боларның кайберләре иҗмаг төзеклегендә җыелган галимнәрнең заманы үтүен шарт итүдә ки, бу тәкъдирдә, ул заман узып та, һичбер ачык каршылык булмаганын белмичә торып, иҗмаг белән дәлил эзләү мөмкин түгел. Аллаһ Тәгалә колларына энә белән кое казу кебек мөшкел һәм бик шикле мондый бер юлны күрсәтүдән пакь. Менә мөселманнар Китап белән Сөннәт кебек ачык бер юлны куеп, бу чыга алмас юлга кергәннәре, булмаган иҗмагларны дәгъва кылганнары һәм шул билгесез иҗмаг белән шәригать текстларына каршы килүенә кадәр барганнары өчен бу кадәр фиркаларга аерылдылар. Шул ук вакытта, имам Мөхәммәд белән Бәшәр әл-Мәриси: «Иҗмагны дәгъва кылган адәм ялганчы,

ихтимал, адәмнәр каршы фикердәдер», – дигән. Кайберәүләр: «Каршы фикерне белмимен, дияргә мөмкин; әмма иҗмаг кылдылар, дияргә мөмкин түгел», – дип аңлатканнар. Ислам имамнарыннан бу мәгънәдә башка сүзләр дә сөйләнелгән, аларның һәммәсенең юлы Китап белән Сөннәтне иҗмагка тәкъдим итү иде. Имам Шафигый һәм Әбү Хатим әр-Рази дәлилне иң элек Китап, соңра нык Сөннәт, соңра иҗмаг һәм имамнарның бердәм фикере, дип, фәкыйһләр сүзләренә Китап белән Сөннәттән дәлил табылмаган вакытта гына баруны дөрес күргәннәр. Тәһарәттән тәяммүмгә[74] бару кебек ки, ул да тәһарәттән гаҗиз булган вакытта гына дөрес. Ләкин моны соңгылар аңламадылар, тәһарәттән гозерсез [сәбәпсез] фәкыйһләр сүзләренә күчтеләр, хәтта «Мөфтинең Аллаһ китабы һәм Рәсүл сөннәтендә карашы дөрес түгел, бәлки аңа тәкълид кылган кешенең сүзенә иярү тиешле. Хәтта бу сүз Китап, Сөннәт һәм сәхабәләр сүзләренә каршы да булса да. Әгәр мөфти куәтле дәлил таптым, [дип,] ышануы белән имамының сүзеннән күчсә, фәтва [бирү] вазыйфасыннан чыгарылыр» дип әйтүгә кадәр батырчылык иттеләр.

Әгәр: «Өмме вәләдне сатудан тыю һәм өч талак турысында сәхабәләр хәзрәти Гомәргә тәкълид кылдылар бит», – дисәгез, җавап: юк, тәкълид кылмадылар, бәлки кайберләре, Ибне Мәсгудь кебек, өмме вәләдне сату хакында, Ибне Габбас кебек, өч талак турысында хәзрәти Гомәргә каршы киттеләр һәм ияргәннәре дә сукырларча тәкълид белән түгел, бәлки үз иҗтиһадлары шуңа барганлык өчен иярделәр. Дөрес, хәзрәти Гомәр җитлеккән булганда Гамру бине Гас аңа кием алмаштырырга киңәш иткән иде, ул хәзрәт исә, әгәр алыштырсам, сөннәт булыр, дип баш тартты. Ләкин бу эшне Гомәр, Рәсүлдән күрмичә яки ишетмичә эшләмәс, дип, адәмнәрнең иярүеннән куркып, кире какты. Шуңа күрә бу вакыйгалардан Китап, Сөннәт алмашында да хәзрәти Гомәргә тәкълиднең дөреслеге һич аңлашылмый. Шул ук вакытта, бу тәкълид нык булган тәкъдирдә, хәзрәти Гомәргә тәкълидне исбатлый. Сез исә аннан һәм аның сүзеннән качып, фәлән-фәләннәрне асыл итеп тотуда!

---

[74] Тәяммүм – су булмаганда, туфрак тузаны белән тәһарәт алу.

Дөрес, хәзрәти Әбү [Мөнзир]нең: «Аңлашылмаган нәрсә булса – аңа ышан да белгән кешегә калдыр» дигән сүзе бар, чыннан да, бер адәм, Китап белән Сөннәттән тапмадымы һәм кыяска[75] көче җитмәдеме, аны белүчегә тапшыру тиешле, ләкин бу сүзнең ахыры, ягъни: «Сиңа нәрсә аңлашылды – шуның белән гамәл кыл. Аңлашылмаган нәрсә булса – аңа ышан да белгән кешегә калдыр», – дигән сүз дәлилләгәнчә, Сөннәт билгеле булган җирдә тәкълид дөрес түгел, бәлки Сөннәткә иярү тиешле. Сез исә бик ачык сөннәтләрне куеп, имамнарыгызга тәкълид кылуда! Шикле мәсьәләләрне дә, аларны иң галим кешеләргә тапшыру тиешле булган хәлдә, сез гыйлеме, наданлыгы мәгълүм булган үз кешеләрегезгә тапшыруда!

Дөрес, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең тормышында да хөрмәтле сәхабәләр фәтва бирерләр һәм фәтва сораучылар да аларга иярерләр иде. Ләкин боларның фәтваләре Аллаһ һәм Рәсүленең хөкемнәрен ирештерүдән гыйбарәт булган кебек, сораучылар да шәригать текстларына каршы була торып сукырларча тәкълид кылмаслар. Бәлки: «Рәсүл моны кушты һәм моннан тыйды», – дигән сүзләргә генә иярерләр, ягъни фәтва бирүчеләр ул Хәзрәт салләллаһү галәйһи вә сәлләмнән арадашчысыз ишеткән нәрсәне фәтва сораучылар арадашчысыз ишетерләр иде яисә фәтва бирүче бер фәтване биреп, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам аны аңлатыр [иде]. Әгәр ул фәтва Сөннәткә каршы исә, зина кылган гыйффәтлене ташлар атып үтерергә [дип] фәтва биргән адәмгә каршы чыккан кебек, аны кире кагар һәм тыяр иде. Кыскасы: нигез Китап белән Сөннәт иде. Сез исә болардан качасыз һәм фәләннәргә иярүдә.

Әгәр Аллаһ Тәгалә **«Нигә һәрбер фиркадан бер төркемне дин белемен өйрәнү һәм, шулай ук, сугыштан кайтканнарны вәгазьләү өчен җибәрмәскә»** [Коръән: 9:122] дип, аларның кисәтүләрен кабул итеп, тәкълид кылуны ваҗиб итте бит, дисәгез, әйтербез: бу аять җиһад өчен юкка чыкканнары вакытта иңгән кисәтүләр аятьләрен кабул [итү] турында. Сезнең һәм һәммәгез кебек, кешеләр фикерләрен вәхигә тәкъдим итү бу аятьтән һич

[75] Кыяс – чагыштыру, охшатуга нигезләнеп фикер йөртү.

аңлашылмый. Хәтта «тәфәккаһү» дип әйтү «дәлил белән белү» мәгънәсендә булганлыктан, бу аять үзе дәлилсез кисәтүләр – кисәтүләр түгеллек икәнлекне аңлатуда һәм тәкълиднең ялганына дәлил китерүдә. Чөнки сез, тәкълидне «бер кешене иярткүче тотып, аның сүзен дәлилсез булса да, кабул [итү] һәм башкаларныкын дәлилле булса да, кире кагу» мәгънәсендә алуда!

Дөрес, Ибне Зөбәер бабай белән аның абыйсы хакында сораганда, Әбү Бәкер сүзенә барып, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнән: «Әгәр дә мин җирдә яшәүчеләр арасында үзем өчен иң сөекле кеше итеп берәрсен алсам, ул Әбү Бәкер булыр иде», – дигән сүзен сөйләде. Ләкин Ибне Зөбәер аңа сукырларча тәкълид белән иярмәде, бәлки дәлиле куәтле булганы өчен аның сүзенә барды һәм Сиддыйкның [Әбү Бәкернең] күпвакытта сүзе туры чыкканлыкка ишарәт өчен бу хәдисне сөйләде. Шул ук вакытта, Ибне Зөбәернең хата ихтималы булганлыктан, аның бу сүзе тәкълид турысында булса да, аны дәлил итеп тоту дөрес түгел. Аллаһ Тәгаләнең шаһит сүзен кабул итәргә кушуы тәкълидкә дәлил булырга шулай ук дөрес түгел. Чөнки: «Шаһитнең шәһадәтен кабул итегез», – дип хакимнәргә Аллаһ Тәгалә кушкан кебек, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам үзе дә шаһитләр сүзе белән хөкем итте.

Димәк, без шаһитнең сүзен, тик ул шәһадәт биргән өчен түгел, бәлки Аллаһ һәм Рәсүле кушкан өчен кабул итәбез. Әмма сез имамыгызның сүзен шәригать Хуҗасы кушкан өчен түгел, бәлки ул әйткән өчен изге санныйсыз. Шуңа күрә бу мәсьәләне Китап һәм Сөннәттән качып, кешеләр фикеренә тәкълид турысында дәлил итеп тотуыгыз бик гаҗәп һәм бик зур ахмаклык. Шәригатьнең: «Бүлүче һәм бәяләүче сүзләрен, сукырның кыйблада һәм [намаз вакыты] кергән вакытта башкаларга ияреүен, адәмнәрнең [намаз вакыты] кергән вакытта һәм авыз ачу белән уразада мөәзингә карауларын, тәрҗемәи хәлләр китапларында да «тәгъдил вә җәрех»тә[76] ияреүне, бүләктә, ир янына хатынын кертүдә һәм хәез каны туктавында бер хатынның сүзенә

[76] Тәгъдил һәм җәрех – кемнең дә булса хәдис тапшырырга лаеклымы, юкмы икәнен тикшерү.

ышануны» дөрес дип күрүне тәкълидкә дәлил итеп тотуыгыз да аннан ким ахмаклык түгел. Чөнки болар хисләре белән сизеп, билгеле, белгән нәрсәләрдән хәбәр бирәләр. Шәригать Хуҗасы исә дөреслеге һәм гаделлеге билгеле булган хәбәр итүченең хәбәрен кабул итәргә куша. Димәк, боларга иярү – Аллаһ һәм Рәсүленең әмерләренә муафыйк һәм гыйлемгә ияру. Сез исә тик уйлаудан хәбәр биргән бер кешегә иярүдә һәм Китап белән Сөннәткә каршы булса да, аның сүзен кабул итүдә! Һәм дә яһүдидән яки нәсарадан яисә имансыздан итләрне, киемнәрне һәм тәгамнәрне сатып алган вакытта, боларның сүзе җитәрлек булып, хәләллек һәм хәләллек сәбәпләрен тикшермәвебездә сукырларча тәкълид түгел, бәлки Аллаһның әмере һәм хәзрәти Гайшәнең: «Әй, галәмнең Рәсүле! Кайбрәүләр ит китерә, бисмилла әйтеп суелганмы, юкмы – мәгълүм түгел, ашыйкмы?» – дигән сүзенә каршы ул Хәзрәт салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең: «Сез «бисмилла» әйтегез дә ашагыз», – дигән сүзе белән гамәл. Шул ук вакытта, әгәр сезнең бу дәлил китерүләрегез дөрес булса, суелган корбаннарыгыз белән ашамлыкларыгыз да көферлек, имансызлык белән кан киселүендә кяфергә, имансызга тәкълид дөрес булган кебек, боларга дин турысында да тәкълид дөрес булырга тиеш. Димәк, сез бу бозык юлыгызны куегыз, кешеләр сүзләренә тәкълидне куеп, Аллаһ китабы һәм Аллаһ Рәсүленең сөннәтенә кайтыгыз! Менә шул вакыт үзегез дә бәхетле булырсыз, өммәтне дә бәхеткә ирештерерсез!

Әгәр сез: «Әгәр адәмнәр һәммәсе иҗтиһад белән йөкләнгән булсалар, колларның яхшылыклары югалыр һәм эшләр дә, сәүдәләр дә ташландык хәлдә калыр иде. Моңа исә шәригать буенча да, акыл буенча да юл юк бит», – дисәгез, җавап: һәркемгә ваҗиб булган нәрсә – үзеңә хас булган хөкемнәрне генә белү. Бу хөкемнәр исә фәкать хәзрәти Рәсүл китергән дини гыйлемнәрдән гыйбарәт булганлыктан, колларның яхшылыклары югалырлык һәм эшләр, сәүдәләр дә ташландык хәлдә калырлык күп түгел, бәлки хөкемнәр нигезләрендә фәкать биш йөз хәдис микъдары, бик аз һәм бик җиңел. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә **«Коръәнне укырга һәм аңларга җиңел иттек, аның**

**белән вәгазьләнеп гамәл кылучы бармы?»** [Коръән: 54:17] дип, исламның җиңеллеген бәян иткән кебек, хөрмәтле сәхабәләр дә һәрбер яхшылыкларын, тормышларын игенлек, мал-туар, сату һәм базар эшләрен – һәммәсен карый торып, үзләренә кирәкле дин эшләренең барысын да бик ачык белгәннәр.

Әмма соңра бер заман килде, диндә фарыз исеме белән төрле бидгатьләр чыкты, нигез булган нәрсәләрдә, тармакларында адашулар күбәйде дә ислам танылмас, аңлашылмас һәм, гомер буенча өйрәнеп тә, беленмәс бер хәлгә килде. Менә болар һәрвакыт артып килде һәм һаман артуда; әмма дин нигезе һичбер вакытта артачак та, кимеячәк тә түгел. Без бу адашуларны түгел, бәлки исламны белергә әмер ителгәнбез, әгәр шулай икән, һәрбер мөселман Рәсүл хәбәрләрен расларга һәм Аллаһ әмерләренә буйсынырга йөкләнгән һәм, әгәр шулай икән, бу хәбәрләрне, әмерләрне белмичә буйсыну мөмкин түгел. Димәк, боларның һәммәсен белү һәрбер мөселманга вәҗиб. Дин һәм дөньябызны саклау һәм хәлләребезне яхшырту, бу нәрсәләрдә тоткарлык һәм боларны оныту һәрбер эшебезне бозык иткәнлектән, Аллаһ аларны безгә мәрхәмәт-фарыз иткән. Бер мәмләкәт, бер шәһәр түрәләренең, ияләренең яхшылыгы гыйлем сәбәпле һәм харап булуы ияләренең бозыклыгы, наданлык сәбәпле. Гыйлемсез адәм хайван кебек, аның гыйлемгә ихтыяҗы ашау һәм эчүгә ихтыяҗдан күбрәк. Кеше, ашау белән эчүгә көнгә фәкать ике-өч мәртәбә мохтаҗ булган хәлдә, гыйлемгә һәр сәгать һәм һәр минут мохтаҗ булуда. Галим адәмнең һичбер дини һәм дөньяви яхшылыгы югалмас, һичбер эше һәм сәүдәсе тукталмас, бәлки боларның юкка чыгуы һәм Аллаһ әмерләренең дә игътибардан төшүе дөреслеккә дә ирешә, хата да кыла торган бер кешенең һәрбер сүзенә сукырларча тәкълид кылуда. Димәк, Аллаһ Тәгаләнең безне тәкълид белән түгел, бәлки карау һәм дәлил китерергә йөкләве безгә шәфкать һәм мәрхәмәтеннән. Әгәр без тәкълид белән йөкләнгән булсак, дөнья һәм ахирәтнең яхшы нәрсәләреннән һичберсе калмас, һәммәсе юкка чыгар, бетәр иде. Чөнки ислам бөтен көнчыгыш белән көнбатышны тутырган һәм мөфтиләр, фәкыйһләр бик артык күбәйгән. Әгәр без боларның

һәммәсенә тәкълид белән йөкләнгән булсак, боларны табып бетерү мөмкин булмаганлыктан, башка бер нәрсәне хәләл дә, хәрам да, важиб та, кимчелекле дә итү тиеш була. Әгәр болар арасында иң галименә тәкълид белән йөкләнгән булсак, тәкълид шартлары җыелган, иң галимне сайлаудан Китап белән Сөннәт дәлилләгән нәрсәне белү меңнәрчә мәртәбә ансатрак. Мондый шартларны җыючы бер кешене, аеруча бу кадәр мөҗтәһидләр арасыннан табу сукыр тавык кебек булган мөкаллидкә түгел, тирән белемле кешегә дә мөмкин түгел. Әгәр без теләсә кайсысына тәкълид белән йөкләнгән булсак, ул вакытта ислам Аллаһ әмере һәм аның Рәсүле әмере түгел, бәлки безнең теләк һәм шәһвәтебезгә иярүче булып чыга ки, моны әйтергә сез үзегез дә риза булачак түгел. Шулай була торып, үзегез аять һәм хәдисләрдән баш тартуда һәм кәефегезгә карап хөкем кылуда сез! Әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам Гукбә бине әл-Харискә: «Мин сине дә, хатыныңны да имездем», – дигән хатынның сүзенә ышанырга һәм хатынын аерырга кушкан хәлдә, сез ул хәдистән баш тартуда һәм мондый бер хатынны иренә хәләл дип фәтва бирүдә. Аның өстенә, үзегез бу хәдис белән тәкълидкә дәлил эзләп, әһәмиятле бер хәдисне ышанычлы да, ышанычсыз да итәсез! Шул ук вакытта, бу эшнең тәкълид булмыйча, шаһитнең шәһадәте кебек, хис әмереннән хәбәрнең кабул булуы һәм Гукбәнең дә, хатынын һичкемгә ияреп түгел, бәлки фәкать әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең сүзе буенча аеруы бик ачык мәгълүм булган бер мәсьәлә.

Сез Мөхәммәд бине Хәсәннең: «Галимнең үз ишенә тәкълиде дөрес булмаса да, үзеннән галимгә тәкълиде дөрес», һәм Шафигыйның: «Мин монда Гомәргә, монда Госманга һәм монысында Гатага тәкълид кылдым», – дигән сүзләрен дә сөйлисез. «Шуның белән имамнар да тәкълидне дөрес күргәннәр бит», – дип дәлил эзлисез. Әмма сәхабәләр һәм табигыйннарның үзләренә һәм башкаларга тәкълид кылуны гаепләү һәм тыю турында сөйләнгән хисапсыз сүзләренә һич илтифат итмисез. Бу исемнәрен искә алганыгыз; Мөхәммәд бине Хәсән белән Шафигыйның тәкълидне бик күп инкяр итүләрен, дәлилдән

башка нәрсәгә иярүне беркайчан да кабул итмәүләрен, Китап белән Сөннәттән башка нәрсәгә һич өндәмәгәннәрен; Әбү Хәнифә Мөхәммәд белән Әбү Йосыфтан гыйлемлерәк булган хәлдә, боларның аңа каршы булуларын һәм аның кебек, үзләренең дә: «Кайдан алынганлыгын белмичә безнең сүзебез белән фәтва бирмәгез!» – дигәннәрен; Шафигыйның: «Сәхабәләрнең акыллары күп һәм иҗтиһад гыйлеме, диндарлыклары бездән өстен», – дип [әйтеп] торып, аларга бик күп җирдә каршылыкта булуын хәтерегезгә дә китермисез. «Имамнарның башкага тәкълидләре дөрес түгел» дип әйтүегез һәм: «Шафигыйның фарызларда Зәедкә буйсынуын иҗтиһадның иҗтиһадка туры килүе турысыннан», – дип ялгыш аңлаткан хәлдә, үзегез, бу дәрәҗәдә Шафигыйны Гомәр, Госман, Гатага мөкаллид ясап, бик гаҗәп бер каршылыкка төшәсез. Сезнең бик зур ахмаклыгыгыздан, Шафигый мөҗтәһид була торып, тәкълид кылып, бу өч затка үзегез мөкаллид булган хәлдә дә, тәкълидегезне дөрес күрмәүдә, билгеле Шафигыйны имам [итеп] тотуда, Шафигый боларга каршы булган җирләрдә, шиксез, аларның сүзләрен кире кагуда һәм үзегез: «Шафигыйга тәкълид кылабыз», – дип [әйтеп] торып, шушылай аңа каршы баруда! Шул ук вакытта, бу сүзләр бу имамнардан ышанычлы булган тәкъдирдә, болар Аллаһ белән Рәсүленнән бер нәрсә дә белә алмыйча һәм төрле сүзләр һич сөйләмичә, бик аз мәсьәләләрдә генә тәкълид кылырлар, үзләреннән галим санаган кайбер адәмнең сүзен кабул итәрләр, шушылай зарурлык вакытында тәкълиднең дөреслеген күрсәтерләр иде. Сез исә бу юлны бөтенләй куйдыгыз, Китап белән Сөннәттән дәлилләр күренә торып, тәкълидне ихтыяр иттегез, гүя чалынган корбан урынына үләксәне малыгыз башы кебек кабул иттегез! Төрле-төрле бозык аңлатулар белән максатыгызны алга җибәрергә тырыштыгыз! Хәтта имам Шафигыйның: «Сәхабәләр фикере безнең өчен үз фикеребездән хәерле», – дигән сүзе белән дәлил эзләп «Димәк, имамнар фикере дә безнең өчен үз фикеребездән хәерлерәк» дип әйтүгә кадәр батырчылык иттегез! Үзегез исә сәхабәләргә тәкълид урынына, Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали сүзләрен ташлап, Шафигыйга ияреп, аның

бу сүзенә каршы киттегез, имамнарның үзләренә тәкълидтән тыеп, сәхабәләр сүзләре белән гамәл кылырга кушканнарын бөтенләй оныттыгыз, һичбер мөселман алдында бу имамнарның сүзләре дәлилсез кабул ителмәүне хәтерегезгә дә китермәдегез, сәхабәләр белән имамнарыгыз арасында бертигез чагыштыру ясадыгыз! Шул ук вакытта, сәхабәләр дин турысында гыйлемлерәк, фикыһны белү белән өстенрәк иделәр, вәхине күрделәр, Рәсүлдән арадашчысыз кабул итеп алдылар, Китап белән Сөннәткә, берәр мөшкел [хәл] чыкса, ул хөрмәтле Хәзрәткә [Рәсүлгә] мөрәҗәгать иттеләр. Шуның өчен дә ул Хәзрәт саллаллаһү галәйһи вә сәлләм: «Кешеләрнең иң яхшылары минем замандашларым, аннан соң минем заманыма якын булган гасырда, аннары аңа якын булган гасырда. Соңыннан шундый кешеләр килер: аларның шаһитлыклары антларыннан, ә антлары шаһитлыкларыннан алда йөрер», «Минем сәхабәләремне хурламагыз, әгәр дә сезнең берәрегез Аллаһ юлында Өхед тавы кадәр алтынны сәдака итсә дә, аларның берсе, хәтта яртысы кадәр дә дәрәҗәгә ирешмәс», – дигән, тугры хәлифәләр сөннәтенә ияргә әмер иткән; Ибне Мәсгудкә гыйлем белән һәм Ибне Габбаска: Я Аллаһ, аны динне аңлаучы ит һәм аны Коръәнне тәфсир кылырга өйрәт», – дип дога кылган; «Мин сезгә Ибне Мәсгуд риза булган нәрсәдән риза» дигәне кебек, Әбү Бәкер белән Гомәргә буйсынырга да кушкан; Гомәрнең куышында бер савыттан эчеп, тәмам туйганын, гыйлем белән йөргәнен һәм: «Аллаһ Тәгалә хаклыкны Гомәр телендә кылды, әгәр миннән соң пәйгамбәр булса, Гомәр булыр иде», – дип әйткән. Димәк, эш болай булганда, сәхабәләргә тәкълиднең дөреслегеннән соңгы имамнарга тәкълидеңнең дөрес булуы ничек тиешле булсын? Шул ук вакытта, Шафигый үзе сәхабәләргә бик күп җирдә каршы булып киткән иде. Димәк, аларга каршы китү дөрес булгач, имамнарга каршы китү күптән дөрес булырга тиеш.

Әгәр сез: «Һәрбер эш һәм һәрбер гыйлемдә шәкерт мөгаллимгә тәкълид кыла, Аллаһ Тәгалә моны кешедә тумыштан ук беркеткән», – дисәгез, җавап: ләкин моннан Аллаһ динендә тәкълиднең, ияртүче сүзен дәлилсез кабул итүнең һәм аны

үзеннән гыйлемлерәк сүзенә дә тәкъдим итүнең дөреслеге һич тиешле түгел. Аллаһ Тәгалә колларына һәрбер нәрсә турында дәлил сорауны тумыштан ук сеңдергән өчен, һичбер кеше дәлилсез сүзне кабул итмәс. Шуның өчен дә Рәсүлләр кешеләрнең иң эчкерсез, иң галим һәм иң камилләре була; өммәтләре дә аларны кешеләрнең иң эчкерсезе дип танып, Аллаһ Тәгалә аларның эчкерсезлегенә ачык аятьләр һәм ышандырырлык дәлилләр китергән һәм дәгъва кылучыларын дәлил белән ныгытканнан соң, нәтиҗәдә, аларга буйсынырга әмер иткән. Димәк, болар вәхи белән куәтләнгән булган хәлдә, сүзләре дәлилсез кабул ителмәгәч, башкаларның сүзләре дәлилсез беренче юл белән кабул ителмәскә тиеш, дәлилгә буйсыну һәм дәлил иясенең сүзен кабул [итү] – адәм баласында табигый эш. Әгәр кеше үз хәленә куелса, һичкемгә тарафдарлык итмәсә, ул вакытта дәгъва кылучы ачык дәлилләр белән ныгытылган адәмнең сүзен кабул итмичә калмый. Ләкин күп кеше бер фикергә һәм бер шәхси мәнфәгатькә хезмәт иткән өчен, шуңа каршы [булган] исбатлы бер сүзне дә ташлауда һәм һәрбер җаваплылыкны өсләренә алуда.

Әгәр сез: «Аллаһ Тәгалә, төрле гәүдә кебек, зиһеннәрне дә төрлечә бар итте, димәк, һәркемне һәрбер мәсьәләдә хаклыкны дәлиле белән белергә көчләмәү Аллаһ Тәгаләнең хикмәт һәм гаделлегенә муафыйк түгел бит», – дисәгез, җавап: бик дөрес, без үзебез дә: «Аллаһ Тәгалә дини мәсьәләләрнең билгеле булганнарын һәм билгеле булмаганнарын һәркемгә дәлиле белән белүне мәҗбүри кылган», – дип әйтмибез. Без фәкать сезнең имамнарыгызны ияртүче [итеп] тотуны; аларның һәрбер фәтвасен шәригать текстлары дәрәҗәсендә, бәлки аннан элек кылуны; шәригать хөкемнәрен Китап белән Сөннәттән алмыйча, тик аларның сүзләреннән алуны; һич белмичә, «Аларның һәрбер сүзе Китап белән Сөннәттән алынган» дип шәһадәт бирүне; боларга каршы: «Ни кадәр галим һәм хөрмәтле булса да, аларның сүзе Китап белән Сөннәттән алынмаган», – дип, сукырларча диварга сугуны инкяр итәбез. Сезнең кебек: «Ислам дине кешеләр фикерләренә һәм кешеләрнең адашуларына нигез-

ләнгән», – димибез, бәлки әйтәбез ки: «Аллаһ Тәгалә колларына булдыра алганча тәкъвалык кылырга кушты». Тәкъвалык – эшне белеп, соңра аның нәтиҗәсе буенча гамәл кылу. Димәк, һәрбер адәм иң элек исламның әмерләрен һәм тыюларын белеп, соңра Аллаһ һәм рәсүленә буйсынырга тиеш. Аллаһ Тәгалә күтәрә алмаслык нәрсә йөкләмәгәнлектән һәм хәзрәти Рәсүлдән соң һичбер дини әмер яшерен калмаган бер адәм дә табылмаганлыктан, Ул Хакимнәрнең Хакиме [Аллаһ] һәрбер гыйлем иясенә булдыра алганча тырышканнарыннан соң, хаталансалар, болай бер савап билгеләгән. Әгәр бер адәм үз фикерен йөртүдән бөтенләй гаҗиз булса, ул вакытта теләсә нинди ышанычлы шәригать галименә мөрәҗәгать итәр һәм мәсьәләне аннан дәлиле белән алыр, сезнең кебек фәкать бер имамны ияртүче итеп тотмас һәм аның һәрбер сүзенә сукырларча ияреп, вәхи урыныннан баш тартмас.

Сез тәкълидне имам артына баскан кешенең намазда имамга [оюы] һәм җәмәгатьнең хаҗда юл күрсәтүчегә буйсынуы белән чагыштырасыз. Шул ук вакытта, имам артына баскан кеше намазны имам укысын-укымасын һәм хаҗда җәмәгатьне юл күрсәтүче озатсын-озатмасын, җиренә җиткезәчәкләр. Боларның намазлары, хаҗлары имам һәм юл күрсәтүче өчен түгел, бәлки Аллаһ әмерләренә буйсыну. Шуңа күрә моны тәкълид димибез һәм сезнең имамыгыз сүзенә, Рәсүл әйткән өчен түгел, бәлки ул [имам] әйткән өчен иярүегезне моның [белән] чагыштыру мөмкин түгел. Әгәр сез моны тәкълид [дип] санасагыз, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам Габдрахман бине Гауфка оеп намаз укыган һәм фарыз булган һиҗрәт өчен бер юл күрсәтүче тоткан. Димәк, ул Хәзрәт [Мөхәммәд] салләллаһү галәйһи вә сәлләм дә мөкаллид булса кирәк, сез бу нәтиҗәне әйтергә, табигый, үзегез дә риза булмаячаксыз! Бер галим бер наданга оеп намаз укый һәм намазы шәригать буенча дөрес хисаплана. Ләкин сез үзегез дә [моңа] кергән булган хәлдә, галимнең наданга тәкълиден дөрес күргән дөньяда һичкем юк. Шул ук вакытта, имамга оючы кеше белән хаҗилар имам эшләгән нәрсәләрне тулысынча эшлиләр һәм, болай эшләмәгән тәкъдирдә, иярүче түгел дип

хисаплananалар. Димәк, әгәр сез тәкълидне моның белән чагыштырсагыз, ул вакытта сез дә имамнарыгызга алар китергән дәлилләрне китерүдә дә, кайда гына булса да, дәлилне тәкъдим итүдә дә иярергә һәм мөҗтәһидләрнең асылы булып торган бу юлдан чыксагыз, аларга ияру булмаганлыкны бик ачык белергә [тиеш]. Шуның өчен үзегезгә зарарлы [булган] мондый чагыштырулардан ваз кичәчәксез!

Әгәр сез: «Рәсүл сәхабәләре ачкан [яулап алган] шәһәрнең яңа мөселманнарына фәтва бирерләр, ләкин бу фәтвадә хаклыкны дәлилдән эзләгез, димәсләр иде», – дисәгез, җавап: сәхабәләр аларга үз фикерләре белән фәтва бирмәделәр, бәлки фәкать әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам әйткән әмерләрне, ул хөрмәтле Хәзрәт эшләгән нәрсәләрне ирештерделәр һәм: «Моны безгә пәйгамбәребез бурыч итте, безнең дә сезгә бурычыбыз бу», – диделәр. Димәк, боларның ирештергән нәрсәләре Коръән белән Рәсүл сөннәтеннән гыйбарәт, бу да үзе дәлил һәм хөкем. Шуңа күрә бу хакыйкатькә сезнең бу замандагы тәкълидегезне чагыштыру, хәтта якын китерү болай мөмкин түгел. Чөнки сез, мөкаллидләр, бүген үз ияртүчегезнең сүзен алып, аннан башка һәрбер дәлил һәм һәрбер хакыйкатьне инкяр итүдә; соңгы галимнәрдән алып элеккеләренең һәрбер сүзләрен кире кагуда; хәтта Шафигый һәм Әбү Хәнифәгә ияруләрегездә аларның сүзләренә һәркемнән артык карышуда; һәрбер гасырда якыннан якын булган сүзе белән фәтва бирүдә һәм заман ни кадәр озак китсә, элекке сүзне шул кадәр ташлауда. Шуның өчен элекке имамнарның китапларын китапханәләрегездә һич тә булдырмауда сез! Шул ук вакытта, сәхабәләр, табигыйннар һәм элекке замандагы башка изгеләр һичберсе «Сез үзегезгә үз арагыздан бер ияртүче тотыгыз да, башкаларга илтифат итмәгез! Китаптан, Сөннәттән хөкем алып маташмагыз! Әгәр Аллаһтан һәм Рәсүленнән риваять кылынган нәрсә ияртүчегезнең сүзенә каршы булса, ул риваятькә карамагыз! Һаман ияртүчегез сүзен алыгыз!» дип әйтмәгәннәрен сез үзегез дә бик ачык белүдә!

Әгәр сез: «Тәкълид, шәригать тә тәкъдирнең тиешле булган нәрсәләреннән, шул кадәр ки, югарыдагы кайбер хөкемнәр дә

узган кебек, тәкълидне инкяр итүләр дә аңа барырга мәҗбүр», – дисәгез, әйтермен: ихтимал, сезнең башыгызга төшкән бу инкяр ителгән һәм хурланган тәкълид тәкъдирнең тиешле эшләреннән булса булыр. Ләкин без моның шәригатьнең тиешле эшләреннән булмыйча, шәригать буенча бозыклык һәм ялган [икәнен] бик күп дәлилләр белән исбатладык. Әгәр сез моны да тәкълид дип әйтсәгез, без инкяр иткән тәкълид бу мәгънә белән тәкълид түгел, бәлки билгеле бер адәмнең һәрбер сүзенә, дәлилгә каршы булса да, сукырларча ышану мәгънәсендә булган тәкълид. Моның исә, кая үзе, киресенчә, ялган, шәригатьнең тиешле эшләреннән булмавы – бик ачык мәгълүм булган бер мәсьәлә. Әгәр тәкълид шәригатьнең тиешле эшләреннән булса, иҗтиһадта дәлилләр китерү аңа капма-каршы булганлыктан, ике капма-каршы [нәрсәдән] берсенең дөреслеге икенчесенең дөрес булмавын таләп иткәнлектән, тәкълид урынына дәлил китерү һәм дәлилгә иярү дөрес булмас иде. Әгәр берсе башкасына капма-каршы булган тәкълид белән дәлил китерүнең бер мәсьәләдә ике кеше тарафыннан яисә бер кешедән ике вакытта җыелулары дөрес, дисәгез, ул вакытта, әгәр бу икесе тигез булсалар, сезгә: «Иҗтиһад заманы үтмәде», – дигән кешеләрне сүгәргә урын калмый.

Әгәр иҗтиһад яхшырак булса, сезнең тәкълидкә күчүегез – яхшыракны куеп, яхшыга бару була. Әгәр тәкълид яхшырак икән, иң ахмак бер мөкаллид иң яхшы бер дәлилләүчедән Аллаһ каршында саваплы һәм дәрәҗәлерәк булырга тиеш. Шул ук вакытта, сезнеңчә, иҗтиһад юлы киселгән, беткән булгач, бу кабатлауга хәҗәт тә юк, бәлки тәкълидтән дәлилләүгә, иҗтиһадка күчү – начарлык һәм бик зур гөнаһ. Димәк ки, бу заманда гыйлем юлы киселгән, Аллаһ дәлиле беткән һәм җир йөзендә Аллаһ дәлилләрен белгән [кеше] калмаган. Моның исә бозыклыгы һәм ялганы – көн кебек мәгълүм булган бер нәрсә. Аны әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең: «Минем өммәтемнән бер төркем ачыктан-ачык хаклыкта булудан туктамас, үзләренә каршы чыгучылар аларга зыян итмәс. Кыямәт көненә хәтле шулай булыр», – дигән сүзе дә раслый.

Чөнки бу төркем – хаклыкны белүче бер төркем. Сукыр тәкълидчеләр үз шәһадәтләре буенча да гыйлем ияләреннән түгел. Кыскасы, шәригатьнең тиешле эшләреннән булган ияру – шәригать текстларын кешеләр фикеренә тәкъдим иту һәм гыйльми низаг кылган мәсьәләләрне Китап белән Сөннәткә кайтару. Әмма кешеләр фикерләренең шәригать текстларыннан булуы һәм аны Китап белән Сөннәткә тәкъдим иту – анысы кая диннән булсын, киресенчә, динне хурлау. Дөрес, без ялган тәкълидкә дәлил итеп китергән әсәрле дәлилне үзләрендә тотучылардан, риваять кылучылардан алдык. Ләкин галим – риваять кылучыга, хаким – шаһиткә мөкаллид түгел, бәлки дөрес хәбәрне һәм гадел шәһадәтне дәлил иткән Аллаһ әмере Һәм Рәсүл әмеренә ияру. Сез тәмам ахмак һәм наданлыгыгыздан аерма дәрәҗәсен һич карамыйча, тәкълид исемендә уртаклыкны күрәсез дә, тәкълиднең дөрес төре белән бозык төренә дәлил китерәсез! Шушылай итеп иң начар адәмнәрнең юлы булган хәйлә белән алдауны өстегезгә йөклисез! Шул ук вакытта, әгәр галимнең риваять кылучыга ияруе тәкълид булса,сәхабәләрдән соң җир йөзендәге һәркем, хәтта икенче сәхабәләрнең риваятьләренә ияргән мәсьәләләрдә сәхабәләр үзләре дә мөкаллид саналырга тиешле булыр иде. Әгәр хаким шаһиткә мөкаллид [булып] хисапланса, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам дә шаһит сүзе буенча хөкем кылганлыктан, ул Хәзрәт саллаллаһү галәйһи вә сәлләм дә (Аллаһ сакласын) сезнең кебек мөкаллид [булып] хисапланыр иде. Бу кабәхәт сүзне исә, уйлавымча, сез үзегез дә әйтергә риза булачак түгел!

Ихтимал, сез әйтерсез: «Сез тәкълидне тыйдыгыз! Хаклыкны эзләүдә карауны һәм дәлил китерүне мәҗбүри иттегез! Иярткүче фәтвасендә хата кылган булыр да, мөкаллид шуңа ияреп, хатага төшәр, дип курыкканыгыз өчен. Шул ук вакытта, бер нәрсә сатып алачак кешенең үзеннән артык белгән үгетләүче сүзе белән алган вакыттагы дөреслеге үзе генә карап алган вакыттагы дөреслектән якынрак булган кебек, бер кешенең үзеннән гыйлемлерәк булган бер имамга тәкълидендәге дөрес-

леге дә үз иҗтиһадындагы дөреслегеннән якынрак». Без моңа җавапта әйтәбез ки: без тәкълидне, фәкать хатадан куркып түгел, бәлки Аллаһ һәм Рәсүленә ияреп, тыябыз. Чөнки Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримендә тәкълид ияләрен шелтәләп гаепләде, Китап һәм Сөннәтне дәлил [итеп] тотарга, өммәт низаглашкан нәрсәләрне Аллаһка һәм Рәсүленә кайтарырга кушты, хөкем тик Аллаһныкы, дип хәбәр бирде, Аллаһ һәм Рәсүленнән башка хуҗалар һәм әүлияләр тотып, аларның хәләл дигәннәрен хәләл, хәрам дигәннәрен хәрам кылудан тыйды, Рәсүленә иңгән нәрсәләрне белмәгән адәмнәрне надан көтү дәрәҗәсендә диде, җитәкчеләргә дә алар Рәсүл әмеренә иргән һәм Рәсүл шәригатен хәбәр итүче булган вакытта гына иярергә кушты, тарткалашу барлыкка килгән тәкъдирдә: «Хәзрәти Рәсүлне хаким итмичә һәм кылган хөкеменнән тынычланмыйча торып, һичкем мөэмин булмас», – дип ант итте. Ул [Аллаһ] Хәзрәтнең [пәйгамбәр галәйһиссәламнең] хөкеменә каршы булган хөкемгә ияр үдән һәм аннан башканы хаким итүдән бик күп куркытты.

Менә бу хөкемнәр ул хөрмәтле Рәсүлнең тормышында нык булган кебек, үлеменнән соң да нык. Бу хөкемнәргә ияру һәм ул хөрмәтле Рәсүлне хаким итү [үзе] исән чагында мәҗбүри булган кебек, үлеменнән соң да мәҗбүри. Чөнки бу заманда ул Рәсүл Мостафаның хөрмәтле шәхесе булмаса да, аның туры юлы булган Китап белән Сөннәт безнең арабызда мәңге сәламәт. Аллаһ Тәгалә ислам нигезе булган Коръәнне үзгәрүсез саклады, «Бу Рәсүлдән соң башка рәсүл килмәс, шәригате гамәлдән чыкмас», – диде, Рәсүл әмеренә каршы чыккан адәмне фетнә һәм каты газап белән куркытты. Аллаһ белән Рәсүле хөкем кылган бер эштә мөэминнәргә һичбер ихтыяр юклыгын бик ачык бәян итте һәм моны һичбер заман белән чикләмичә, Коръән белән Сөннәткә ияру сәхабәләргә мәҗбүри булган кебек, безгә дә мәҗбүри булуын аңлатты. Димәк, безгә Аллаһ белән Рәсүленең хөкеменә һәм тәкъдиренә ияру, билгеле, мәҗбүри. Моны сез мөкаллидләр дә инкяр итәчәк түгел! Димәк, билгеле бер имамга тәкълид тиешле булыр шул вакытта: әгәр аның һәрбер хөкеме

Аллаһ белән Рәсүленең хөкеменә туры килсә. Шул ук вакытта, мондый бер адәм имамнар арасында түгел, бөтен сәхабәләр арасында да юк иде. Әбү Бәкер шәһид өчен дият[77] барлыгын белмәгән иде, Гомәр сүзенә кайтты. Гомәр «син дә мәет, алар да мәет» мәгънәсендәге аятьтән игътибарсыз булган иде, Әбү Бәкер сүзенә кайтты. Госман авырлы булуның иң аз вакытын белмәгән иде, Ибне Габбас сүзенә кайтты. Гали ир баланың шәһадәте атасы файдасына кабул ителмәүне хәтерләмәгән иде, Шөрәйх сүзенә кайтты. Моның кебек, башта белмичә фәтва биргән хәлдә, соңра белгән адәмнәрнең сүзләренә кайтулар сәхабәләр арасында бик күп, санап кына бетерерлек түгел.

Ибне Каййим бу күләмдә тагын кайбер мәсьәләләрне искә алса да, кыскартып калдырдык.

Инде аңлашылды: һәрбер хөкеме Аллаһ белән Рәсүленең хөкеменә һәм карарына туры килгән бер адәм сәхабәләр арасында да булмаган. Димәк, сезнең имамнарыгызга да Аллаһ белән Рәсүленең карарларыннан кайберләренең билгеле булмыйча калуы табигый. Менә шушы сурәттә, ягъни Аллаһ әмере һәм Рәсүл әмере имамыгызга билгесез калып, ялгыш фәтва биргән вакытта, я аның фәтвасен кире кагу, кабул итү сезнең ихтыярыгызда калыр, яисә ихтыярыгыз киселеп, Аллаһ һәм Рәсүле карар кылган нәрсәнең үзе белән гамәл кылумы важиб булыр? Менә бу бер сорау, сезнең аңа бер канәгатьләндерерлек җавап та юк. Шул ук вакытта, сезнең бәхәсегездә сез искә алган бер кешенең үзеннән гыйлемлерәк булган бер имамга тәкълидендәге дөреслеге үз иҗтиһадындагы дөреслегеннән якынрак, дигән дәгъвагыз да – бик ачык бер ялган әмер. Әгәр сезнең имамыгызга, мәсәлән, Шафигыйга үзенең тиңдәше яки аннан гыйлемлерәк бер имам каршы булса, ул вакытта тәкълидегездә дөреслеккә ирештегезме, хата кылдыгызмы – кайдан белү кирәк? Бу вакытта сез Шафигыйның әйткәне кебек төндә утын кисүче буласыз ки, кулыгызга таяк урынына елан алудан да хәбәрсез каласыз! Димәк, әгәр

---

[77] Дият – берәүнең үтерелгәне өчен түләнгән мал.

бердәм рәвештә дөреслеккә ирешсәгез, бер савап юк. Әгәр хата кылсагыз, акылыгызны, фикерегезне файдаланмаган өчен, Аллаһ каршында газапланачаксыз! Әмма мөҗтәһид уңышка ирешсә – ике саваплы, хата кылса – бер саваплы. Димәк, иҗтиһадның киләчәге тәкълиднең киләчәгеннән иминрәк.

Дөрес, әгәр бу мәсьәләдә дөреслек билгеле имамыбыз белән, башкасы белән түгел, дип белсәгез, ул вакытта дөреслеккә якынрак булыр. Ләкин моны белү, шиксез, дәлил белән булачагыннан, сез бу вакытта мөкаллид түгел, бәлки дәлилгә ияргән булачаксыз! Нигездә, гыйльми [рәвештә] низаглашкан мәсьәләләрдә дөреслеккә якынаю – ул мәсьәләне ияртүче сүзенә кайтарып, башка имамнарның һәммәсенең сүзен, күпчелек аларда була торып, кире кагу түгел, бәлки ул мәсьәләне, Аллаһ кушканча, Китап белән Сөннәткә кайтару.

Шул ук вакытта, сез искә алган мисалда сезгә файда түгел, бәлки сезгә зарарлы иң зур бер дәлил. Чөнки әгәр бер кеше бер нәрсә алырга яисә бер юлга керергә теләсә һәм ул турыда ике кеше яисә күбрәк кешеләр бер-берсе белән каршылыкка кереп, һәрберсе башкасы кушканның капма-каршысын кушса, бу вакытта бу адәм боларның һичберенә иярмичә, икеләнү эчендә кала һәм дөреслекне эзләргә үзе керешә. Әгәр болар мәгърифәт һәм диндә дә бертигез була торып, берсен сукырларча кабул итүгә көч куйса яисә тигезлек һәм тигез булмауны белмичә, дәлилсез-нисез зәгыйфрәген игътибарына алса, ул вакытта бу адәмне дөреслеккә ирештерсә дә, фикерсез ахмак һәм игътибарсыз дип шелтәләнә. Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә дәлилсез, сукырларча бер имамның сүзен кабул итүдән тыйган һәм төрле кешеләрнең сүзен өстен күрү өчен тыштан бер дәлил эзләүне әмер иткән. Инде без сездән сорыйбыз: сез борынгы һәм хәзерге һәрбер галимгә тәкълиднеме яисә фәкать кайберсенә [генә] тәкълиднеме дөрес күрәсез? Әгәр һәрберсенә тәкълидне дөрес күрсәгез, сезнең имамыгызга кебек, башкаларга да тәкълид дөрес булырга тиеш. Димәк, сезнең фәкать бу имам сүзен кабул итеп, аның каршысындагы башкаларның сүзләрен кире кагуыгыз акылга сыя

торган бер эш түгел. Әгәр шулай икән, сез боларга иярүне дөрес күрдегез һәм диннән башкага иярү, шиксез, дөрес түгел иде.

Димәк, боларның сүзләрен кире кагу динне кире кагу булып чыга. Моннан башка, сез имамыгыздан ике [төрле] сүз риваять кылынса, аларның кайсы белән булса да гамәлне дөрес күрәсез! Бу сүзләрнең икесен дә үз мәзһәбегездән хисаплыйсыз! Ихтимал ки, имамыгызның тиңдәше [булган] икенче мөҗтәһиднең сүзе иң өстенрәк һәм Китап белән Сөннәткә муафыйграктыр. Димәк, ни өчен аның сүзен имамыгызның ике [төрле] сүзенең берсе кебек итеп үз мәзһәбегездән хисапламыйсыз! Моннан башка, имамыгызга үзегез кебек тәкълид кылган кайбер ияртүчеләрегезнең сүз һәм фикеренә каршы чыккан яисә чыгарган бер сүзе белән, ничек булса да бер юл табып, фәтва бирәсез, хөкем кыласыз, кирәксенгәнен тиешле итәсез! Әгәр мондый бер хилафлык имамыгызның тиңдәше [булган] яисә аннан өстен бер имамнан чыкса, аңа илтифат та итмисез, кире кагасыз! Имамыгызның тиңдәше [булган] бу имам – имамыгызның әүвәлге һәм ахыргы иярченнәреннән иң югарырак, бөегрәк булуын хәтерегездән чыгарасыз.

Тугры хәлифәләр, Ибне Мәсгудь, Ибне Габбас, Әби бине Кәгъб, Әбү әд-Дарда һәм Мөгаз бине Җәбәл кебекләрнең сүзләре белән фәтване [кабул итүгә караганда] имамыгыз шәехләреннән берсенең сүзе белән фәтване кабул итәргә хаклырак, [дип] хисаплыйсыз! Моңа исә мөкаллидләрдән башка һичкемнең риза булу ихтималы юк. Әгәр фәкать кайберсенә тәкълидне дөрес күреп: «Һәрбер фирка фәкать без тәкълид иткән имамга иярсен дә аның шикелле яки аннан гыйлемлерәк [булган] башкаларның һәммәсен кире каксын», – дисәгез, бу вакытта, аеруча һәрбер фирка бу дәгъваны дәгъва кылган хәлдә, сезгә үз имамыгызның тәкълид иясе булуын исбат [итү] өчен дәлил күрсәтү тиеш була. Шул ук вакытта, сезнең ни Китаптан, ни Сөннәттән, ни өммәт иҗмагыннан һичбер дәлилегез юк. Киресенчә, һәрбер фирканың үз мәзһәбен изгеләштерүе, башкаларны адаштыруы һәм, бу сәбәпле, өммәт арасына бүленү төшүе, ислам диненең төрле дулкынланулары күз алдына куелуы һәм соңгы имамнарның сүзләре

каршысында сәхабәләрнең сүзләре диварга сугылуы – һәммәсе тәкълиднең ялган икәнен бик ачык исбат итә торган нәрсәләрдән.

Аллаһ Тәгалә бер кешенең күңел күзен сукыр итсә, аны һичбер нәрсә эшләтер хәл юк. Менә сез мөкаллидләр шулкадәр азган һәм шулкадәр юлдан чыккансыз ки, имамыгызның сүзе дип, Аллаһ хөкеме, Рәсүл хөкеменә дә каршы хөкем кылуда һәм: «Хәзер җир йөзендә Аллаһ дәлилләре белән торучы кешеләр юк, күп заманнан бирле беткән», – дип бакыруда сез! Сездән бер төркем, ягъни хәнәфиләрнең күпчелеге «Әбү Хәнифә, Әбү Йосыф, Зөфәр[78], Мөхәммәд бине Хәсән, Хәсән бине Зиядәдән[79] соң һичкемнең сүзе кабул ителмәс» дип, кайберәүләр «Әүзагый, Суфьян әс-Сәүри, Вәкигъ бине әл-Җәррах[80], Габдулла бине әл-Мөбарәктән[81] соң һичкемгә ихтыяр юк» дип, кайберәүләр, ягъни шафигыйлар «Шафигыйдан соң һичкемгә иярү дөрес түгел» дип әйткәннәре кебек, Бәкер бине әл-Галяъ әл-Кушәйри әл-Мәлики[82] дә: «Һиҗрәттән ике йөз елдан соң һичкемгә ихтыяр юк», – дип аңлаткан. Менә болар иҗтиһад томалау заманында фикердә каршылыкка кергән кебек, кем сүзен кабул итәргә кирәк, шуның турында да бик күп сүзләргә аерылганнар. Боларча хәзер гыйлем турысыннан сөйләшә торган кешеләр бетте, Китап белән Сөннәттән хөкемнәр чыгару өчен фикер йөртү дөрес булган заманнар узды, шуңа күрә һичкем имамының сүзен Китап белән Сөннәткә түгел, бәлки бу икесен имамының сүзенә тәкъдим итеп, ул изге хөкемне, әгәр имам сүзенә туры килсә – кабул итәр, юк икән – кире кагар. Ягъни изге һәм ялгышмас шәригатькә

[78] Зөфәр Әбү Һөзәйл бине әл-Һөзәйл әл-Ганбәри (728–775) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, казый.

[79] Хәсән бине Зияд әл-Лүлүи (734–814) – дин галиме, ислам хокукы белгече, мөҗтәһид, казый.

[80] Вәкигъ Әбү Суфъян бине әл-Җәррах әр-Руәси (746–812) – дин галиме, хәдис белгече, Коръәнне тәфсир кылучы.

[81] Габдулла Әбү Габдрахман бине әл-Мөбарәк әл-Мәрвәзи (736–797) – дин галиме, хәдис белгече.

[82] Бәкер Әбү Фазыл бине Мөхәммәд бине әл-Галяъ әл-Кушәйри әл-Мәлики (874–955) – дин галиме, ислам хокукы белгече, казый.

хатасы дөреслегенә [караганда] күп [булган] бер адәмнең сүзе тәкъдим ителер. Шушылай итеп ислам нигезеннән чыгарылыр һәм төрле каршылыклар белән тутырылыр. Ләкин болар бу бозыклыкларын һәм бу билгеле каршылыкларын исбат [итүгә] һәм изге шәригатьне инкяр [итүгә] ни кадәр тырышсалар да, Аллаһ Тәгалә үз нурын тәмамламыйча куймас.

Димәк, без боларга әйтәбез: әгәр шулай икән, бу вакыттан соң һичкемгә ихтыяр юк һәм, әгәр шулай икән, ике йөз елдан соң иҗтиһад бетәчәк. Ничек сез башкаларны һәм аларның Китап белән Сөннәткә муафыйк иҗтиһадларын куеп, моңа тәкълидне ихтыяр иттегез? Мәликнең сүзен алып, аның каршысында аннан хәерле сәхабәләр һәм табигыйннар сүзләрен диварга суктыгыз? Шул ук вакытта, бу ихтыярыгызга ни Китаптан, ни Сөннәттән, ни иҗмагтан, ни кыястан, ни ияртүчегез сүзләреннән һичбер дәлил юк иде. Дөрес, сез имамыгызны заманның алга баруы, аскетизм һәм диндарлык, шәехләр йөзе, иярүчеләренең күплеге белән өстен итмәкче буласыз. Ләкин ахыргы төркемнең дә бу дәлилнең урынына тотынганын һәм дә бу вакытта имамыгыздан артык, иң алдынгы, иң аскет, иң диндар, иярүчеләре бик күп, аның өстенә, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең үзенә юлыккан хөрмәтле сәхабәләргә иярү тиешлеген хәтерегездән чыгарасыз! Әбү Һөрәйрәдән имамы да булган, иярүчесе дә булган сигез йөз кешенең гыйлем алуын күңелегезгә дә китермисез! Ибне Габбас, Ибне Гомәр, Ибне Мәсгудь, Зәед бине Сабит, Мөгаз бине Җәбәл, Гомәр һәм Гали[83] кебекләргә тәкълидне исегезгә дә алмыйсыз! Зәед бине Сабит гыйлем алган Габдулла бине Габбастан гыйлем алуны фикерегезгә дә кертмисез! Имамнарыгызга иярүчеләр арасында Гата, Тавус, Мөҗәһид, Гыйкримә, Гобәйдулла бине Габдулла, Җабир бине Зәед, Сәгыйдь Шәгъби, Мәсрук, Галькәмә, Әсвәд, Шәрих, Нәфигъ,

---

[83] Ибне Габбас, Ибне Гомәр, Ибне Мәсгудь, Зәед бине Сабит, Мөгаз бине Җәбәл, Гомәр, Гали – Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзеннән гыйлем алган хөрмәтле мөселманнар, аның иярченнәре (сәхабәләре).

Сәлим, Касыйм, Гурвә, Хариҗә бине Зәед, Сөләйман бине Ясәр һәм Әбү Бәкер бине Габдрахман[84] кебек һичкемнең юклыгына игътибар да итмисез! Боларның һәм иярүчеләренең гасырлары хөрмәтле һәм үзләре зур дәрәҗәле була торып, соңгы замандагыларны үзләренә тәкълидтән тыюларына илтифат та итмисез! Фәлән-фәлән китаплардан күчермәсә, Аллаһ китабы һәм Аллаһның Рәсүле сөннәтеннән дәлил эзләгән адәмнең сүзенә колагыгызны да салмыйсыз! «Без Китап белән Сөннәтне аңламаганлыктан, тәкълид юлына керәбез», – дип үзегез әйткән хәлдә, галимнәр сүзләрен, Китап белән Сөннәткә тәкъдим иткән һәм муафыйк булса – кабул [иткән], каршы булса – кире каккан галимнәрне инкяр итәсез! Китап белән Сөннәтне сез белмәсәгез, Аллаһ Тәгалә бу заманда һәм сезнең арагыздан мондый галим кешеләрне бар итәргә кодрәтле түгелмени? Аллаһ сакласын, нигә кодрәтле булмасын? Кодрәтледер һәм бар иткән дә. Ләкин сез үз заманыгызда булган галимнән көнләшкәнлектән: «Аңа гыйлем тиешле түгел иде», – дип аны хурлауда һәм аның сүзләрен, никадәр туры булса да, инкяр итүдә! Шул ук вакытта, әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам: **«Минем өммәтем яңгыр кебек: аның башы яки ахыры хәерлеме – белеп булмый»**, – дип һәм Аллаһ Тәгалә дә: **«Ул [Аллаһ] укый-яза белми торган кавем эченнән үзләре кебек укый-яза белмәгән кешене [Мөхәммәдне] дөньяның барча кешеләренә рәсүл итеп җибәрде. Алар башта ачык адашуда булсалар да, ул рәсүл кешеләргә Аллаһ аятьләрен укый, аларны бозык игътикадлардан пакьлый һәм аларга Коръәнне, шәригать хөкемнәрен өйрәтә. Шулай ук ирешмәгән-күрмәгән, ягъни кыяматкә чаклы яши торган бөтен дөнья кешеләренә аны пәйгамбәр итеп җибәрде. Ул [Аллаһ] – Көчле һәм Хикмәт**

[84] Гата, Тавус, Мөҗәһид, Гыйкримә, Гобәйдулла бине Габдулла, Җабир бине Зәед, Сәгыйдь Шәгъби, Мәсрук, Галькәмә, Әсвәд, Шәрих, Нәфигъ, Сәлим, Касыйм, Гурвә, Хариҗә бине Зәед, Сөләйман бине Ясәр, Әбү Бәкер бине Габдрахман – сәхабәләрдән гыйлем алган мөселманнар (табигыйннар), бөек дин галимнәре.

**иясе. Аллаһның рәхмәте шундый, аны теләгән кешесенә бирер. Аллаһ – Олуг юмартлык иясе»** [Коръән: 62:2-4], – дип, Аллаһның рәхмәте, шул җөмләдән, гыйлем, хикмәт һәм иҗтиһадның һичбер заманда сүнмәячәген аңлаткан. **«Пәйгамбәрлек бу адәмдә булырга тиешле түгел иде» дигән кешеләргә каршы: «Әллә алар Раббыңның рәхмәтен билгелиләрме? Без әле аларның дөнья тормышларын Үзебез бүлдек, байлары ярлыларны хак биреп эшләтсеннәр өчен, аларның кайберләрен дөнья тормышындагы дәрәҗәдә кайберләреннән артык иттек. Раббыңның рәхмәте алар җыйган малдан хәерлерәк»** [Коръән: 43:32], – дип Аллаһ рәхмәтенең теләсә кемдә чагылуын белдергән.

* * *

Менә хәзер һиҗри 751 елда, ягъни, иҗтиһад бетте, дигәннән бик күп заманнан соң вафат булган мәшһүр Ибне Каййимнең «Игълям әл-мөвәкъкыйгыйн» исемле китабының тәрҗемәсе бу күләмдә тәмам булды. Бик ачык күренде ки, Ибне Каййим тәкълидтән тәмам бизгән, иҗтиһадның чикләнмәгәнлеген һәм чикләнә алмаячагын бик ачык, бик катгый дәлилләр белән исбатлаган, исламның бидгатьләр белән тулып, нигезеннән чыкканын сөйләгән. Шуңа күрә төзәтү юлына кереп, мәзһәб-фәлән [дип] карамыйча, ислам нигезенә кайтуны өстен күргән һәм киңәш биргән. Әгәр «Иҗтиһад заманы үтмәде һәм билгеле бер имамның сүзенә тәкълид тиешле түгел» дип әйтү, сез [әйткән] кебек, көферлек һәм адашу булса, бездән элек кяфер, бездән элек азгын Ибне Каййим һәм дүрт имам үзләре булырга тиешле иде, азрак инсафлык кылыгыз! Эшне уй белән түгел, бәлки дәлилгә карап йөртегез! Аллаһ Тәгаләнең хокукта тигезлекне һәм гаделлекне исбатлау өчен, кешеләр җәмгыятенә иң яхшы һәм иң муафыйк итеп җибәргән ислам ничек бу заманда килеп, мөселманнарга яхшы түгел булып китсен? Бу юләрлек һәм бу

көферлеккә чыгаруларыгызны бераз куеп торыгыз да, Китап белән Сөннәтне белмибез, дисәгез, һич булмаса, «Исламда иҗтиһад бар» һәм «Иҗтиһад чикләнгән» дигән ике заман арасындагы аерманы караш дикъкатегездән кичерегез! Исәпләгез ки, ни өчен мөселманнар исламның башлангыч чорында бу кадәр прогресс таптылар һәм ислам эченә мөселман һәм мөселман булмаган бөтен дөньяны рәхәт-рәхәт сыйдырдылар да, хәзер мөселманнар бу кадәр артка киттеләр һәм исламны хәтта үзләре дә сыймаслык бик тар итеп куйдылар? Әгәр сез бөтенләй риза булмасагыз, бу сорауның җавабын Аллаһ Тәгаләнең **«Сездән алдагы кешеләр белән дә шундый ук хәлләр булды (кешеләр шундый ук сынауларга дучар булды). Җир өстендә йөрегез һәм карагыз»** [Коръән: 3:137], **«Элек яшәгәннәр өчен Аллаһның гадәте шундый булды. Аллаһ гадәтенең үзгәргәнен тапмассың»** [Коръән: 33:62], **«Әгәр аларга: "Аллаһ иңдергән Коръән хөкемнәренә һәм рәсүл гамәленә килегез", дип әйтелсә, алар: "Ата-бабаларыбызны нинди юлда, нинди гамәлдә тапсак, шул безгә җитә", – дип җавап бирәләр. Аларның ата-бабалары хаклыкны белмәсәләр дә һәм туры юлда булмасалар да, шулай эшләрләрме?»** [Коръән: 5:105] дигән сүзләрендә табачаксыз! Яшәешнең хакыйкатендә Аллаһның шундый бер сөннәте һәм бер кануны бардыр ки, аңа игътибар иткән адәм мәдәниятнең иң югарысына менгән кебек, аны игътибарсыз куйган адәм дә түбәнлекнең иң түбәненә төшүдә.

Менә элекке мөселманнар исламның күрсәтмәсе буенча бу канунны аңлап, золым урынына гаделлекне, бозык әхлак урынына вөҗдан сихәтлеген, «Без һәркемнән өстен» дип уйлау урынына дуслыкны, тәкълид урынына иҗтиһадны һәм гыйлем белән хикмәт Кытай мәҗүсиләрендә булса [да], болай аны сезнең кебек кире какмыйча, кабул итүне ихтыяр иткәннәр. Шул сәбәпле, тормышларын саклаганнар иде. Соңра бер заман килде: мөселманнар ислам күрсәтмәсен оныттылар, золым һәм бозык әхлакка чумдылар, һәрбер дәүләттән аерылып, мәдәни эшләрдән мәхрүм калдылар, гыйлем һәм хикмәтне, кая мәҗүсидән алсыннар, хәтта яһүди һәм

нәсарада күрсәләр [дә], болай чиркана башладылар. Иҗтиһад һәм фикер йөртүне куеп, вәхшиләр, хәтта яшь балалар кебек, [болар] сукырларча тәкълидне ихтыяр иттеләр, яңа бер файдалы гамәлгә тотынган адәмне юләр [дип], бер китаптан бер мәгънә чыгаруы белән мәшгуль кешене ахмак [дип] санадылар һәм әйттеләр ки: «Кая безгә мондый гамәлләрне эшләргә, кая безгә бу китапларны аңларга?! Куй! Борынгыларга хас эш белән маташма! Инде иҗтиһад заманы узды, безгә тәкълидтән башка нәрсә калмады».

Менә болар иҗтиһад һәм фикерләүне бетереп, тәкълидне исбат [итү] юлында шулкадәр тырыштылар ки, хәтта бер мөселманны үзләре каршысында тезләндереп, тәкълид киемен киярргә мәҗбүр иттеләр. Нигездә, кеше табигате үзе дә тәкълидкә тартым. Хәтта тәкълид сәбәпле, бер үсеш дәрәҗәсе дә таба. Яшь баланың хәрәкәте башта, тууыннан соң, төгәл һәм тигез булмаса да, үскән саен имезүчесенең һәм ата-анасының хәрәкәтләренә иярергә тырыша, шул вакытта гамәлендә беренче үзләштерү һәм беренче охшату күренә дә башлый. Тәрбияле кеше янында торган балаларның әхлаклы, тәрбиясез кеше янында торган балаларның әхлаксыз булулары һәм сыйныфтагы бер әхлаксыз баланың бөтен сыйныфташларына зарар биргәнлеге безнең бу дәгъвабызны, ягъни тәкълиднең кешедә табигый булуын бик ачык күрсәтүдә. Шуның өчен дә кешедә тәкълид әсәренең бәласе куәтле. Шул дәрәҗәдә ки, кеше тәкълид итә-итә фикерләүләрен куя, хөкем чыгаруларын югалта да, тәкълиде табигый хәрәкәте шикелле булып китә. Инде бер кеше бу дәрәҗәгә төштеме – сез аннан һич хәерлек көтмәгез! Һичбер гыйлем һәм һичбер эштә прогресс табар, дип исәпләмәгез!

Димәк, ул табигый булган тәкълидтән котылу өчен билгеле бер чара кирәк ки, әүвәлдә ул – Рәхимлеләрнең Рәхимлесе [Аллаһ] биргән акыл һәм вөҗдан. Хайваннар акыллы булмаганлыктан, тәкълидләрендә һәм бер хәлләрендә калган хәлдә, кеше акылы белән аз-аз тәкълидтән чыгуда һәм шулай акрын-акрын прогресс табуда. Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә, акылларын

файдаланмыйча, тәкълидләрендә калган адәмнәрне хайван кебек, бәлки хайваннан да начаррак, дигән.

Димәк, хайванлыктан һәм тәкълид дәрәҗәсеннән чыгып, кешелек һәм мәдәният дәрәҗәсенә җитү өчен, әлбәттә, акыл һәм фикерне файдаланырга кирәк. Ләкин, кызганычка каршы, кешеләрнең бик күбесе, бик күпвакыт бу кануннан чыкканнар һәм акылсыз, фикерсез тәкълидтә нык булып калганнар. Безгә тарих күрсәтә ки, бик элекке заманнан бирле вакыт-вакыт иҗтиһад нуры галәмне яктыртып, гыйлем белән эшне күтәреп җибәрсә дә, аннан соң тагын тәкълид караңгылыгы басып, дөньяны наданлык, әхлаксызлык белән тутырган һәм бу икесе, кичә белән көндез кебек, әйләнеп торган.

Элекке греклар акылларын йөртеп, фәлсәфәне чыгарганнар иде, соңгылары аларга тәкълид итеп, фәлсәфәне юкка чыгардылар. Соңра ислам килеп, фикерләүгә, акылны файдалануга юл күрсәткәннән [соң], мөселманнар акылларын йөрткәннәр һәм гыйлемне, эшне бик арттырганнар иде. Иҗтиһад кояшы соңгы мөселманнарда тагын батты, тәкълид юлына кереп, бүгенге хәлгә, бүгенге түбәнлеккә төштеләр. Әмма иң соңра Европа уянды, тәкълид караңгылыгыннан чыкты, теше-тырнагы белән иҗтиһад һәм фикерләүгә тотынды да, гыйлемнәр һәм эшләрне менә бүген шашып карап торган дәрәҗәләргә ирештерде. Менә электән бирле гыйлем, мәгърифәт, иҗтиһад һәм тәкълид шушылай, көндез белән кичә кебек, үзгәреп, алмашынып килде һәм моннан соң да шулай китәчәк. Менә бу канун – бу үзгәреп торган галәмнең үзгәрмәгән бер кануны. Без бу канунны бер иҗтиһад һәм тәкълид турысында гына түгел, бәлки бу галәмнең башка җирләрендә дә күрәбез. Әгәр бер адәм тарих ишекләрен карауны дикъкатеннән кичерсә, өммәтләр, үзләренә килгән үзгәрүләр һәм алмашынуларны күреп, шакката.

Болгар, Алтын Урда, Казан һәм Кырым хөкүмәтләренең куәт һәм көчләрен күргән бер адәм боларның юкка чыгуын, икенче, бик зәгыйфь һәм яртылаш мәдәни, хәтта вәхши бер милләтнең кул астына кереп китүен ничек акылына китерсен?!

Сарай шәһәре зиннәт һәм рәхәтлекләр эченә күмелеп, бер адәм бервакыт килеп тә, бу шәһәрнең таш өстендә таш та калмаячагын ничек тасвирласын?! Моннан алты ай элек Мәсина шәһәренең юкка чыгачагын һәм харап булачагын, бу кадәр байлыклар бетерелүеннән башка, ике йөз мең адәм туфрак астында калып, артларыннан миллионнарча хур булганнарның аһ-ваһлары кемнең фикеренә килгән иде?!

Менә бу галәмнең кануны будыр ки, бер вакыт бер милләтне канаты астына алып тәрбияләсә, икенче вакыт үзе шул милләтне утлар эченә салып куыруда. Инде, әгәр шулай икән, бу нәрсә – бу галәмнең үзгәрми торган кануны. Димәк, бүген аның куәтле һәм аның мәдәни булган милләтләренең тәкълид бәлаләре һәм сәясәт дулкыннары астында юкка чыгып китүләре бик ихтимал булган кебек, иң ахмак һәм иң ваемсыз күренгән милләтләрнең дә иҗтиһад һәм мәдәнияттә иң югары дәрәҗәләргә менүләре һич булдыра алмаслык түгел. Димәк, бик мөмкин, безгә дә бер вакыт килер, сукырларча тәкълид боендырыгы муеныбыздан салыныр, Коръән кушкан саф иҗтиһад һәм дөрес фикерләү тоткасына ябышылыр. Менә шулвакыт безгә дә рәхәтлек ишекләре ачылыр.

Ихтимал, безгә бу рәхәт көннәр якынлашкандыр ки, хәзер мөселманнар һәрбер җирдә бераз хәрәкәтләнүдә һәм тәкълидтән чыгып, иҗтиһадка таба баруда. Боларның иҗтиһадлары Коръән кушкан саф иҗтиһад һәм дөрес фикерләү булса, мин рәхәт көннәребезнең якынлашуын ихтимал гына димәс, бәлки катгый [рәвештә] әйтер идем.

Ләкин, кызганычка каршы, эш болай ук түгел, бәлки безнең, тәкълидтән чыктык, дигәннәребезнең бик күбесе бер тәкълидне куеп, аннан да начар икенче бер тәкълидкә төшүдә. Элеккеләр хатыннар мәсьәләсендә бөтенләй хайванлык һәм коллыкны яхшы күргән кебек, бер фирка да, һичбер мәнфәгать һәм зарарын карамыйча, Европага тәкълидне өстен күрүдә. Бер фирка каберләрне тәбрикләүдә [изгеләштерүдә] бабаларына ияргән хәлдә, башка берсе Европага тәкълид кылып, мәйханә һәм фәхешханәләрне зиярәт кылуда. Тәкълидчеләр бөтенләй рам эченә тыгып,

авызлыклауда, һәрбер гыйлемнән йөз чөерүдә, ноктасы-ноктасына [кадәр] элекке фикыһка иярүдә, яхшылыкны яшел чапан һәм зәңгәр читек киюдән гыйбарәт, дип хисаплауда. Тәкълид кылганнары кебек, иҗтиһад тарафдарларыбыз дигәннәр үзләре дә һәрбер бушлыкны, һәрбер юләрлекне ихтыяр кылуда һәм зарармы, файдамы – һәрбер форманы кабул [итәргә] тырышуда; фикыһтан гына түгел, бәлки шәригать исеменнән бөтенләй бизүдә һәм мәдәниятне катыргы яка куеп, кара эшләпә киюдән гыйбарәт, дип әйтүдә; Европаның кайбер түбән төркеменә тәкълид кылуда. Кызганыч ки, болар малларын комар [уеннары], акылларын маскарад белән бетерүдә, аталарын ата булганлык өчен ачулануда һәм һәрбер нәрсәне вөҗданы белән түгел, бәлки фәкать кәефе белән хөкем итүдә.

Кыскасы: мөкаллидләр һәрбер яңаны фәкать яңа булганы өчен кире каккан кебек, «Тәкълидтән чыктык без» дип әйтүчеләр үзләре дә һәрбер искене, хәтта безнең өчен бик файдалы милли һәм дини гадәтләребезне дә фәкать иске булганнары өчен кире кагуда, тәкълидне, хакыйкатьтә, аңа ачуланып түгел, бәлки мөкаллид булган өчен куюда. Болар Аллаһ Тәгаләнең: **«Әллә алар җир өстендә йөрмәделәрме, йөрсәләр гыйбрәт алырлар иде, күңелләре йомшарып Аллаһның газабын аңлар иделәр һәм колаклары да хак сүзләрне ишетә торган булыр иде. Чынлыкта, маңгай күзенең сукыр булуы Аллаһны танып мөселман булудан мәхрүм итмәс, күкрәк эчендәге күңел сукыр булса – ул мәхрүм итәр»** [Коръән: 22:46] дигән сүзен хәтерләп, бу тәкълидләрдән ваз кичсәләр һәм шәригать кушкан саф иҗтиһадны кабул итсәләр, тәкълид һәм иҗтиһад исеменнән бу кадәр бозыклык, бу кадәр түбәнлекләр билгеле булмас иде. Бу ике фирка аңласын иде ки, ислам башка, фикыһ сүзе башка. Исламга иярү важиб булса да, фикыһ сүзенә иярү мәҗбүри түгел.

Коръәннән, Сөннәттән бик ачык күренеп торганлыктан, беләләр иде ки, ислам яңа булсын, иске булсын, адәм өчен файдалы һичнәрсә һәм һичбер мәгърифәттән тыю түгел, киресенчә, һәрбер эш һәм һәр мәгърифәттә прогрессны, иҗтиһадны

үзе әмер [итә]. Исламча, Аллаһ Тәгалә яхшылыкны хәләл, яхшы әхлакны мәҗбүри һәм начарлыклар белән бозык әхлакны хәрам иткән. Ислам әхлагы һәм милли гадәтләрне саклау шарты белән гыйлем һәм эшләрне, Кытай мәҗүсиләреннән булса да, алу – ислам тарафыннан әмер ителгән бер хөкем. Исламның кануны: **«Чынлыкта, Аллаһ һәр эштә гадел булырга, яхшы эшләр кылырга һәм якын кардәшләрнең хакын үтәргә боера. Аллаһ сезне бозыклыктан, хәрам эшләрдән һәм хаксыз золым итүдән тыя. Ул сезне вәгәзьли, бәлки, вәгазьләнерсез!»** [Коръән: 16:90], – дигән сүз ки, моңа зарар бирмәгән вакытта ислам һичбер нәрсәдән тыймый.

* * *

Хәзер аңлашылды ки, безгә бер тарафтан гыйлемнәр һәм эшләр өчен иҗтиһад мәҗбүри булган кебек, икенче тарафтан фикыһны төзәтү һәм исламны нигезенә кайтару өчен дә бик күп тырышу тиешле. Бу тиешлек безнең югарыда әйтелгән сүзләребездән дә бик ачык аңлашылган иде. Шулай булса да, мөселманнарның үсеше, артта калуы шуңа бәйле булган мондый мөһим бер мәсьәләдә тагын җентекләп аңлатуларга керешү зарар түгел, бәлки файда биргәнлектән, без бу китапка өстәмә буларак сәед Мөхәммәд Рашиднең «Әл-мәнар»да «Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе» исемле язган китабын тәрҗемә итүне кирәкле күрдек. Һәрбер киләчәк нәрсә якын.

***Габдулла Буби***
**Прошло ли время иджтихада или нет?**

*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 09.06.2022 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 9,5. Тираж 300 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

420029, Татарстан, Казань, Сибирский тракт, 34, корпус 14, подъезд 1, офис 317
E-mail: sales@kurantyprint.ru

بعد الطبع تفتيش صوگنده تابلغان بعض خطالر :

| خطاء | صواب | بيت | يول |
|---|---|---|---|
| ترقی‌نک | ترقی‌نگ | ٢ | ١ |
| بحثلری | مجتهدلری | ٣ | ١٢ |
| لغت | لعنت | ٣ | ١٤ |
| ان يفتن | ان يفتنی | ١١ | ٥ |
| ما فرطتانی | ما فرطنا فی | ١٥ | ٢٢ |
| واتممت نعمتی | وأتممت عليكم نعمتی | ١٥ | ٢٣ |
| مستقيم | سقيم | ١٦ | ٢٠ |
| حلاق | خلاف | ٢٩ | ٥ |
| تقليه | تقليد | ٣٨ | ٢٥ |
| فبول | قبول | ٤٤ | ٢٣ |

بالْعَدْل وَالْاحْسان وَ ايتَاء ذی الْقُرْبی وَ ینْهی عَن الْفحْشَاء وَالْمُنْكَر وَ الْبغی»
دیگان سوزدر، كه بوڭا ضرر ویرمگان وقتده اسلام هیچ برشیدن
مانع دگلدر.

شمدی آڭلاشلدی، كه بزه بر طرفدن علوم وصنایع ایچون اجتهاد
لازم بولدیغی كبی، ایكنچی طرفدن فقه‌نی توزاتو واسلام‌نی اساسینه
قایتارو ایچونده بك زیاده دورشمق لازمدر.

بولزوم بزم یوقارغی سوزلرمزدنده بك آچق آڭلاشلمش ایدی.
شولای بولسه‌ده مسلمانلرڭ ترقیسی، تدنیسی آڭا باغلنان بویله
مهم برمساله‌ده دخی تفصیلاته كرشو ضرر دگل، بلكه فایده
ویردیكندن بز بورساله‌یه ذیل اولارق سید محمد رشیدنڭ
المنارده «مصلح ایله مقلدنڭ مناظره‌سی» عنوانی آستونده یازدیغی
رساله‌سینی ترجمه قیلونی مناسب كوردك وكل آت قریب.

عبدالله بوبی

صوڭ

فورمه‌نی قبول‌غه دوروشوده، فقه‌دن گینه‌دگل ، بلکه شریعت اسمندن بتونلای بیزوده ومد نیت‌نی قاطورغه یاقا قویوب قاره اشلاپا کییودن عبارت دیوب ایتوده آوروپانک بعض برسفلا گروهسینه تقلید ایلمکده درلر . تأسف‌که بونلر ماللرینی قمار ، وعقللرینی مسکرات ایله تلف ایتمکده وآتالرینی آتا بولغانلق ایچون آچولانمق‌ده وهر برشی‌نی وجدانی برلان دگل، بلکه فقط کیفی بلن محاکمه ایلمک‌ده‌درلر .

والحاصل: مقلدلر هربر یکی‌نی فقط یکی بولدیغی ایچون رد ایلدکلری کبی ، تقلیددن چقدق بز دیگانلر اوزلریده هربر ایسکی‌نی حتی بزم ایچون بك فایده‌لی عادات ملیه ودینیه‌مزنی‌ده فقط ایسکی بولدقلری ایچون رد ایلمکده وتقلیدنی حقیقت آگا آچولانوب دگل، بلکه مقلد بولدقلری ایچون قویمقده درلر . کاشکی بونلر الله‌تعالی‌نک « افلم یسیروا فی‌الارض فتکون لهم قلوب یعقلون بها او اذان یسمعون بها فانها لا تعمی‌الابصار ولکن تعمی‌القلوب التی فی الصدور » دیگان، سوزینی خاطرلاب بو تقلیدلردن وازکچه‌لر ، وشریعت قوشقان‌صاف اجتهادنی قبول قیلسه‌لر ایدی، تقلید هم‌اجتهاد اسمندن بوقدر فساد وبوقدر ذلت‌لر معین بولماز ایدی . بوایکی فرقه آگلاملی ایدیلر ، که اسلام باشقه ، قول فقها باشقه . اسلامه‌اتباع واجب بولسه‌ده قول فقهاغه اتباع لازم دگل‌در .

وقرآندن، سنتدن‌بك آچق کورنوب‌طورغانلق‌دن‌بیلملی‌ایدیلر ، که‌اسلام‌یکی اولسون ایسکی‌اولسون آدم‌ایچون فایده‌لی‌هیچ شی‌وهیچ بر معرفتدن‌مانع‌دگل، بالعکس‌هربر صنعت وهر معرفتده‌ترقی‌و اجتهاد‌ایله اوزی آمردر. اسلام‌چه الله‌تعالی طیباتنی‌حلال‌واخلاق‌حسنه‌نی لازم‌وخبایث ایله‌اخلاق‌فاسده‌نی‌حرام‌ایلمش‌در . اخلاق‌اسلامیه‌وعادات‌ملیه‌نی محافظه شرطی ایله علوم وصنایع‌نی‌صین مجوسلرندن بولسه بیله آلو اسلام طرفندن امر اولنمش برحکم‌در. اسلامک قانونی : « ان الله یأمر

صالوب قاورمقده‌در. ایمدی مادامکه بو تقلیات بو عالمنگ قانون لایتغیری‌در؛ بس بو کون آننگ قوتلی و آننگ مدنی اولان ملتلرنگ تقلید بلالری وسیاست طولقونلری آستونده محو اولوب کیتولری بك احتمال بولدیغی کبی، اگ احمق واگ غافل کورنان ملتلرنگده اجتهاد ومدنیت‌ده، اگ یوغاری درجه‌لره بینولری برده مستبعد دگل‌در. بس بك‌ممکن، بزه‌ده بر وقت کیلور صوقور تقلید بویوندریغی بوینمزدن صالنور، قرآننگ قوشدیغی صاف اجتهاد وصادق تفکر طوطقه‌سینه یابشیلور؛ مونه شول وقت بزه‌ده راحت ایشکلری آچلور.

احتمال بزه‌بو راحت کونلر یاقنلاشمش‌در، که حاضرنده مسلمانلر هر بر یرده بر آز حرکتلنمك‌ده وتقلیددن چغوب اجتهادغه طابا بارمقده درلر. کاشکی بونلرننگ اجتهادلری قرآننگ قوشدیغی صاف اجتهاد وصادق تفکر بولسه ایدی بن راحت کونلرمزننگ یاقنلاشوینی احتمال‌غینه دیماز بلکه، قطعی ایتور ایدم.

لکن مع‌التأسف ایش بولایوق دگل، بلکه بزم تقلیددن چقدق دیگانلرمزننگ بك کوبسی بر تقلیدنی قویوب آندنده ناچار ایکنچی بر تقلیدکه توشمك‌ده درلر. ایسکی‌لر قادینلر مسأله‌سنده بتونلای حیوانلق وقوللق‌نی مصلحت کوردکلری کبی، برفرقه‌ده هیچ بر منفعت ومضرت قارامایونچه آوروپاغه تقلیدنی ترجیح قیلمقده درلر. بر فرقه قبرلرنی تبریك‌ده بابالرینه ایاردکلری حالده، دیگر برسی آوروپانی تقلید قیلوب میخانه وفخش خانه‌لرنی لاابالیانه زیارت ایلمك‌ده درلر. تقلیدچیلر بتونلای رام ایچینه طغوب آوزلقلاوده وهر بر علم‌دن یوز چاوروده ونقطه‌سی نقطه‌سینه ایسکی فقه‌گه متابعتده ویخشی‌لق‌نی یاشل چاپان وزنگر چیتك کیودن عبارت دیوب حسابلاوده، تقلید ایلدکلری کبی، اجتهاد طرفداریمز دیگانلر اوزلریده هر بر بوشلق وهر بر سفاهت‌نی اختیارده وضرری فایده‌سی هر بر

ایسکی یونانلی‌لر عقللرینی یورتوب فلسفه‌نی چغارمشلر ایدی صوڭغی‌لری آنلره تقلید ایدوب فلسفه‌نی برباد قیلدیلر. صڭره اسلام کیلوب تفکر واستعمال عقل‌غه ارشاد قیلدیغندن مسلمانلر عقللرینی یورتمشلر وعلمنی صنعت‌نی بك آرتدرمشلر ایدی، اجتهاد قویاشی‌صوڭغی مسلمانلردن دخی غروب ایتدی، تقلیدیولینه کروب بوکونگی حال‌گه وبوکونگی سفالت که توشدیلر. اما اڭ صڭره آوروپا اویاندی، تقلید ظلمتندن چقدی، دیشی طرناغی ایله اجتهاد وتفکرگه طوطوندی‌ده علوم وصنایع‌نی، مونه بوکون شاشوب قاراب طوردیغمز درجه‌لره ایرشدردی. مونه ایسکی‌دن بیرلی علم ومعرفت هم اجتهاد وتقلید شوشلای کوندوز ایله کیچه کبی، اوزگاروب آلماشنوب کیلدی وبوندن صوڭ هم شولای کیده‌چك‌در. مونه بوقانون اشبوعالم متغیرنڭ برقانون‌لایتغیری‌در. بز بوقانون‌نی براجتهاد وتقلید بابنده‌غینه دگل، بلکه اشبوعالم‌نڭ باشقه یرلرنده‌ده کورمك ده‌مز. اگربرآدم ابواب تاریخ‌نی نظر دقتندن کیچورسه امتلراوزه‌رینه کیلگان تغیر وتبدل لرنی کوروب شاقلرقاطار.

بلغار وآلتون اردوهم قازان وقریم حکومتلرینڭ قوت وشوکتلرینی کوران برآدم بونلرنڭ انقراضینی وایکنچی، بك ضعیف ونیم مدنی حتی‌وحشی برملت‌نڭ قول آستینه کروب کیتووینی نیچك عقلینه کیتورسون؟ سرای شهرینڭ زینت وراحتلری ایچینه کومولان برآدم بروقت کیلوبده بوشهرنڭ طاش اوستونده طاش بیله‌قالمیه چغینی نیچك تصور ایلسون؟ بوندن آلتی آی مقدم مسینا شهرینڭ محو وخراب اولاچغی وبوقدر بایلقلر تلف اولووندن باشقه ایکی یوز بیك آدم طوپراق آستونده قالوب آرتلرندن میلیونلرچه اچ وسفیللرنڭ آه‌واه‌لری کیم نڭ‌فکرینه کلمش ایدی؟

مونه بو عالم‌نڭ قانونی اوشبودر، که بر وقت بر ملت‌نی قاناطی آستینه آلوب تربیه‌لسه ایکنچی وقت عین شول ملت‌نی اوت‌لر ایچینه

حرکتلرینی تقلیدکه دوروشه وشول وقت عملنده اوّل ضبط واوّل تناسب کورنه‌ده باشلای‌در، تربیه‌لی کشی یاننده طورغان بالالرنک اخلاقلی وتربیه‌سز کشی یاننده طورغان بالالرنک اخلاقسز بولرلری وصنفده‌غی بر اخلاقسز بالانک بتون صنف آرقداشلرینه ضرر ویرمك‌لگی بزم بو مدعامزی یعنی، تقلیدنک انسانده طبیعی بولمق‌لغینی، بك آچق کورساتمك‌ده‌در. شونک ایچونده انسانده اثر تقلید بلاسی قوتلی‌در. شول درجه‌ده، که انسان تقلید ایده ایده تفکرلرینی قویه، محاکمه‌لرینی یوغالتاده تقلیدی حرکات طبیعیه‌سی شیکللی بولوب کیته‌در. ایمدی بر انسان بو درجه‌گه توشدیمی سز آندان اصلا خیر کوتمه‌گز! وهیچ بر علم وهیچ بر صناعتده ترقی طابار دیوب ایسابلامه‌گز!

بس اول طبیعی اولان تقلیددن قوتولمق‌لق ایچون معین بر چاره کیراك، که اولده اول ارحم‌الراحمین حضرتلرینک‌ویردیکی عقل، وجدان‌در. حیوانلر عقللی اولمادقلرندن تقلیدلرنده وبر حاللرنده قالدقلری حالده، انسان عقلی ایله آز آز تقلیددن چقمقده وشولای آقرون آقرون ترقی طابمقده‌در. شونک ایچوند الله‌تعالی حضرتلری عقللرینی استعمال قیلمایونچه تقلیدلرنده قالغان آدملرنی حیوان کبی بلکه حیواندن‌ده اضل دیمش‌در.

بس حیوانیتدن وتقلید درجه‌سندن چغوب انسانیت ومدنیت درجه‌سینه بینمك‌لك ایچون البتة عقل وفکرنی استعمال قیلورغه کیراك؛ لکن مع التأسف انسانلرنک بك کوبسی وبك کوب وقت بوقانوندن چقمشلر، وعقلسز، فکرسز تقلیدده ثابت قدم بولوب قالمشلردر. بزه‌تاریخ کورساته‌در، که بك ایسکی‌زماندن برلی وقت‌وقت اجتهاد نوری عالم‌نی، یاقتورتوب‌وعلم‌ایله صنعت‌نی، کوتاروب جیبارسه‌ده آنک صوگنده دخی تقلید ظلمتی باصوب دنیانی جهل واخلاقسزلق ایله طولدرمش وبوایکیسی کیچه ایله کوندز کبی، ایلانوب‌طورمش‌در.

عَلَيْهِ اٰبَاۤؤُنَا اَوَلَوْ كَانَ اٰبَاۤؤُهُمْ لَا يَعْلَمُونَ شَيْـًٔا وَلَا يَهْتَدُونَ» دیگان سوزلرنده طاباجق‌سکز! حقیقة وجودده الله‌نک اویله بر سنتی و بر قانونی واردر، که آنی اعتبار ایدن آدم مدنیت نک اک یوغاری‌سنه بیندیکی کبی، آنی اعتبارسز قویغان آدم‌ده سفالت‌نک اک توبانینه توشمك‌ده‌در.

مونه ایسکی مسلمانلر اسلامک ارشادی بویونچه بو قانون‌نی آکلاب ظلم اورنینه عدالت‌نی، فساد اخلاق بدلینه صحت وجداننی، بز هر کیم‌دن اوستون دیوب انزوا اورنینه اختلاطنی وتقلید اورنینه اجتهادنی هم علم ایله حکمت، صین مجوسلرنده بولسه بیله آنی سزگ کبی، رد ایتمایوب قبول قیلونی اختیار ایلمشلر، وشول سببدن حیاتلرینی صاقلامش‌لر ایدی، صگره بر زمان کیلدی مسلمانلر ارشاد اسلام‌نی اونوتدیلر، ظلم و فساد اخلاق‌غه چومدیلر، هر بر دولت‌دن آیریلوب امور عمرانیه‌دن محروم قالدیلر، علم وحکمتنی قایا مجوس‌دن آلسونلر حتی یهود ونصاری‌ده کورسه‌لر بیله استکراه ایته باشلادیلر. اجتهاد و فکر یورتونی قویوب وحشی‌لر حتی یاش بالالر کبی، صوقور تقلیدنی اختیار ایلدیلر، یکی بر عمل نافع‌غه طوطونغان آدم‌نی سفیه و بر کتاب‌دن بر معنا استخراجی ایله مشغول کشی‌نی احمق صانادیلر، ودیدیلر، که قایابزگه بونداین عمللرنی اشلرگه وقایا بزگه بو کتابلرنی آکلارغه؟ قوی! متقدمین‌گه خاص اش ایله ماطاشمه! ایندی اجتهاد زمانی اوزدی، بزه تقلیددن باشقه شی قالمادی.

مونه بونلر اجتهاد وتفکرنی بیتروب تقلیدنی اثبات یولنده اول قدر دوروشدیلر، که حتی بر مسلمان‌نی اوزلری قارشوسنده دیزلاندیروب تقلید لباسنی کیمیه مجبور ایتدیلر. ذاتا طبیعت انسان اوزیده تقلیدکه مایل‌در. حتی تقلید سببلی بر درجه ترقی‌ده طابادر. یاش بالانک حرکاتی باشده ولادتندن ضوگ غیر مضبوط وغیر متناسب بولسه‌ده اوسکان صایون مرضعه‌سینک وآتا آناسینک

بولدی دیگاندن بك کوب زمان صوڭ وفات اولان مشهور ابن قیم‌نڭ «اعلام الموقعین» اسمنده‌گی کتابی‌نڭ ترجمه‌سی بوراده تمام بولدی. بك آچق کورندی، که ابن قیم تقلیددن تمام بیزمش واجتهادنڭ مسدود دگل‌لگینی ومسدود هم اولامیه‌چغینی بك ظاهر وبك قطعی دلیللر ایله اثبات ایلامش، واسلامڭ بدعتلر ایله طولوب اساسندن چقدیغینی یاناباقیله سویلامش، وبناءً علیه اصلاح یولینه کروب مذهب فلان قارامایونچه اساس اسلامه قایتونی ترجیح وتوصیه قیلمش‌در. اگر زمان اجتهاد منقرض دگل ومعین بر امامڭ سوزینه تقلید لازم دگل، دیمك‌لك، سزڭ کبی، کفر وضلالت بولسه ایدی، بزدن ایلك کافر وبزدن ایلك آزغون ابن‌قیم هم ائمهٔ اربعه اوزلری بولورغه تیوشلی ایدی، آزراق انصاف قیلڭز! ایش‌نی ظن‌بلن‌دگل، بلکه‌دلیل‌گه‌قاراب‌یورتڭز! الله‌تعالی‌نڭ حقوقده‌مساوات وعدالت‌نی‌اثبات‌ایچون‌جمعیت‌بشریه‌گه اڭ‌صالح‌واڭ‌موافق‌قیله‌رق جیبار دیکی اسلام نچك بوزمان کیلوب مسلمانلره غیر صالح بولوب کیتسون؟ بوسفاهت وبوتکفیرلریکزنی بر آزقویوب طوریکزده کتاب ایله سنت‌نی بیلمایمز دیسه‌ڭز هیچ اولماسه اسلامده اجتهاد وار واجتهاد مسدود دنیلان ایکی‌زمان آره‌سنده‌غی آیرمه‌نی نظر دقتکزدن کچوریکز! وایسابلاڭز، که نه ایچون مسلمانلر ابتدای اسلامده بوقدر ترقی طابدیلر واسلام ایچینه مسلم وغیر مسلم بتون دنیانی راحت راحت‌صیدر دیلرده حاضرنده مسلمانلر بوقدر آرتقه کیتدیلر واسلام‌نی حتی اوزلریده صیمازلق بك طار ایتوب قویدیلر؟ اگر سز بتونلای ممنون اولماسه‌ڭز بوسؤالنڭ جوابینی الله‌تعالی‌نڭ: «قَدْ خَلَتْ مِنْ قَبْلِكُمْ سُنَنٌ فَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ فَانْظُرُوا – سُنَّةَ اللّٰهِ فِي الَّذِينَ خَلَوْا مِنْ قَبْلُ وَلَنْ تَجِدَ لِسُنَّةِ اللّٰهِ تَبْدِيلًا وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ تَعَالَوْا إِلَىٰ مَا أَنْزَلَ اللّٰهُ وَإِلَى الرَّسُولِ قَالُوا حَسْبُنَا مَا وَجَدْنَا

متأخرین‌نی اوزلرینه تقلیددن منعلرینی التفاتده ایتمای‌سز! و فلان فلان کتابلردن کوچرماسه کتاب‌الله وسنة رسول‌الله ایله دلیل ایستیان آدمک سوزینه قولاغکزنی‌ده صالمای‌سز! وبز کتاب ایله سنتی آکلامادیغمزدن تقلید یولینه کرمز دیوب، اوزیکز ایتدککز حالده اقوال علمانی، کتاب ایله سنته عرض ایدن و موافق بولسه قبول، مخالف بولسه رد قیلان عالملره انکار ایته‌سز! کتاب ایله سنت‌نی سز، بیلماسه‌کز، الله تعالی اشبو زمانده وسزک آره‌کزده بونلری عالم کشیلرنی خلق قیلورغه قادر دکل‌منی؟ العیاذ بالله نیگه قادر بولماسون؟ قادردر هم خلقده ایلمشدر؛ لکن سز اوز زمانکزده اولان عالمه، حسد ایتدککزدن آکا علم تیوشلی دکل ایدی دیه‌رك آنی حقارت ایلمك‌ده و آنک سوزلرینی نه قدر طوغری بولسه‌ده انکار قیلمقده‌سکز! حال بوکه افندمز علیه السلام: «امتی کالمطر لایدری اوله خیر ام آخره» دیوب، هم الله تعالی‌ده: «هو الذی بعثَ فی الأمّیینَ رَسُولاً منهم یتْلوا علیهمْ ایاته ویزکّیهم ویعلّمهم الْکتابَ وَالْحکْمةَ وَانْ کانُوا منْ قبلُ لفی ضَلالٍ مبینٍ وَاَخرینَ منهم لمّا یلحقوا بهم وهو العزیزُ الحکیمُ ذلكَ فضلُ اللّهِ یؤتیه منْ یشاءُ واللّهُ ذُوالفَضْلِ الْعَظیم» دیه‌رك فضل، الله‌نك، آنک جمله‌سندن علم‌وحکمت هم اجتهاد ایدی هیچ برزمان سونمیه‌چکینی آکلاتمش ونبوت بو آدمده بولورغه تیوشلی دکل ایدی، دیگان کشیلره قارشی: «اهم یقسمونَ رحمةَ ربّك نحنُ قسمنا بینهم معیشتهم فی‌الحیوة‌الدنیا ورفعنا بعضهم فوقَ بعضٍ درجاتٍ لیتّخذَ بعضهم بعضاً سخریاً ورحمةُ ربك خیر مما یجمعون» دیوب، فضل الهی‌نك دیلسه کیم‌ده تجلی ایده‌چکنی بیلدرمش‌در.

مونه شمدی هجرتدن یدی‌یوز اللی‌برنچی سنه‌ده‌یعنی، اجتهادمنقرض

کوب بر آدمنك سوزی تقدیم اولنور. وشوشلای ایتوب اسلام اساسندن چغاریلور ودورلی تناقضلر ایله طوطرولور؛ لکن بونلر بو فسادلرینی وبو آچق تناقضلرینی اثبات غه وشریعت مقدسه‌نی انکار غـه نه قدر دوروشسه‌لرده الله تعالی اوز نورینی تمام قیلمایونچه قویماز.

بس، بز بونلر، ایته‌مز: مادامکه بومدت صوکنده هیچ کیمه اختیار یوق ومادامکه ایکی یوز یلدن صوك اجتهاد منقرض‌در. بس نچك سز باشقه‌لرنی وآنلرك کتاب ایله سنته موافق اجتهادلرینی قویوب معین بوکا تقلیدنی اختیار ایلدیکز؟ ومالك‌نك سوزینی آلوب آنك قارشوسنده‌غی آندن خیر اصحاب وتابعین سوزلرینی دیواره صوقدیکز؟ حال بوکه بو اختیاریکزه نه کتابدن ونه سنت‌دن ونه اجماع‌دن ونه‌قیاس‌دن ونه اقوال متبوعکزدن هیچ بر دلیل یوق ایدی. درست سز، امامکزنی تقدم زمان، زهد وتقوی، لقای شیوخ وکثرت اتباع ایله ترجیح ایتمکچی بولاسز! لکن فریق آخرنك‌ده بو دلیل‌نك اورنینه تمسکینی همده بووقت امامکزدن‌زیاده، اك‌مقدم، اك‌زاهد، اك‌تقوی، تابعلری اك کوب وآنك اوستینه‌ده افندمز علیه السلام‌نك اوزینی یولقغان اصحاب کرام‌غه ایبارو تیوشلگینی خاطرکزدن چیغاره‌سز! ابوهریره‌دن: امامی وار تابعی‌وار، سکز یوز کشی‌نك علم آلووینی کوکلکزه‌ده کیتورمای‌سز! ابن عباس، ابن عمر، ابن مسعود، زید بن ثابت، معاذ بن جبل، عمر وعلی کبیلره تقلیدنی ایسکزه‌ده آلمای‌سز! زید بن ثابت علم آلغان عبد الله بن عباس‌دن علم آلونی فکرکزه‌ده کرتمای‌سز! واماملریکزك اتباعسی آره‌سنده عطاء، طاوس، مجاهد، عکرمه، عبید الله بن عبد الله، جابر بن زید، سعید شعبی، مسروق، علقمه، اسود، شریح، نافع، سالم،قاسم عروه، خارجه بن‌زید، سلیمان‌بن یسار، وابوبکر بن‌عبدالرحمن کبی هیچ کیم‌نك یوقلغینی اعتبارده قیلمای‌سز! وبونلرك هم تابعلرینك عصرلری شریف واوزلری بیوك درجـه‌لی بولا طوروب

ایچون دلیل کورساتو لازم بولادر. حال بوکه سزنگ نه کتابدن ونه سنتدن ونه اجماع امتدن هیچ بر دلیلنگز یوقدر. بالعکس هربر فرقهنگ اوز مذهبینی تقدیس وباشقهلرنی تضلیل قیلووی واشبو سببدن امت آراسینه تفریق توشووی ودین اسلامنگ دورلی اضطرابلره معروض بولووی وصوکغی امامدرک سوزلری قارشوسنده اقوال صحابهنگ دیوارغه صوغولووی، همهسی تقلیدنگ بطلانینی بك آچق اثبات قیلا تورغان شیلردندر.

اللهتعالی بر کشینگ کوکل کوزینی صوقور قیلسه آنی هیچبر نرسه اشلاتور حال یوق. مونه سز مقلدلر شول قدر آزمش وشول قدر یولدن چقمشسکز، که امامزنگ سوزی دیهرك، حکمالله حکم رسوله بیله مخالف حکم قیلمقده وشمدی وجه ارضده براهین الهیه ایله قایم اولان کشیلر یوق، کوب زماندن بیرلیمنقطع دیوب، باغرمقدهسکز! سزدن بر طائفه یعنی اکثر حنفیه «ابو حنیفه، ابو یوسف، زفر، محمد بن حسن، حسن بن زیاده، صوکنده هیچ کیمنگ سوزی قبول قیلنماز» وبعضیلر «اوزاغی، سفیان الثوری، وکیع بن الجراح وعبدالله بن المبارك، صوکنده هیچ کیمه اختیار یوق» وبعضیلر یعنی شافعیلر «شافعی صوکنده هیچ کیمه اتباع درستدگل» دیدکلری کبی، بکر بن العلاء القشیری المالکیده «هجرتدن ایکی یوز یل صوکنده هیچ کیمه اختیار یوق» دیوب تصریح ایلمشدر. مونه بونلر انسداد اجتهادک زماننده اختلاف قیلشدقلری کبی، کیم سوزینی قبول قیلورغه کیراك، شونگ خصوصندهده بك کوب قوللرگه آیرلمشلردر. بونلرچه شمدی باب علمدن سویلاشه طورغان کشیلر بتدی کتاب ایله سنتدن احکام چغارو ایچون نظر درست بولغان زمانلر اوزدی، بناء علیه هیچ کیم امامینگ سوزینی کتاب ایله سنته دگل، بلکه بوایکیسنی امامینگ سوزینه عرض قیلوب، اول حکم مقدسنی اگر قول امامینه مطابق ایسه قبول، یوق ایسه رد قیلور. یعنی مقدس ویا کغشماز شریعتکه خطاسی صوابندن

تقلیدنی جایز کورسه‌کز! سزنک امامکز کبی ، باشقه‌لرغه‌ده تقلید درست بولورغه کیراك، بس سزنک فقط بو امام سوزینی قبول قیلوب آنک قارشوسنده‌غی باشقه‌لرنک سوزلرینی رد ایتووکز، عقل‌غه صیبه طورغان براش دگلدر. مادامکه‌سز بونلره اتباع نی‌درست کوردیکز ودیندن باشقه‌غه اتباع مطلقا درست دگل ایدی.

بس بونلرنک سوزلرینی رد، دین‌نی‌رد بولوب چغه‌در.بوندن ماعدا سز امامکزدن ایکی قول روایت قیلنسه آنلرنک قایسی ایله بولسه‌ده عمل‌نی جایز کوره‌سز! وبو قوللرننک ایکوسنیده اوز مذهبکزدن حساب قیلاسز! احتمالکه امامکزنک نظیری ایکنچی مجتهدننک سوزی راجح رك وکتاب ایله سنته موافقراقدر. بس‌نه ایچون آنک سوزینی امامکزنک ایکی‌سوزینک برسی‌کبی ایتوب اوزمذهبکزدن حساب قیلمای‌سز ؟ .بوندن‌ده ماعداسز، امامکزه اوزکز کبی تقلید ایدن بعض اصحابکزنک قول وفکرینه خلاف ایتکان یاخود تخریج قیلغان برسوزی ایله نچك بولسه‌ده بروجه طابوب فتوی ویره‌سز، حکم قیلاسز ومقتضا سنی الزام ایته‌سز! اگر بویله بر خلافلق امامکزنک نظیری یاخود آندن اوستون بر امام‌دن صادر بولسه ، آ کا التفاتده ایتمای‌سز، ردقیلا سز! امامکزنک نظیری بو امام واصحاب امامکزنک اولندن آخرندن اجل واعلی بولمق لقینی خاطریکزدن چغاره سز.

خلفای‌راشدین، ابن‌مسعودابن‌عباس،ابی‌بن‌کعب ،ابوالدرداٴ ومعاذ بن جبل کبیلرنک سوزلری ایله فتوی‌دن مشایخ امامکزدن برسی‌نک سوزی ایله فتوی نی احق بالقبول حساب ایته‌سز! بو کا ایسه مقلدلردن باشقه‌هیچ کیم‌نک راضی بولو احتمالی یوق‌در. اگر فقط بعضی‌سینه تقلید نی جایز کوروب هر بر فرقه فقط بز تقلید ایدن امامه ایپارسونده آنک مثلی یاکه آندن اعلم باشقه‌لرنک همه‌سینی رد ایلسون دیسه‌کز، بو وقتده خصوصا هربر فرقه بو مدعی نی دعوا قیلدقلری حالده سزه اوز امامکزنک اولی بالتقلید بولمق‌لغینی اثبات

حاطب‌لیل بولاسڭزکه قولڭزه عود اورنینه افعی کیرووندن‌ده خبرسز قالاسز! بس، اگر اتفاقا اصابت قیلسه‌ڭز بر ثواب یوق. اگر خطا قیلسه‌ڭز عقلڭزی، فکرڭزی استعمال ایتمادیکڭز ایچون عندالله عذاب قیلنه‌جق‌سڭز! امامجتهد، مظفر بولسه ایکی ثوابلی‌خطاٴ قیلسه‌برثوابلی‌در. بس اجتهادڭ استقبالی، تقلیدڭ استقبالندن امین‌رکدر.

درست، اگر بو مسئله‌ده صواب، معین امامڭز ایله، باشقه‌سی ایله دگل دیوب بیلسه‌ڭز! اول وقت صواب‌غه اقرب بولور؛ لکن بونی بیلو مطلقا حجت ایله اولاچغندن، سز بو وقتده مقلددگل، بلکه دلیله اتباع ایتمش اولاچق سڭز! ذاتا علما نزاع قیلشقان مسأله‌لرده اقرب الی‌الصواب اول مسأله‌نی قول متبوعه قایتاروب باشقه اماملرڭ همه‌سینڭ سوزینی اکثریت آنلرده بولاطوروب رد دگل، بلکه اول مسأله‌نی الله‌نڭ‌قوشدیغنچه کتاب ایله سنتکه قایتارودر.

حال‌بوکه سز ذکر قیلغان مثالده، سزه فایده دگل، بلکه سزه ضررلی اڭ بیوك بر حجت‌در. چونکه اگر بر کشی برنرسه آلورغه یاخود بریولغه کرورگه دیلاسه واول خصوصده ایکی کشی یاخود کوبراك کشیلر اختلاف قیلشوب هربری دیگری قوشقان‌نڭ خلافینی قوشسه بو وقت بو آدم بونلرڭ هیچ برینه تقلید قیلامایوب تردد ایچنده قالا وصواب‌نی ایزلارگه اوزی کرشه‌در. اگر بونلر معرفت ودیانت هم نصیحت‌ده مساوی‌بولا طوروب برسینی‌علی‌العمیا قبول‌غه اقدام‌ایلسه، یاخودمساوات‌وعدم مساوات‌نی بیلمه‌یوب‌استدلالسز، نه‌سز ضعیفرا کینی اعتبارینه آلسه اول وقت بو آدم‌نی اصابت قیلسه بیله فکرسز آحمق واعتبارسز دیوب ذم قیلنه‌در. شونڭ ایچون‌ده الله‌تعالی‌حضرتلری دلیلسز علی العمیا برامام‌نڭ سوزینی قبولدن منع وقول مختلفین‌نی ترجیح ایچون خارج دن بردلیل ایزلاو ایله امرایلمش‌در. ایمدی بز سزدن صورایمز: سز سلف‌دن، خلق‌دن هربر عالم‌گه تقلیدنی‌می یاخود فقط بعضی سنه تقلیدنی‌می جایز کوره‌سز؟ اگر هربرسینه

وقضاسینه اتباع، معین لازم‌در، بونی سز مقلدلرده انکار قیلاچق دگل‌سگز ! بس معین بر امامه تقلید لازم بولور، شول وقتده، اگر آنگ هر بر حکمی، الله ایله رسولینگ حکمی‌نه طوغری کیلسه؛ حال بوکه بویله بر آدم اماملر آره‌سنده دگل، بتون اضحاب آره‌سنده‌ده یوق ایدی. ابوبکر شهید ایچون دیت وارلغینی بیلماگان ایدی، عمر سوزینه قایتدی. عمر سنده میت آنلرده میت، مفادنده‌غی آیتدن غفلت قیلمش ایدی، ابوبکر سوزینه قایتدی. عثمان اقل مدت حمل‌نی بیلمامش ایدی، ابن عباس سوزینه قایتدی. علی ابن‌نگ شهادتی آتاسی فایده‌سنه مقبول دگل‌لکینی خاطرلامامش ایدی، شریح سوزینه قایتدی. بونگ کبی، باشده بیلمایوب‌فتوی ویردکلری حالده صوگره بیلگان آدملرنگ سوزلرینه قایتولر اصحاب آره‌سنده بك کوب صاناب‌غینه بیترورلك دگل‌در. «ابن قیم بوراده دخی بعض مسأله‌لرنی ذکر قیلسه‌ده اختصارا ترك ایلدك» ایمدی آگلاشلدی: هر بر حکمی الله ایله رسولینگ حکم وقضاسینه طوغری کیلان بر آدم اصحاب آره‌سنده‌ده بولنمامش‌در. بس سزگ اماملریگزده‌ده الله ایله رسولی‌نگ قضالرندن بعضی‌لرینگ خفی قالمقلغی طبیعی‌در. مونه شوشی صورتده یعنی، امر الله وامر رسول امامگزه خفی قالوب یاگمش فتوی ویردیکی وقتده یا آنگ فتوی‌سنی رد وقبول سزنگ اختیارگزده قالور یاخود اختیارگز کیسلوب الله ورسولی قضا قیلغان شی‌نگ عینی ایله عمل واجب بولور؟ مونه بو بر سؤال‌در، که سزنگ آگا بر جواب شافی‌گزده یوق‌در؛ حال بوکه سزنگ بحثگزده ذکر قیلدیغگز بر کشی‌نگ اوزندن اعلم بولغان بر امام‌غه تقلیدنده‌گی صوابی اوز اجتهادنده‌غی صوابندن اقرب‌در دیوب، دعواگزده بك آچق برامر باطل‌در. اگر سزنگ امامگزه مثلا شافعی‌گه اوزینگ نظیری یاکه آندن اعلم بر امام مخالفت قیلسه اول وقت تقلیدگزده اصابتمی خطامی ایتدگز قایدن بیلمك کیراك؟ بو وقت سز شافعی‌نگ دیدیکی کبی

سوزی ایله الغان وقتده‌غی صوابی اوزی گینه قاراب آلغان وقتده‌غی صوابندن اقرب بولدیغی کبی، بر کشی‌نک اوزندن اعلم بولغان بر امامغه تقلیدنده‌گی صوابی‌ده اوز اجتهادنده‌غی صوابندن اقرب‌در، بز بوگا جوابده ایته‌سز که: بز تقلیدنی فقط خطادن قورقوب دگل، بلکه الله ورسولینه اتباعا منع قیلامز، چونکه الله تعالی قرآن کریمنده اهل تقلیدنی ذم قیلدی، کتاب وسنت‌نی دلیل طوطارغه وامت نزاع قیلشقان شیلرنی الله‌غه هم رسولینه قایتاروغه قوشدی، حکم یالکز الله‌نک دیب خبر ویردی، الله ورسولندن باشقه ارباب واولیاء طوطوب آنلرگ حلال دیگانلرینی حلال وحرام دیگانلرینی حرام قیلودن نهی ایلدی، رسولینه منزل شیلرنی بیلمگان آدملرنی جاهل انعام منزله‌سنده دیدی، اولی‌امرگه‌ده آنلر امر رسولگه متبع وشریعت رسولنی مخبر بولدقلری وقتده‌غینه ایاروگه قوشدی، ومشاجره واقع بولغان تقدیرده حضرت رسول‌نی حاکم قیلمایونچه وقیلغان حکمندن حرجلانمایونچه طوروب هیچ کم مؤمن بولماس دیوب قسم ایتدی، واول حضرتنک حکمینه خلاف حکم گه تقلیددن وآندن باشقه‌نی حاکم قیلودن بك زیاده قورقتدی.

مونه بوحکملر اول رسول اکرمنک حیاتنده ثابت بولدیغی کبی مماتی صوگنده هم ثابتدرلر، بوحکملره اتباع واول حضرت اکرمی حاکم قیلمقلق حیاتنده لازم بولدیغی کبی، مماتنده هم لازمدر؛ چونکه بو زمان اول رسول مصطفی‌نک شخص کریمی بولنماسه‌ده آننک هدایتی اولان کتاب ایله سنت بزم آره‌مزده سلامت باقی‌در. الله‌تعالی اساس اسلام قرآن‌نی اوزگاروسز حفظ قیلدی، وبو رسولدن صوگ باشقه رسول کیلمز، وشریعتی نسخ اولنماز دیدی، وامر رسوله مخالفت ایدن آدم‌نی فتنه وعذاب الیم ایله قورقتدی. والله ایله رسولی حکم قیلان بر ایشده مؤمنلره هیچ بر اختیار یوقلغینی بك آچق بیان ایتدی وبونی هیچ بر زمان ایله قیدلامیوب قرآن ایله سنت که اتباع اصحاب‌غه لازم بولدیغی کبی بزگه‌ده لازم بولمقلغینی آگلاتدی، بس بزه الله ایله رسولی‌نک حکم

على الحق لايضرهم من خذلهم ولامن خالفهم حتى تقوم الساعة» ديگان سوزيده تأييد قيلمقده‌در.

چونکه بو طائفه حقلقنى عالم بر طائفه‌در، صوقور تقليدچيلر اوز شهادتلرى بوينچه ده اهل علم‌دن دگل‌درلر، والحاصل: لوازم شرعدن اولان متابعت، اقتداء ونصوص شرعيه‌نى آراى رجالگه تقديم وعلما نزاع قيلان مسأله‌لرنى كتاب ايله سنته، قايتارودر. امـا آراى رجالنگ نصوص شرعيه‌دن استغناسى وآنى كتاب ايله سنته تقديم آنسى قايا ديندن بولسون، بالعكس دين‌نى حقارتدر. درست بز بطلان تقليدكه، دليل ايتوب كتورديكمز حجت اثريه‌لرنى حامللردن راوى‌لردن اخذ ايلدك؛ لكن عالم، راوى‌غه حاكم، شاهدكه مقلد دگل، بلكه خبر صادق‌نى وشهادت عدل‌نى حجت قيلان امرالله وامر رسولگه متبع‌در. سز تمام احمق وجاهللكگزدن قدر فارق‌نى هيچ بر قارامايونچه اسم تقليدده اشتراك‌نى كوره سزده تقليدنگ نوع صحيحى ايله، نوع فاسدينه استدلال قيلاسز! وشوشلاى ايتوب اگ خبيث آدملرنگ طريقى اولان تلبيس‌نى اوستوگزه يوكلايسز! حال بوكه اگر عالمنگ راوى‌گه اتباعى تقليد بولسه‌ايدى، اصحابدن صونگ وجه ارض‌ده‌غى هر كيم حتى ايكنچى صحابه‌لرنگ روايتلرينه ايياردكلرى مسأله‌لرده اصحاب اوزلرى بيله مقلد صانالورغه تيوشلى بولور ايدى. اگر حاكم شاهدگه مقلد حسابلانسه ايدى، افندمز عليه السلام‌ده شاهد سوزى بويونچه حكم قيلغانلقدن اول حضرت صلى الله عليه وسلم‌ده «العياذ بالله» سزنگ كبى مقلد حسابلانور ايدى، بو قباحت سوزنى ايسه، ظنمچه سز اوزيگزده ايتورگه راضى بولاچق دگل سكز!

احتمال سز ايتورسز: سز تقليدنى منع قيلديگز! وطلب حقده نظر واستدلالنى لازم ايلديگز! متبوع فتوى‌سنده خطا قيلغان بولورده مقلد شوگا ايياروب خطاغه‌توشار ديه قورقديغگز ايچون، حال بوكه برشى صاتوب آلاچق كشى‌نگ اوزندن آرتق بيلان ناصح امين

آگا واروغه مجبوردرلر دیسه‌گز! ایتورمز: احتمال سزگ باشگزه توشکان بومنکر ومذموم اولان تقلید لوازم قدردن بولسه بولور؛ لکن بزبونگ لوازم شرعدن اولمایوب شرعا فساد وبطلانینی بك کوب دلیللر ایله اثبات ایلدك؛ لوازم شرعدن بودگل، بلکه متابعت وامتثالدر. بز یوغاریده اوزغان احکامنگده تقلید دگل، متابعت ایکانلگینی اثبات ایلمش ایدك. اگرسز بونیده تقلید دیوب ایتسه‌گز، بز انکار قیلان تقلید بومعنا بلن تقلید دگل، بلکه برمعین آدمگ هربر سوزینه دلیلگه مخالف بولسه بیله صوقور اوشانو معناسنده اولان تقلیددر، بونگ ایسه قایا اوزی بالعکس بطلانی لوازم شرعدن اولمقلغی بك آچق معلوم اولان برمسئله‌در. اگرتقلید، لوازم شرعدن بولسه ایدی، اجتهادده استدلال آگا ضد بولغانلقدن وضدین‌نگ برسی‌نگ ثبوتی دیگرینگ انتفاسینی تقاضا قیلغانلقدن، موضع تقلیدده استدلال واتباع حجت درست بولماز ایدی. اگر بری دیگرینه ضد اولان تقلید ایله استدلال‌نگ برمسأله‌ده ایکی کشی طرفندن یاخود برکشی‌دن ایکی وقتده اجتماعلری درست دیسه‌گز! اول وقت، اگر بوایکی‌سی مساوی بولسه‌لر سزه زمان اجتهاد منقرض دگل‌دیگان کشیلرنی سوگارگه اورون قالمای‌در.

اگر اجتهاد افضل بولسه، سزگ تقلیده کوچووگز افضلی قویوب مفضوله وارو بولادر. اگر تقلید افضل ایسه، اگ آحمق برمقلد، اگ فاضل برمستدل‌دن عندالله‌ثوابلی ودرجه‌لی‌رك بولورغه کیراك؛ حالبوکه سزگچه طریق اجتهاد، مقطوع ومنقرض بولغاچدین بوتردیدکه حاجتده یوق، بلکه‌تقلیددن استدلال واجتهادغه کوچو معصیت وبك بیوك گناه‌در، دیمك‌که بوزمان طریق علم کسلمش، حجت‌الله بیتمش ویر یوزنده براهین الهیه‌نی بیلان قالمامشدر. بونگ ایسه فساد وبطلانی کون کبی، معلوم اولان برشی‌در، که آنی افندمز علیه السلامنگ: «لاتزال طائفة من امتی

بولسه ده دلیلنی تقدیم قیلوده ده اتباع ایتملی ومجتهدلرننگ اصلی قایم اولان بوطریقدن چقسه گز آنلره اتباع اولمادیغنی بك آچق بیلملی و شوننگ ایچون اوز یگزه ضرر بویله قیاسلردن و از کچملی سگز!

اگر سز اصحاب رسول، فتح ایلدکلری بلادگ یگی مسلمانلرینه فتوی ویرورلر ولکن بو فتوی ده حقلقنی دلیلدن طلب قیلگز دیمازلر ایدی دیسه گز! جواب: اصحاب آنلره اوز رأیلری ایله فتوی ویرمدیلر، بلکه فقط افندمز علیه السلام ایتکان امرلرنی واول حضرت اکرم قیلغان شیلرنی تبلیغ ایلدیلر و (بونی بزه نبیمز عهد باغلادی بزمده سزه عهدمز اشبودر) دیدیلر. بس بونلرگ تبلیغ ایلدکلری شیلری قرآن ایله سنت رسولدن عبارتدر، که بوده نفس دلیل هم حکمدر. بناءعلیه بو حقیقتکه سزگ بوزمانده غی تقلیدگزنی قیاس قیلو حتی یاقین کتورو، بیله ممکن دگلدر؛ چونکه سز مقلدلر بوکون، اوز متبوعگزنگ سوزینی آلوب آندن باشقه هر بر دلیل وهر بر حقیقتکه انکار ایتمکده متأخرلردن آلوب متقدملرننگ هر بر سوزلرینی رد ایلمکده حتی شافعی و ابوحنیفه گه تابعلریگز آنلرگ سوزلرینه هرکیمدن آرتق قارشمقده و هر بر عصرده بولغانگز یاقیندن، یاقیننگ سوزی ایله فتوی ویرمکده وزمان نه قدر اوزاق کیتسه کلام متقدمنی شول قدر ترك قیلماقده، وشوننگ ایچون ایسکی امامرننگ کتابلرینی کتبخانه لرگزده اصلا بولندرمامقده سگز! حال بوکه اصحاب و تابعین و باشقه اسلاف صالحین هیچ برسی «سز اوزیگزه اوز آره گزدن بر متبوع طوطگزده باشقه لره التفات ایتمه گز! کتابدن، سنتدن حکم آلوب ماتاشمه گز! اگر اللهدن ورسولندن روایت قیلنغان شی، متبوعگزننگ سوزینه خلاف بولسه، اول روایتکه قاراماگز! همان متبوعگزننگ سوزی ایله اخذ قیلگز!» دیوب ایتمادکلرینی سز اوزگزده بك آچق بیلمکده سگز!

اگر سز تقلید، شرع هم قدر لوازمندندر، شول قدر، که یوغاریده غی بعض احکامده اوزدیغی کبی، تقلیدکه منکرلر بیله

قیلورغه قوشدی. تقوی‌لق دیمك اشنی بیلوب صوگره آننگ موجبنچه عمل‌قیلمق دیمك‌در. بس‌هر بر آدم اگ ایلك اسلامنگ امر ونهی‌لرینی بیلوب صگره الله ورسولینه اطاعت قیلمالی‌در. الله‌تعالی تکلیف مالایطاق قیلمادیغندن وحضرت رسولدن صوگ هیچ برامر دینی خفی قالمغان بر آدم‌ده طابلمغانلق‌دن اول‌احکم‌الحاکمین حضرتلری هر براهل‌علم‌گه بقدرالاستطاعت دوروشدقلری صوگنده خطاالانسه‌لر بیله برثواب تعیین ایلمش‌در. اگر بر آدم اوز فکرینی یورتودن بتونلای عاجز بولسه اول‌وقت‌دیلاسه نیندااین اوشانوچلی عالم‌بالشریعتکه مراجعت قیلور ومسأله‌نی آندن دلیلی بلن اخذایدر سزگ کبی، فقط بر امام‌نی مقتدابه ایتوب طوتماز وآننگ هر بر سوزینه صوقور ایياروب مشکاة وحی‌دن اعراض قیلماز.

سز، تقلیدنی‌مأمومنگ نمازده‌امامه وجماعتنگ حجده دلیله‌تبعیتینه قیاس قیله‌سز؛ حال‌بوکه مأموم نمازنی امام اوقوسون اوقوماسون وجماعت حج‌نی دلیل قیلسون قیلماسون یرینه جیتکزه چکلردر. بونلرگ نمازلری، حجلری امام‌ودلیل ایچون دگل، بلکه اوامر الهیه‌گه امتثالادر، بناءعلیه بونی تقلید دیمیه وسزگ قول امامگزه رسول‌ایتکانلك‌ایچون‌دگل، بلکه‌اول‌ایتکانلك‌ایچون‌ایياروگزنی آگا قیاس قیلمیه ممکن دگل‌در؛ اگر سز، بونی‌تقلیدصاناسه‌گز افندمز علیه السلام، عبدالرحمن‌بن عوف‌غه‌اویوب‌نماز اوقغان‌وفرض‌بولغان هجرت ایچون‌بر دلیل‌طوتقان؛ بس اول حضرت صلی الله‌علیه وسلم‌ده مقلدبولسه کیراك، سز بونتیجه‌نی‌ایتورگه‌طبیعی‌اوزیگزده راضی‌بولمایه‌چق‌سگز! بر عالم بر جاهل‌گه اویوب نماز اوقی‌در ونمازی شرعا درست حسابلانه‌در؛ لکن سز اوزیگزده داخل بولدیغگز حالده عالم‌نگ جاهل‌گه تقلیدینی درست کورن دنیاده هیچ کیم‌یوقدر؛ حال‌بوکه‌مأموم ایله‌حاجیلر مأموم‌قیلغان‌شیلرنگ‌عینینی‌قیلمقده‌وبولای‌قیلمادقلری تقدیرده تابع‌دگل‌حساب اولنمقده‌درلر. بس اگرسز تقلیدنی بوگا‌قیاس‌قیلسه‌گز اول‌وقت‌سزده‌امام‌لریگزه آنلر کتورگان‌دلیللرنی کتورودە‌وقایده‌غنه

ایچونده رسوللر انسانلرنگ اگ صادق واگ عالم واگ کامللری بولا وامتلری هم آنلری اصدق‌ناس دیوب اعتراف قیلا طوروب، الله‌تعالی آنلرنگ صدقینه آیات باهره وبراهین قاطعه قایم‌قیلمش ومدعی‌لرینی دلیل ایله‌اثبات قیلدقلری صوگنده‌غیه آنلره اطاعت ایله امر ایلمش‌در. بس بونلر وحی ایله مؤید اولدقلری حالده سوزلری دلیلسز قبول قیلنمغاچدین باشقه‌لرننگ سوزلری برهانسز بطریق اولی قبول قیلنماسقه کیراك، حجت‌که انقیاد وصاحب حجت‌ننگ سوزینی قبول بنی آدم‌ده امر طبیعی‌در؛ اگر انسان اوز حالنده قویولسه هیچ کیم‌گه طرفدارلق ایلماسه اول وقت مدعی‌سنی ادلهٔ باهره ایله اثبات ایدن آدمگ سوزینی قبول قیلمایونچه قالمای‌در؛ لکن کوب انسان برفکرگه وبرمنفعت شخصیه‌غه خدمت ایتدکلری ایچون‌شوگا‌مخالف اثباتلی برسوزنیده طاشلامقده وهر بر مسئولیت‌نی اوستلرینه آلمقده درلر.

اگرسز الله‌تعالی قوای بدنیه کبی ذهنلریده مختلف خلق‌ایلدی بس هر کیم‌نی، هر بر مسأله‌ده حقلق‌نی دلیلی ایله معرفت که‌کوچلمك‌لك الله‌تعالی‌ننگ حکمت وعدلینه موافق دگل بیت دیسه‌گز! جواب: بك درست، بز اوزمزده الله‌تعالی مسائل دینیه‌ننگ جلی‌سنی، خفی‌سنی هر کیم‌گه دلیلی ایله معرفت‌نی لازم قیلغان دیوب ایتمای‌مز، بز فقط سزنگ امامل‌ریگزنی مقتدابه طوطوغه وآنلرنگ هر بر فتوی‌سنی نصوص شرعیه منزله‌سنده، بلکه آندن‌مقدم قیلوغه واحکام‌شرعیه‌نی کتاب ایله‌سنتدن آلمایوب یالگز انلرنگ‌سوزلرندن آلوغه وبرده بیلمایونچه آنلرنگ هر بر سوزی کتاب ایله سنتدن آلنغان دیوب شهادت ویروگه‌وبونلره‌مخالف‌نه‌قدر عالم‌وفاضل‌بولسه‌ده آننگ‌سوزی کتاب ایله سنت‌دن آلنمغان دیوب علی‌العمیا دیوارغه صوغوغه انکار قیلامز وسزنگ کبی‌دین اسلامنی آرای رجال واوهام ناس‌غه مبتنی دیمایمز بلکه ایتامز که الله‌تعالی عبادینه‌بقدر الاستطاعه‌تقوی‌لق

کیتدیگز، واماملرنـگ اوزلرینه تقلیددن نهی ایدوب قول اصحاب ایله، عمل گه قوشدقلرینی بتونلای اونوتدیگز، وهیـچ‌بر مسلمـان عندنده بو امامَلرنـگ سوزلری دلیلسز مقبول دگل‌لکنی خاطریگزه‌ده کتورمدیگز، واصحاب ایله امامَلریگز آره‌سنده بر قیاس مساوات یاصادیگز! حال‌بوکه اصحاب، دین بابنده اعلم وفضل فقه ایله ممتاز ایدیلر، وحی‌نی کوردیلر، رسول‌دن بلاواسطه‌تلقی قیلدیلر، کتاب ایله سنتده بر ر مشکل چقدی ایسه، اول‌حضرت اکرمه مراجعت ایلدیلر، شونـگ ایچونده اول حضرت صلی‌الله علیه وسلم: «خیر الناس قرنی ثم‌الذین‌یلونهم‌ثم‌الذین‌یلونهم‌ثم‌یجیٔ قوم تسبق‌شهادةاحدهم‌یمینه‌و یمینه شهاته—لاتسبوااصحابی‌فلوان‌احدکم‌انفق مثل‌احدذهباما بلغ‌مداحدهم‌ولا نصیفه» دیمش وخلفای‌راشدین‌سنتنه‌اتباع ایله‌امر ایلمش‌وابن‌مسعودکه— علم ایله وابن عباس‌غه: «الهم فقهه فی‌الدین وعلمه‌الحکمة والتأویل» دیوب دعا قیلمش وبن سزه ابن‌مسعود راضی بولغان شی‌دن راضی‌یم دیدیکی کبی، ابوبکر ایله عمرگه اطاعت‌ایله‌ده‌قوشمش‌وعمرنـگ‌قوشنده‌بر قدحدن‌ایچوب‌تمام‌طویغانینی‌علم‌ایله‌یورمش‌والله‌تعالی‌حقلق‌نی‌عمردیلنده قیلدی؛ اگر بندن صوڭ نبی‌بولسه ایدی، عمر بولور ایدی دیوب، تصریح ایلمشدر. بس‌ایش بویله‌اولدیغنده اصحابه تقلیدڭ جوازندن صوڭغی امامَلره تقلیدڭ جوازی نچك‌لازم بولسون؟ حال‌بوکه شافعی اوزی اصحابه، بك‌کوب یرده خلاف‌کیتمش ایدی. بس آنلره قارشو کیتو جـایز بولغاچدین امامَلره خلاف کیتو کوبدن جایز بولورغه کیراك.

اگر سز هربر صنعت وهربر علم‌ده متعلم معلم‌گه تقلید ایته‌در، الله‌تعالی بونی فطرت انسانده رکز قیلمش‌در دیسه‌گز! جواب: لـکن بوندن دین الله‌ده تقلیدنـگ وقول متبوعنی حجتسز قبول قیلونـگ وآنی اوزندن اعلم سوزینه بیله تقدیم ایتونـگ صحتی برده لازم دگل‌در، الله‌تعالی عبادینی هربر خصوصده طلب حجت‌که مفطور ایلدیکی ایچون هیـچ‌بر انسان دلیل‌سز سوزنی قبول قیلماز؛ شونـگ

آ ڭا مخالفتلرینی و آنڭ کبی، اوزلرینڭده: «قایدن آلندیغنی بیلمایونچه بزم سوزمز ایله فتوی ویرمه ڭز!» دیدکلرینی هم شافعی نڭ: «اصحاب نڭ عقللری کوب وعلم اجتهاد وورعلری بزدن اوستون» دیه طوروب، آنلره بك کوب یرده خلاف کیتدیککنی خاطریڭزه ده کتورمایسز واماملرنڭ غیری گه تقلیدلری درست دگل دیدیکڭز وشافعی نڭ فرائض ده زیدکه تبعیتینی اجتهادنڭ اجتهادغه طوغری کیلوی بابندن دیه تأویل قیلدیغڭز حالده اوزیڭز، بوراده شافعی نی عمر، عثمان، عطاغه مقلد یصاب، بك عجب بر تناقض غه توشه سز، سز بك زیاده آحمق لغڭزدن شافعی مجتهد بولا طوروب تقلید ایلدیکی بواوچ ذاته اوزیڭز مقلد بولدیغڭز حالده ده تقلیدڭزنی درست کورممکده ومعین شافعی نی امام طوطمقده وشافعی بونلره خلاف کیتکان یرلرده مطلقا آنلرڭ سوزلرینی رد ایلمك ده واوزیڭز شافعی گه تقلید قیلامز دیه طوروب شوشلای آ ڭا خلاف وارمقده سڭز! حال بوکه بو سوزلر، بو اماملردن ثابت بولغان تقدیرده بونلر الله ایله رسولندن بر نصده بیلنمیان واقوال مختلفه اصلا ایشلمیان، بك آز مسأله لرده گینه تقلید ایدرلر، واوزلرندن عالم صانادقلری بعض بر آدمڭ سوزینی قبول قیلورلر، وشوشلای ضرورت وقتنده تقلیدنڭ درستلکینی کورساتورلر ایدی. سز ایسه بو یولنی بتونلای قویدیڭز، کتاب ایله ایله سنتدن دلیللر کورنه طوروب تقلیدنی اختیار ایلدیڭز، گویا مذبوح اورنینه میته نی رأس مالڭز کبی قبول ایلدیڭز! ودورلی، دورلی بوزوق تأویللر ایله مقصدڭزنی ترویج قیلورغه دوروشدیڭز! حتی امام شافعی نڭ: «رأی اصحاب، بزم ایچون اوز رأیمزدن خیرلیدر» دیگان سوزی بلن دلیل ایستاب: «بس رأی ائمه ده بزم ایچون اوز رأیمزدن خیرلی رك در» دیمیه قدر، جسارت ایلدیڭز! واوزیڭز ایسه اصحاب غه تقلید بدلینه ابو بکر، عمر، عثمان، علی سوزلرینی طاشلاب شافعی گه ایبارەرك آنڭ بو سوزینه خلاف

زمان اجتهاد منقرضمی دگلمی؟ ٤

تقليد جيولغان ، اگ عالمنى انتخابدن كتاب ايله سنت دلالت ايدن شيئى معرفت بيگلرچه دفعه اسانراقدر . بويله شرطلرنى جامع بر كشينى خصوصا بوقدر مجتهدلر آره‌سندن طابو صوقور طاوق كبى اولان مقلدكه دگل ، راسخ فى العلم گه‌ده ممكن دگلدر . اگر بز ديلسه‌ك قايسى سنه تقليد ايله مكلف اولسه‌ق اول وقت اسلام ، امر الله وامر رسوله دگل بلكه بزم ايسته‌ك وشهوتمزه تابع بولوب چغه‌در ، كه بونى ايتورگه ، سز اوزيگزده راضى بولاچق دگلسگز ، وشولاى بولا طوروب اوزيگز آيت وحديثلردن اعراض وكيفگزه قاراب حكم قيلمقده‌سگز ! افندمز عيله السلام ، عقبه بن الحرث كه : « بر بن سنى‌ده قادينگ نى‌ده ايمزدم » ديگان قادينڭ سوزينه اوشانورغه وقادينينى آيرورغه قوشديغى حالده سز ، اول حديثدن اعراض قيلمقده وبويله برقادينينى ايرينه حلال ديوب فتوى ويرمكده ، وآنگ اوستينه‌ده اوزيگز بوحديث ايله تقليدكه دليل ايستاب عيني برحديث‌نى ثابتده غير ثـابتده قيلمقده سگز ! حال‌بوكه بوايشنگ تقليد اولمايوب شاهدنگ شهادتى كبى ، امرحسى‌دن خبرنى قبول اولمقلغى وعقبه‌نگ‌ده قادينينى هيچ كيمه ايـاروب دگل ، بلكه فقط افندمز عليه السلام‌نگ سوزى بويونچه ايرمقلغى ، بك آچق معلوم اولان بر مسأله‌در .

سز محمد بن حسن‌نگ : « عالمگ كندى مثلينه تقليدى درست بولماسه‌ده اوزندن عالم گه تقليدى درستدر » وشافعى‌نگ : « بن بونى عمرگه وبونى عثمانه‌وبونسينى عطاغه تقليدا ايتدم ديگان » سوزلرينى‌ده نقل قيلاسز ، وشونگ ايله اماملرده تقليدنى جايز كورگانلر بيت ديوب دليل ايستاى‌سز ، اما اصحاب وتابعين‌دن اوزلرينه هم باشقه‌لره تقليدنى ذم ومنع خصوصنده نقل اولنان حسابسز سوزلره هيچ بر التفات ايتماى‌سز ، واوشبو اسملرينى ذكر ايلديگگز ؛ محمد بن حسن ايله شافعى‌نگ تقليدكه بك زياده‌انكارلرينى ودليلدن غيرى گه اتباعنى اصلاقبول قيلمادقلرينى وكتاب ايله سنتدن باشقه‌غه‌هيچ بر اندامدكلرينى وابو حنيفه ، محمد ايله ابويوسف‌دن اعلم بولديغى حالده بونلرگ

اما صکره برزمان کیلدی، دینده فرض اسمی ایله درلو بدعتلر چقدی، اصولده فروغده اغلوطات کوبایدی ده اسلام طـانلماز، آکلاشلماز وعمر بویونچه اویرانوبده بیلنماز برحاله کیلدی. مونه بونلر هروقت آرطوب کیلدی وهمان آرتمقده‌درلر؛ امااساس دین هیچ‌بروقت آرطه‌چقده کیمویه‌چکده دگل‌در. بز بواغلوطات‌نی دگل بلکه اسلام‌نی‌بیلوایله مأمورمز، مادامکه هربر مسلمان اخباررسول‌نی تصدیق واوامر الهیه‌گه اطاعت‌ایله مکلف‌در ومـادامکه‌بوخبرلرنی، امرلرنی بیلمایونچه اطاعت ممکن دگل‌در. بس بونلرک همه‌سینی‌بیلو هربر مسلمانه واجب‌در. دین ودنیـامزی حفظ واحوالمزی اصلاح بوشیلره توقف وبونلری اهمال هربرایشمزی افساد ایتدیکندن الله آنلری بزه‌مرحمة فرض ایلمش‌در. برمملکت وبرشهرنـک معموریتی واهالی‌سینک صلاحی علم سببلی وخرابلغی واهـالی‌سنک فسادی جهل سببلی‌در، علمسز آدم حیوان کبی‌در، آنلرک علم‌گه احتیاجی طعام وشرابغه احتیاجدن کوبرك‌در، انسان طعام ایله شراب‌غه‌یومی،فقط ایکی اوچ دفعه محتاج بولدیغی حالده؛ علم‌گه هر ساعت وهردقیقه محتاج بولمقده‌در، عالم آدمنـک دینی ودنیوی هیچ بر مصلحتی یوغالمز وهیـچ برصنعتی وتجارتی معطل قالمز، بلکه بونلرک ضیاعی واوامر الهیه‌نـک هم نظردن دوشووی اصابتده، خطاده قیلا طورغان بر کشی‌نـک هربر سوزینه علی‌العمیا تقلیدده‌در. بس الله‌تعالی‌نـک‌بزی تقلید ایله دگل بلکه نظر واستدلال ایله تکلیف قیلمقلغی بزه کمـال شفقت ومرحمتندندر. اگر بز تقلید ایله مکلف اولسه ایدك، دنیا وآخرت مصلحتلرمزنـک هیچ برسی قالماز، همه‌سی ضایع اولور، بتار ایدی. چونکه اسلام بتون شرق ایله غرب‌نی طوطورغانلقدن ومفتیلر، فقیه‌لر بك زیاده کوبایگانلك‌دن؛ اگر بز بونلرک همه‌سینه تقلید ایله مکلف اولسه‌ق؛ بونلری طابوب بترو ممکن اولمادقدن ماعدا برشی‌نی، حلالده، حرامده، واجبده، ساقطده قیلمق لازم بولادر. اگر بونلر آراسنده اک عالمینه تقلید ایله مکلف اولسه‌ق شروط

ایيارمکده و کتاب ایله سنته خلاف اولسه بیله آنک سوزینی قبول ایلمکده‌سکز! همده یهوددن یا که نصرانی‌دن یاخود فاسق‌دن ایتلرنی، کییوملرنی و طعاملرنی صاتوب آلغان وقتده بونلرک سوزی ایله کفایه‌لنوب حلیت و اسباب حلیت‌نی تیکشرمازسزلکمزده صوقور تقلید دگل بلکه‌الله‌نک امری و حضرت عائشه‌نک: «یارسول‌عالم! بعضیلر ایت‌کتوره‌در تسمیه‌سی وارمی، یوقمی معلوم دگل آشایقمی؟» دیگان سوزینه قارشی اول حضرت صلی الله علیه و سلم نک: «سموا انتم و کلوا» دیگان سوزی ایله عمل‌در. حال بوکه اگر سزک بو استدلال‌لریکز درست بولسه ذبایح ایله اطعمه‌ده کفار هم فساقه و کیردیکه قویو ایله قان کیسلونده کافره هم فاسقه‌یه تقلید درست بولدیغی کبی بونلره باب دینده‌ده تقلید درست بولورغه کیره‌ك. بس سز بوسقیم یولکزنی قویکز، اقوال رجاله تقلیدی قویوب کتاب الله هم سنت رسول الله‌غه قایتوکز! مونه شول وقت اوزیکزده مسعود بولورسز، و امتی هم‌سعادتکه اولاشدیررسز!

اگر سز، اگر آدملر همه‌سی اجتهاد ایله‌مکلف، اولسه‌لر ایدی مصالح عبادده یوغالور وصنعتلر هم تجارتلرده معطل قالور ایدی، بوگا ایسه شرعاده، عقلاده یول یوق‌بیت دیسکز! جواب: هر کمگه واجب اولان شی اوزینه خاص بولغان حکم‌لرنی‌گینه بیلودر، بو حکملر ایسه فقط حضرت رسول کتورگان علوم دینیه‌دن عبارت اولغانلقدن مصالح عباد یوغالورلق‌وصنعتلر، تجارتلر معطل قالورلق کوب‌دگل، بلکه‌اصول‌احکام‌ده‌فقط‌بش‌یوز حدیث‌مقداری، بك آز وبك جیکل‌در. شونک ایچون الله تعالی: «ولقد یسرنا القرآن للذکر فهل من مدکر» دیوب، اسلام‌نک جیکل‌لکنی بیان قیلدیغی کبی، اصحاب کرام‌ده هر بر مصلحتلرینی،معاشلرینی‌ایگنلك، طووار، صاتو وبازار اشلرینی همه‌سینی قارای طوروب اوزلرینه کیرا کلی دین ایشلرینک بارسنی‌ده بك آچق بیلمشلردر.

سوزینه واروب افندمز علیه السلامدن : ( لوکنت متخذا من اهل الارض خلیلا لاتخذت ابا بکر خلیـلا ) دیگان سوزنی نقل قیلدی ؛ لکن ابن‌زبیر آگاصوقر تقلیدایله ایپارمدی بلکه‌دلیلی قوتلی بولغانلق ایچون آنک سوزینه واردی وصدیقنک کوب وقت سوزی طوغری چققانلق‌غه اشارت ایچون بوحدیث‌نی نقل ایلدی. حال بوکه ابن زبیرنک خطا احتمالی اولغانلقدن آنک بوسوزی تقلید خصوصنده بولسه بیله آنی دلیل ایتوب طوطو درست‌دگلدر. والله‌تعالی‌نک‌شاهدسوزینی‌قبول‌قیلورغه‌قوشووی‌تقلیدکه‌دلیل‌بولورغه دخی صالح دگلدر. چونکه شاهدنک شهادتینی قبول‌قیلـگز دیوب حاکملرگه الله تعالی قوشدیغی کبی افندمز علیه السلام اوزیده قول شهود ایله حکم ایلدی.

بس بز،شاهدنک سوزینی مجرد اول شهادت ویرگان ایچون دگل، بلکه الله ورسولی قوشقانلق ایچون قبول قیـلامز. اما سز امامکزنک سوزینی صاحب شرع قوشقانلق ایچون دگل، بلکه اول ایتکانلك ایچون مقدس صانایسز؛ بناءً علیه بو مسئله‌نی کتاب هم‌سنتدن اعراض ایده‌رك آرای رجاله تقلید خصوصنده دلیل‌ایتوب طوطووگز بك عجب وبك بیوك آحمق‌لقدر هم‌شریعت‌نک :«قاسم ومقوم سوزلرینی، صوقرنک قبله‌ده ودخول وقتده باشقه‌لره ایپاروویني، آدملرگ دخول وقتده وفطر ایله صومده مؤذن‌گه قاراولرینی، ترجمهٔ رسالت‌ده هم تعدیل وجرح‌ده اتباعني، هدیه‌ده، زوج یانینه زوجه‌سنی کرتوده وحیض قانی‌نک کیسلوونده بر قادین‌نک سوزینه اشانونی» قبول کورمکلکی‌نی تقلیدکه دلیل ایتوب طوطووگزده آندن کیم آحمقلق دگلدر. چونکه بونلر حسلری ایله سیزوب معین بیلدکلری شیلردن خبرویره‌لر. صاحب الشریعه ایسه ظاهرالصدق والعدالت اولان مخبرگ خبرینی قبول قیلورغه قوشه‌در. بس بونلره اتباع الله ورسولی‌نک امرلرینه موافق هم علم‌گه اتباع‌در. سز ایسه مجرد ظندن خبر ویرگان برکشی‌گه

سز، علمی، جهلی غیر معلوم اوز اصحابڭزه تفویض قیلمقده‌سڭز!

درست، افندمز علیه‌السلامڭ حیاتنده بیله اصحاب کرام فتوی ویرورلر و فتوی صوراوچیلر هم آنلره اییارورلر ایدی؛ لکن بونلرڭ فتوی‌لری الله و رسولی‌نڭ احکامینی تبلیغ‌دن عبارت اولدیغی کبی، صوراوچیلرده نصوص‌غه خلاف بولا طوروب صوقور تقلید قیلمازلر؛ بلکه رسول بونی قوشدی و بوندن طیدی دیگان سوزلره گینه ایيارورلر یعنی مفتی‌لر، اول حضرت صلی الله علیه و سلم‌دن بلاواسطه ایشتکان شی‌نی مستفتی‌لر بالواسطه ایشتورلر ایدی یاخود مفتی بر فتوی‌نی ویروب افندمز علیه السلام آنی تقریر قیلور؛ اگر اول فتوی خلاف سنت ایسه زانی بکرنی رجم ایله فتوی ویرن آدمه انکار قیلدیغی کبی، آنی رد و منع ایدر ایدی. والحاصل: اساس کتاب ایله سنت ایدی. سز ایسه بونلردن اعراض و فلانلره اتباع قیلمقده‌سڭز!.

اگر الله تعالی: «فَلَوْلَا نَفَرَ مِنْ كُلِّ فِرْقَةٍ مِنْهُمْ طَائِفَةٌ لِيَتَفَقَّهُوا فِي الدِّينِ وَلِيُنْذِرُوا قَوْمَهُمْ إِذَا رَجَعُوا إِلَيْهِمْ» دیوب، آنلرڭ تنذیرینی قبول قیلارق تقلید ایتونی واجب ایلدی بیت دیسه‌ڭز! ایتورمز: بو آیت جهـاد ایچون غائب اولدقلری وقت نازل اولان انذار آیتلرینی قبول خصوصنده‌در. سزڭ وهمڭز کبی، آرای رجالنی وحی‌گه تقدیم بو آیتدن اصلا آڭلاشلمایدر. حتی تفقه دیمك دلیل ایله بیلو معناسنده اولغانلقدن بو آیت اوزی دلیل‌سز انذار، انذار دگل‌لك‌نی آڭلاتمقده و تقلیدنڭ بطلانینه دلالت قیلمقده‌در. چونکه سز، تقلیدنی بر کشینی مقتدابه طوتوب آنڭ سوزینی دلیلسز بولسه‌ده قبول و باشقه‌لرنقینی دلیل‌لی بولسه‌ده رد قیلو معناسنده اخذ قیلمقده سڭز!

درست، ابن زبیر، جدایله اخوه حقنده صورالدقده؛ ابوبکر

وسنت رسول‌ده نظری درست دگل بلکه آ کالازم تقلید ایلدیکی کشی نک سوزینه اتباعسی‌در. دیلاسه بوسوز کتاب، سنت هم اقوال صحابه‌گه مخالف‌ده بولسون؛ اگر مفتی قوتلی دلیل طابدم اعتقادی ایله امامی‌نک سوزندن کوچسه، منصب فتوی‌دن عزل اولنور» دیو گه قدر جسارت ایلدیلر.

اگر، ام‌ولدنی بیع‌دن نهی هم طلاق ثلاث خصوصلرنده اصحاب، حضرت عمرگه تقلید قیلدیلر بیت دیسه‌کز، جواب: یوق تقلید قیلمادیلر بلکه بعضیلری ابن‌مسعود کبی، ام‌ولدنی بیع حقنده و ابن عباس کبی طلاق ثلاث خصوصنده حضرت عمرگه خلاف کیتدیلر وایپارگانلریده صوقور تقلید ایله دگل، بلکه اوز اجتهادلری شوکا وارغانلق ایچون اتباع ایلدیلر. درست حضرت عمر اختلام بولدیغنده عمرو بن‌عاص آکا تبدیل‌لباس ایله توصیه قیلمش ایدی اول‌حضرت ایسه اگر تبدیل ایلسه‌م سنت بولور دیوب رد ایلدی. لکن بو ایشنی عمر، رسول‌دن کورمایونچه‌یا که ایشتمایونچه قیلمازدیه‌رك آدملرک اتباع سنت‌دن قورقوب رد ایلدی؛ بناء علیه بو واقعه‌لردن کتاب سنت مقابلنده بیله حضرت عمرگه تقلیدنک جوازی اصلا آکلاشلمایدر. حال‌بوکه بو تقلید ثابت بولغان تقدیرده حضرت عمرگه تقلیدنی اثبات ایته‌در. سز ایسه آندن وآنک سوزندن اعراض ایدوب فلان وفلانلرنی اصل ایدوب طوتمقده‌سکز!

درست، حضرت ابی‌نک: «ما اشتبه علیك فکله الی عالمه» دیگان سوزی وار، درواقع بر آدم، کتاب ایله سنت‌دن طابمادیمی وقیاس‌غه کوچی یتمادیمی، آنی عالمینه تفویض قیلو معین تیوشلیدر؛ لکن بوسوزنک تمامی یعنی: «ما استبان لك فاعمل به وما اشتبه علیك فکله الی عالمه» دیگان سوز دلالت قیلدیغنچه سنت ظاهر بولغان یرده، تقلید جایز دگل، بلکه سنته اتباع لازمدر. سز ایسه بك ظاهر سنتلری قویوب امامل‌رگزه تقلید ایلمکده سکز! واشتباه واقع اولان مساله‌لرنی‌ده، آنلری اک عالم اصحابه تفویض تیوشلی بولغانی حالده

هیچ ممکن اولمیان بر یولنی کورساتمکده‌درلر. چونکه مجتهدننگ کتاب
ایله سنتدن مقصود آڭلاوی بوحکم گه علمای شرق وغرب همه‌سی
اتفاق قیلغان دیوب بیلودن بیک دفعه آساترا قدر. احتمال بوحکم‌ده
اختلاف بولور؛ لکن مجتهدگه واصل بولماز عدم علمنی دلیل ایتوب
طوتمق‌لق اصلا ممکن دگل‌در. الله‌تعالی وصولی آغر اولان بویله
اشلر ایله تکلیف‌دن البتة منزه‌در. کاشکی مقلدلر بویله مشکوک بر شی گه
مراجعت قیلغانچی، بك آچیق اولان کتاب ایله سنت که یابشسه‌لر ایدی،
معین، بك کوب مرتبه آرتق استفاده قیلورلر ایدی. حال‌بوکه بونلرنڭ
بعض‌لری صحت اجماعده انقراض عصر مجمعین‌نی شرط ایلمکده‌درلر، که
بوتقدیرده اول عصر اوزوبده هیچ برخلاف ظاهر بولمغانینی
بیلمایونچه طوروب اجماع ایله دلیل استاو ممکن دگل‌در. الله‌تعالی
قوللرینه اینه ایله قیو قازو کبی مشکل وبك شکلی بویله بر یولنی
کورساتودن منزه‌در. مونه مسلمانلر کتاب ایله سنت کبی ظاهر
بر یولنی قویوب، اشبو چیغلماز یولغه کردکلری ویوق اجماعلرنی
دعوا قیلدقلری وشول اجماع مجهول ایله مغارضهٔ نصوصه قدر
واردقلری ایچون بوقدر فرقه‌لرگه آیرلدیلر؛ حال‌بوکه امام محمد
ایله بشر المریسی: «اجماعنی دعوا ایدن آدم یالانچی‌در، احتمال آدملر
اختلاف قیلمشلردر» دیمش. وبعضیلر: «مخالفنی بیلمایمن دیورگه
ممکن؛ اما اجماع قیلدیلر دیورگه ممکن دگل» دیو تصریح ایلمشلردر.
ائمهٔ اسلامدن بو مفادده باشقه سوزلرده نقل اولنمش‌در، آنلرنڭ
همه‌سی‌نڭ مسلکی کتاب ایله سنت‌نی اجماعغه تقدیم ایدی. امام شافعی
هم ابو حاتم الرازی دلیل‌نی، اڭ الیك کتاب، صڭره سنة ثابته، صڭره
اجماع واتفاق ائمه دیوب، اقوال فقهاغه کتاب ایله سنتدن دلیل طابلمغان
وقتده‌غینه وارونی جایز کورمشلردر. طهارتدن تیمم گه وارو کبی، که
اول‌ده طهارتدن عاجز بولغان وقتده‌غینه جایزدر، لکن بونی صوڭغی‌لر
آڭلامدیلر، طهارتدن عذرسز تیمم گه کوچکان کبی، کتاب ایله
سنت‌دنده عذرسز اقوال فقهاغه کوچدیلر، حتی: «مفتی‌نڭ کتاب الله

منكم بعدی فسیری اختلافا کثیرا » دیوب ، مختلفین‌نی ذم قیلدیغی حالده سز صوقور تقلیدکز ایله اختلافلرنی کوبایتدیکز ، دین‌نی آیردیکز ، دورلی دورلی شیعه‌لر یصادیکز ، اوزیولکزنی مدح وباشقه‌لرنی ذم که طوطوندیکز ، کتابلرمز ، دینمز ، نبیمز همر بمز بر بولا طوروب ایکنچی مذهب سوزی ایله عمل درست دکل دیه‌رك آنلری بتونلای ملت اخری کبی ، عدایلدیکز ؛ اگر سز تقلید وتعصب‌نی قویوب آره‌مزده کتاب وسنت‌نی حاکم ایلسه‌کز و آره‌مزده مساوی اولان اشبو کلمه‌ده جیولسه‌کز و بعضکز بعضیکزنی من‌دون‌الله‌ار باب‌ایتوب طوطمه‌سه‌کز ایدی ، معین بونزاعلر آزایور و بوقدر افتراق‌لر قالماز ایدی .

درست حضرت‌عمر ، شریح که : « کتــاب‌الله ایله ، آنده بولمسه سنت رسول ایله و آنده‌ده بولمسه صالحلر حکم‌قیلغان شی‌ایله حکم قیل ! » دیوب ، یازدی ؛ لکن بوسوزده کتاب‌ایله سنتده طابلماسه‌غینه اقوال صحابه که‌هم‌باشقه‌لره بارونك‌جوازینی بك‌صریح آکلاتدیغندن قایاتقلیدک‌لهنده اولسون ، بالعکس‌تقلیدک علیهنده‌بك آچیق دلیلدر . مونه اصحابك طریقی اشبودر ، وحضرت عمرك بوسوزی شول اسلاف کرام سیراتینی تعیین ایده‌در . صکره بر زمان کیلدی بعضیلر بر حادثه ظاهر بولدیسه کتاب‌ایله سنت‌که مراجعت قیلمایوب واقوال صحابه‌که کوبدان قارامیوب حتی کتاب‌ایله سنت‌که مخالف بولسه بیله‌فلان وفلانلرك سوزلرینی آلاباشلادیلر وبعضیلر : « اگر مفتی‌که بر برحادثه کورنسه اك‌الیك بومفتی‌شول حادثه‌ده‌گی اقوال‌مجتهدین‌نی قارار ، اگر اختلافلری بولماسه کتاب‌ایله سنت‌که قار اماز بلکه اجماع ایله اخذقیله‌رق شونك‌ایله فتوی ویرور ، اگر اختلافلی ایسه ، قایسی سوز دلیل‌که اقرب شونك ایله‌اخذ وحکم قیلور » دیوب ، تصریح‌ایلدیلر . حال‌بوکه بوسوز معاذنك حدیثینه وعمرنك کتابینه وبتون اقوال‌صحابه‌یه وصریح کتاب‌ایله ظاهر سنته‌مخالفدر . بونلر آدمله‌ره مقدور اولغان یولنی کورساتدکلری حالده ، بومقلدلر

استنان ایله قوشدیغی آدملر، خیر خلق و اعلم امت اولان اصحاب کرام ایدیلر، سز ایسه آنلره تقلید اورنینه آنلردن بك کوب درجه کیم اولان فلان وفلانلره تقلید قیلمقده سکز! حال بوکه استنان اقتدادیمکدر اصحابه اقتدا بولادر، آنلر قیلغان شی نك مثلینی ایتان ایله آنلر هیچ کیم نك سوزینی دلیلسز قبول قیلمدیلر، حتی باشقه صحابه‌لر کبی، ابن مسعود او زیده تقلیددن بك صریح منع قیلمش ایدی. بس آنك بو سوزنده‌گی استناندن مرادی البته صوقور تقلید دگلدر. بناء علیه اصحاب کبی سزده هیچ کیم نك سوزینی دلیلسز قبول قیلمز سزلق لازمدر، اگر سز افندمز علیه السلام نك: «علیکم بسنتی وسنة الخلفاء الراشدین المهتدیین من بعدی» هم «اقتدوا بالذین من بعدی» دیگان، سوزلری ایله دلیل ایستمك چی بولسه گز بو حدیثلرده سزگ لهگزده دگل، بلکه علیهگزده‌درلر؛ چونکه آنلر آره‌سنده بر سنت ظاهر اولغان وقت آنك خلافی اولان قول گه تقلید ایدن هیچ کیم یوق ایدی بس سزگ تقلیدگز آنلرگ سنتینه خلافدر. بوندن ماعدا افندمز علیه السلام وجوب اتباعده خلفای راشدین سنتنی اوز سنتینه مقارن قیلدی، بس بونلرگ سنتی ایله اخذ بونلره صوقور تقلید دگل؛ بلکه اول رسول اکرم نك سوزینه اتباعدر؛ حال بوکه سز بو حدیثده صراحة ذکر قیلنغان خلفای راشدین گه دگل، بلکه شافعی لرغه، حنفی لرگه تقلید ایتمکده، حتی بعض علماگز بونلر قارشوسنده خلفای راشدین گه تقلید درست دگل، دیمکده سکز! بس سز بو صوقور تقلیدلریگزده بو حدیثلره موافق دگل بلکه مخالف سکز. بو حدیث کثرة اختلاف وقتنده افندمز علیه السلام ایله خلفای راشدین نك سنتلرینه تمسك ایله قوشدیغی حالده سز، فلاننك رأیینه وفلان نك مذهبینه یابشورغه قوشاسز، بو حدیث محدثات اموردن قورقوتوب هر بر محدث بدعت وهر بر بدعت ضلالت دیدیکی حالده، سز تقلید ایدوب وفلان نك قولینی کتاب ایله سنت که بیله تقدیم ایدوب، اك بیوك واك قبیح بدعتلرگه دوشدیگز، بو حدیث ایچنده: «فانه من یعش

بلکه علیهنده دلیلدر. اگر بو آیتده گی اتباع، سز ایتکانچه صوقور تقلیددن عبارت بولسه ایدی، ابو یوسف ایله‌محمد، ابو حنیفه‌گه و بخاری ایله مسلم کبی اصحاب‌احمد، احمدنڭ أوزینه بك کوب یرده خلافلق قیلغانلر. بس‌جاهل وصوقور تقلیددعواسنده بولنان سزڭ ابو حنیفه ایله احمدگه اتباعڭز آنلرڭ اتباعلرندن قوتلی‌راك بولسه کیراك. سز بونی ایتورگه طبیعی اوزڭزده جسارت قیله‌میه‌چق‌سڭز!

اگر سز افندمز علیه السلامنڭ: «اصحابی کالنجوم بایهم اقتدیتم اهتدیتم» دیگان سوزی، صحة تقلیدده صریح بیت‌دیسه‌ڭز، جواب: بو سوز افندمز علیه السلام‌دن‌ثابت دگل، ثابت‌بولغان‌تقدیرده سز اوزیڭز نجومنی قویدڭزده آنلردن بك کوب مرتبه کیم‌بولغان کشیلرگه تقلیدنی اختیار ایلدیڭز و ائمهٔ اربعه‌گه‌تقلیدنی خلفاء اربعه‌گه تقلیددن‌اولی کوردیڭز وشوشلای‌ایتوب‌حدیث بك‌صریح دلالت‌قیلغان شی‌گه‌خلاف کیتدیڭز؛ حال‌بوکه اصحاب آره‌سنده‌بك‌کوب حکملرده اختلاف وار ایدی، بعضیلری طلاق ثلاثنی بر دیدکلری حالده، بعضیلری اوچ دیمشلر ایدی. (ابن‌قیم‌بوراده دخی اون آلتی‌اختلافلی وتناقضلی حکملرنی صانامشدر. بز اختصارا آنلری ترك‌ایلدك) ایمدی سز، اگر بونلرڭ همه‌سینه اتباعنی درست کورسه‌ڭز اول وقت دیلسه کیم دیلسه‌قایسی سوزنی آلسون اختیارلی بولورغه ومذهبڭزگه خلاف کیتکان کشیلرنی آچولانمازغه‌کیراك، اگر بونلرڭ همه‌سینه اتباعنی درست کورمسه‌ڭز اول‌وقت بوحدیث‌نی بوزغان و آڭا خلافلق قیلغان‌کشی اڭ‌ایلك اوزیڭز بولاسز؛ بناءعلیه بوحدیث‌نڭ ثبوتی‌ده سزه فایده دگل بلکه‌ضرردر.

اگر سز عبدالله بن‌مسعودنڭ: «من کان مستنا منکم فلیستن بمن‌قدمات اولئك اصحاب‌محمد.» دیگان سوزی‌بلن دلیل‌ایستامکچی بولسه‌ڭز، جواب: بو سوزده سزڭ فایده‌ڭزه دگل، بلکه ضررڭزه دلیلدر، چونکه بو سوز احیاغه أستنان‌دن طیمش ایدی، سز ایسه احیا و امواتنڭ همه‌سینه تقلیدایده‌سز، بوندن ماعدا ابن‌مسعود آنلره

طوروب اوزلرینه تقلیددن نهی ثابت اولمشدر. ایمدی اگر بونلرنك بوسوزلرینه اطاعت واجب بولسه تقلیدکز باطل، اگر واجب بولماسه استدلالکز فاسددر، حال بوکه الله تعالی بونك اوستینه: «فَاِنْ تَنَازَعْتُمْ فِی شَیْءٍ فَرُدُّوهُ اِلَی اللّٰهِ وَالرَّسُولِ اِنْ کُنْتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللّٰهِ وَالْیَوْمِ الْآخِرِ» دیه رك، متنازع فیه ومجتهد فیه اولان مسأله لرنی کلام الله وسنت رسولدن باشقه هربر رأی وهربر مذهب که رد وتقلیددن منع ایلمشدر. بناءً علیه اولی امرگه الله ورسولی خبرویرگان شیلرده گینه اطاعت لازمدر. بس بو وقت بونلره اطاعت اصالة، الله ورسولینه اطاعت بولوب چغادر. مع مافیه بو وقت ده ده سزظن قیلغانچه اولی امرگه اطاعت معناسی قالمای دگل، بلکه همان قالا، وبونص غه اگ موافق تبعا اطاعت معناسی قالادر، چونکه بو نص بونلره اصالةً دگل بلکه تبعا اطاعت ایله امر ایله مش وشونك ایچون عاملنی قایتارمایوب طاعة رسولگه مقارن کتورمشدر. اما رسولگه تبعیت اولی امرگه تبعیت کبی، تبعا دگل بلکه اصالة ایکانلگینی آڭلاتو ایچون آنسینی عامل ایله افراد قیلوب کتورمش وقرآنده بولسون بولماسون امر رسولگه اتباعنك لزومینی آڭلاتمشدر.

اگر سز الله تعالی مهاجرین ایله انصاره متابعت ایدنلری «وَالَّذِینَ اتَّبَعُوهُمْ بِاِحْسَانٍ» دیوب، ثناقیلدی بونلره باحسان اتباع، تقلید بیت دیسه کز جواب: یوق برده تقلید دگل بلکه آنلرنك نهجلرینه سلوکدر. چونکه آنلر تقلیددن نهی قیلدیلر، ومقلدنی اهل بصیرتدن دگل دیدیلر، آنلر آره سنده بو مقلدلر مذهبنده بولنان بر کشی ده یوق ایدی، آنلر نصوص شرعیه نی آراء رجالگه قایتارودن بك یراق ایدیلر. بس بونلره باحسان تابعلر شونداین عالملردر، که آنلر کتاب الله وسنت رسول الله غه هیچ کیمنك سوزینی مقدم قیلمازلر وهیچ کیمگه علی العمیا تقلیه ایلمازلر، بس بو آیت سزایتکانچه تقلیدنك لهنده دگل

کشیلرنگده سوزلرینی قبول قیلمقدهسگز! وبو بوزوق یولگزغه حضرت رسولنگ: «قدسن لکم معاذ فاتبعوه» دیگان سوزی ایلهده دلیل ایستمکدهسگز! حال بوکه بو حدیثنگ معناسی معاذگه هر بر ایشنده اتباع قیلگز دیمک دگل، بلکه افندمز علیه السلامنگ بیلدیکی معین بر ایشنده اتباع ایدیگز دیمکدر، که لفظ حدیث شونی تقاضا قیلدیغی کبی، بو اتباعنگ تیوشلکیده معاذ ایشلگانلك ایچون دگل بلکه اول حضرت صلیالله علیه وسلمنگ امری ایله ثابتدر. شونگ ایچونده حضرت معاذ اوزی: «دینگزنی هدایتده بولغان عالمدنده تقلید ایله آلماگز، قرآننگ منار طریق کبی، بك ظاهر یرلری وار آنلری هیچ کیمدن صورمهگز، بیلمادیکگز یرلرینی عالمینه تفویض ایدیگز!» دیوب، تقلیددن منع ایلمش وظاهر قرآنه اتباع ومشکلاتنده توقف ایله امر قیلمشدر.

اگر سز اللهتعالی، اولیامرگا اطاعت ایله قوشدی، آنلر علما ایدی بس آنلرنگ فتویلرینه تقلید واجبدر دیسهگز! جواب: اولی امر فقط علما دگل بلکهعلما ایله امرادر. درست بونلره اطاعت واجب لکن اللهورسولی قوشقان ایشلرده واجب. علمای متقدمین اللهورسولی قوشقان ایشلرنی تبلیغده وامرائ تنفیذده بك مبالغه قیلورلر ایدی. بوندن سزنگ ظن قیلدیغگز کبی، آرائ رجالنی سنت رسولگه تقدیم وآنلره تقلیدنگ لزومی برده آنگلاشمایدر؛ حتی، بالعکس بو آیت تقلیدنی، بك آچق ابطال ایلمکدهدر. چونکه بو آیت الله ورسولینه اطاعت یعنی امرلرینیطوطو ونهیلرندن طیولو ایله توصیه قیلادر. بس اللهورسولینه اطاعت ایچون امرالله وامررسولنی بیلورگه کیراك بنائ علیه اگر بر کشیسز مقلدلر کبی، بن الله ورسولینگ امرلرینی بیلمای من بلکه فقط اهل علمگه تقلید ایدهمن دیسه، اول کشینگطاعة الله وطاعة رسولنی تحقیقی ممکن دگلدر. شونگ ایچون معاذ بن جبل، عبدالله بن مسعود، عبدالله بن عمر، عبدالله بن عباس، ابوحنیفه، شافعی، مالك واحمد کبی اصحاب وائمهدن اوزلری اولی امر بولا

دیواره صوقدی. مونه اسلاف صالحین سزگ کبی دگل، بلکه سنت رسول قارشوسنده هیچ برشي نی قبول قیلمازلر ایدی. فقط بو ضررلی بدعتلرنی صوگره سز چغاردیگزده مسلمانلرنگ باشینی بوقدر بلالره صوقدیگز!

درست عمر، ابو بکرگه «رأینا لرأیك تبع» دیگان، لکن بو سوزنی صحیح بخاری‌ده طارق بن شهاب‌دن روایت قیلنغان اوزون بر حدیث آره‌سنده ذکر قیلمش‌در، که اول حدیث‌نگ اوزندن عمرنگ ابو بکرگه بعض یرلرده مخالفتی بك اچق آڭلاشیلادر؛ چونکه اول حدیث‌ده ابو بکر، عدم اخذدیت ایله حکم قیلدیغی حالده عمر، اخذدیت ایله قائل اولمش‌در. بس حضرت عمرنگ بو سوزنده‌گی تبعیت تقلید معناسنده دگل بلکه سنگ رأیگ‌نی دلیلی نه نظرا اصوب طابدق‌ده شوڭا متابعت ایلدك معناسنده‌در. مسروق‌نگ: «ما کنت ادع قول ابن مسعود لقول احدمن الناس» دیگان سوزینگ‌ده معناسی اشبودر. هم ابن مسعود ایله ابن عمرنگ اوزسوزلرینی قویوب، عمر سوزی ایله همده زیدنگ اوزسوزینی قویوب علی سوزی ایله آلولریده تقلید دگل بلکه فکرلر برلشکان وقت عالم‌نگ عالم‌گه موافقتی بابندن ایدی. شونگ ایچونده بونلر، بر سنت ظاهر بولدی ایسه آنگ قارشی‌سنده هیچ کیم‌نگ سوزینی قبول قیلمازلر ایدی، و قارشی‌سنده‌غی کشی‌نگ قوة دلیلی ظاهر بولسه سزگ کبی، جاهل تعصب‌غه واروب آنی قبولدن استنکاف‌ده ایتمازلر ایدی، بونلر سزگ کبی صوقور تقلیدگه اصلا وارمازلر ایدی. شونگ ایچونده زید ایله ابن عمر دلیل قارشی‌سنده‌غی قول عمرنی قبول قیلمادقلری کبی، ابن مسعودده عمرنگ بر طلاق دیدیکی حرام لفظینی یمین دیمش‌در «ابن قیم بوراده ابن مسعودنگ عمرگه یوز مسأله‌ده خلاف واردیغنی ذکر قیلمش‌در» وابن عباس هم بر سنت قارشی‌سنده ابو بکر و عمر ایتدی دیگان کشی‌گه: «باشگزه طاش جاوار، بن رسول الله ایتدی دیدیکم حالده، سز ابو بکر و عمر سوزلرینی قارشی‌قویمقده‌سگز!» دیوب، اظهار غضب ایلمش‌در. حال بوکه سز مقلدلر! سنت قارشوسنده اصحابدن بك کوب درجه توبان

دگلدر، وارسون حضرت عمرنک حضرت ابو بکرگه هر بر سوزنده تقلیدی ثابتده بولسون! بو وقتده‌ده سزک ایچون هیچ بر فایده یوقدر. چونکه سز اصحابه هیچ بر معادل بولمغان کشیلرگه تقلید ایده‌سز، صاحبلریکزنک سوزینه ایاروب برده‌حیاسز ابو بکر ایله عمرگه مخالف کیده‌سز، حتی شافعیه‌نک بعض اصول کتابلرنده کورندیکی کبی بعضیلریکز وارکه ابو بکر ایله عمرگه تقلید حرام و شافعی‌گه تقلید واجب دیسز، شافعی‌گه و باشقه امامل‌ره تقلید خصوصنده هیچ بر سوز بولمایوب بو ایکی‌سینه اتباع حقنده کوب حدیثلر وارلغینی بتون خاطرگزدن چغاره‌سز! سز، مونه حضرت عمرنی نمونه‌ایتوب طوطیکز! واول اویالغان شی‌دن اویالگزده ابو بکرگه تقلید ایدیکز! بلکه‌اول وقت سزدن الله‌ده ورسولی‌ده راضی‌بولور. حال‌بوکه سز بو حدیثنی اختصار واوزیکزه یایسز یرینی خذف قیلدیکز! حدیثنک تمامی بو یله‌در: «ابو بکر، کلاله خصوصنده بن رأیم ایله حکم قیلامن صواب بولسه الله‌دن، خطابولسه بندن و شیطاندن‌در. کلاله‌دیمك مادون الولد و الوالد دیمك‌در دیوب حکمی‌صوگنده حضرت عمر، بن ابو بکرنک خلافینه وارودن الله‌تعالی‌دن حیاایده‌من دیمش‌در.» پس‌بو حدیث بو یونچه عمرنک ابو بکرگه مخالفتدن حیاسی بوحکم‌نی قیلو خصوصنده غینه‌دگل بلکه کلامی‌نک همه‌سی‌نک صواب دگللکی وجواز خطا ایله اقرار خصوصلرنده در. شونک ایچونده حضرت عمر عندالوفات بن کلاله خصوصنده هیچ بر شی آکلامدم دیمش وحین حیاتنده حضرت ابو بکرگه بك کوب یرده خلاف کیتمش‌در. ابو بکر اهل ردة‌نی سبی قیلمش ایدی، عمر ام‌ولددن باشقه لرینی آزاد ایتوب اهللرینه قایتاردی، ابو بکر ارض عنوه‌نی تقسیم و عمر وقف ایلدی، ابو بکر عطاده تسویه قیلور وعمر مفاضله‌نی جایز کورور ایدی، ابو بکر استخلاف قیلمش ایدی، عمر ایسه حضرت رسوله اتباعا آندن عدول ایلدی وابو بکر سوزینی حضرت رسول سنتی قارشی‌سنده

«وَاذْكُرْنَ مَا يُتْلَى فِي بُيُوتِكُنَّ مِنْ آيَاتِ اللّٰهِ وَالْحِكْمَةِ» ديه‌رك، نساءرسوله امر قیلنغان ذکری کبی، قرآن و حدیثدن عبارتدر. مونه‌بز شوشی ذکرگه اتباع ایله مأمورمز، بس اگر بر کشی اوزی بیلماسه اهل ذکرگه یعني‌حضرت رسوله‌منزل ذکرنی بیلان آدمه مراجعت‌قیلور واول خبرویرگان شی‌گه‌اتباع‌ایدر، معین بر کشی‌نی هدف‌ایتوب طوتماز، اسلاف‌صالحین‌همه‌سی‌اشبو طریقده‌ایدیلر، آنلرڭ، هر بر سوزینه‌اتباع قیلا طورغان معین‌بر متبوعلری‌یوق ایدی. عبدالله‌بن عباس، اصحاب‌کرام‌دن فقط‌حضرت رسولڭ سوزندن، ایشندن، سنتندن صورار باشقه‌هیچ برشی‌دن صورماز ایدی، اصحاب‌ده‌امهات مؤمنین‌دن، خصوصا‌حضرت‌عائشه‌دن‌اول‌حضرت‌صلی‌الله‌علیه‌وسلم‌نڭ اونده‌گی‌ایشلرینی‌گینه صورارلر وتابعین هم‌ائمهٔ‌فقه‌ده شوشلای قیلورلر ایدی، شافعی‌نڭ‌احمدگه: «سن‌حدیث‌نی بندن آرتق‌بیلاسڭ اگر بر حدیث سنڭ‌عندگده صحیح‌بولدیمی دیلسه‌شامی، دیلسه کوفی، دیلسه بصری،اولسون‌سن، آنی‌بڭا‌بیلدره‌کور! بن آڭا‌ذاهب‌اولاچق‌من» دیدیکی‌کبی، اهل علم‌نڭ‌هیچ برسی‌معین‌بر آدم‌نڭ رأیندن ومذهبندن صورماز و باشقه‌لرنڭ‌همه‌سندن‌یوزچه‌وروب معین‌برسینه‌باغلانماز ایدی. حال‌بوکه‌تقلید‌بالاتفاق علم دگل و علم‌سز فتوی‌ویرن آدم حقنده افندمز علیه‌السلام: «قتلوه قتلهم‌الله»دیوب بددعا قیلمش ایدی، برشی‌گه رسول‌بددعا‌قیلدیمی اول‌شی معین‌حرام‌در. بس‌بو امر رسول بویونچه‌ده تقلید حرام بولوب چغه‌در.

اگر سز حضرت‌عمر، کلاله حقنده بن‌ابوبکرنڭ خلافینه وارودن الله‌تعالی‌دن حیاایدمن دیه‌رك ابوبکرگه تقلیدایلمش بیت دیسه‌ڭز !ایتورمز: بونڭ‌ایله‌حضرت‌عمرنڭ‌حضرت‌ابوبکرگه‌فقط‌بر مسأله‌ده‌تقلیدی‌ثابت‌بولادر. بوندن‌ایسه‌سزڭ‌دیدیکڭز‌کبی، بر آدم‌نڭ هر بر سوزینه نصوص شرعیه کبی تقلید ایدوب باشقه سوزلرنڭ هیچ برسینه حتی‌نصوص شرعیه‌گه بیله‌التفات قیلمازسزلق اصلا لازم

حتی ظاهر تعصبه چوموب قول صاحبڭزه مخالف اولان کتاب ایله سنتی بیله ردقیلوغه قدر، جسارت ایلدیڭز! دوغروسی سز صاحبڭزنڭ سوزینه علی العمیا ایيار دیڭز، و آنڭ حکملرینی نقل وحکایه قیلدیڭز، وعهده سی قائلینه دیه ظن ایلدیڭز، وشوشی عذریڭز ایله عنداحکم الحاکمین قوتولماقچی اولدیڭز! حال بو که صاحبڭز دلیلسز، بڭا ایيارمه ڭز دیه رك بو مسئولیتنی اوز اوستندین توشرمش ایدی؛ بناء علیه سز آدملر آره سنده بیلمایو نچه قیلدیغڭز بو حکملریڭز ایچون عندالله مسئول ومعذب اولاچق سڭز!

دخی سز مقلدلرگه ایته مز: صاحبڭزنڭ سوزی مجرد اوز سوزی بولو جهتندن هیچ بر شرعی دگل، بس بوحیثیتدن آنڭ ایله اصلا عمل قیلامیه جق سڭز! اگر بو سوزنی افندمز علیه السلامدن مروی دیسه ڭز بو سوزنی هیچ ایتمگان حضرت رسوله ده، و بونی حضرت رسول ایتدی دیمیان صاحبڭزه ده افترا ایتمش اولاچق سڭز! اگر مادامکه حضرت رسول اوزمزدن اعلمه اتباع، و بیلمادیکمزنی بیلگان کشی لردن سؤال واولو العلمنڭ استنباطینه مراجعت ایله امر ایلدی. بس بز بو تقلیدمزده امر رسوله متبع مز دیسه ڭز، بك طوغری بزده امر رسوله اتباع تیوشلی دیوب دعوا قیلامز؛ لکن، اگر بر اورنده امر رسول ایله قول صاحبڭز قارا قارشی کلسه لر بو وقتده سز قایسی سی بلن اخذ قیلاجق سڭز؟ اگر امر رسولی آلوب قول صاحبڭزی دیواره صوقسه ڭز اول وقت تقلیددن چیغوب مستدل بولوب کیده سز! اگر قول صاحبڭزی آلوب امر رسولی الله غه تفویض قیلسه ڭز و بزم صاحبمز امر رسولی بزدن عالمرك اگر امر رسول منسوخ یا که دیگر بر قوتلی رك دلیل معارض و یاخود آنڭ عندنده غیر صحیح بولماسه ایدی، البته اول آڭا خلاف قیلماز ایدی دیسه ڭز، بو وقت سز صاحبڭزڭ قولینی محکم وقول رسولی ضعیف ومردود قیلمش اولاجق سڭز! درست اهل ذکردن صورمق لازم؛ لکن ذکر دیمك قوری علمدن عبارت دگل، بلکه الله تعالی نڭ:

وبیلونگده اجتهادسز ممکن دگل‌لگی، سزگچه‌ده قضیهٔ مصدقه بولندیغی حالده‌بوثوابلی اجتهادنی‌قویووگز وبعضیسی، بعضیسنی‌تأییدایدن کتاب‌الله وسنت رسول الله‌دن یوزچاووروب اختلافلر وتناقضلر ایله طولی کتابلره، وفلان فلان‌نڭ‌قوللرینه مراجعتگز، بك زیاده تعجب اولنه‌جق بر مسأله‌در. بو قدر مختلف‌اقوال فقهانڭ قایسی‌سی صواب‌ایکانلگینی کتاب ایله‌سنته مراجعت سز، نچك بیلورگه کیراك؟ بزنی بو قدر اقوال متضاده آره‌سینه آطودن همده خطادن «سز مقلدلرچه‌ده» معصوم اولمیان بر آدم‌نڭ بارسوزلرینه متابعت ایله امردن الله ایله رسولی منزه‌درلر. مونه ایش شوشلای بولا طوروب‌سز تلفیق‌نی درست کورمسه‌گز ده‌ابو حنیفه ایله‌شافعی‌دن‌هم‌امام‌محمدایله‌ابو یوسف‌دن‌دیلاسه قایسی‌سینه‌تقلیدنی‌درست کوره‌سز، ومعین‌برسینه‌تقلیدواجب‌دگل‌دی‌سز! معین متناقضان هر ایکی‌سی حق‌دگل، بس اگر اولگی‌سی حق بولسه حق‌دن، باطل‌غه کوچونی، اگر ایکنچی‌سی حق‌بولسه‌خلاف‌حق‌ده‌دوام‌نی جایز کوره‌سز صگره‌سز، بونلرنڭ‌برسینه‌البته‌صواب‌دیوب‌ایباره‌سز سز بونڭ صوابغلینی‌قایدن‌بیله‌سز؟ اگر دلیل‌بلن بیلدك‌دیسه‌گز، مقلد دگل مستدل‌سگز! اگر تقلید ایله بیلدك چونکه آنڭ علمی قوتلی وصلاحی بك مشهور اولغانلقدن حقلقدن باشقه‌نی معین‌سویلاماز دیسه‌گز اول وقت، اگر آنی معصوم دیسه‌گز آنڭ: «بن معصوم دگل» دیگان اوز مسلکینی ابطال قیلاسگز، اگر آڭا خطانی جایز کورسه‌گز بو معین مسأله‌ده فقط آنڭ سوزی صواب باشقه مخالفین‌نڭ همه‌سینڭ سوزی خطا دیوب قایدن بیلدیگز؟ احتمال‌سز اول، خطا قیلسه‌ده مأجور بیت، بس بو مأجور ایشده متابعت ایلدیکمزدن بزده مأجورمز دیه‌جك‌سگز! درست اول، مأجور؛ لکن خطاسی‌ایچون دگل، مأمور به بولغان اجتهادنی قیلدیغی‌ایچون مأجور، سز ایسه بو مأمور به‌نی قیلمادیغگز ایچون‌مأجور دگل، بلکه مأزورسگز! اگر معرفت حق‌غه وصول ایچون سز ده اجتهادگزنی صرف قیلسه‌گز ایدی، اول وقت سز ده‌مأجور بولور ایدیگز؛ لکن‌سز اقتداریگزنی‌صرف قیلمادیگز!

ایچون هر بر دورلی حیله‌لره صابدی؛ لکن، بو حیله‌لر خصملرندن صادر بولسه اول وقت نصوص‌نی بوکبی، احتماللر ایله رد قیلو درست دگل دیوب، باربار باغردی. مونه آنلر بو حیله‌نی اوزلری قیلدیلر. اگر خصملری قیلسه‌لر آنی دورلی وجه‌لر ایله، رد ایدرگه دوروشدیلر. حال بوکه بو حیله‌لرگ هیچ برسی اساس اسلام‌ده وزمان اصحابده یوق ایدی. اصحاب کرام، اول حضرت اکرم‌دن ایشتکان سوزلرنی، هیچ بر آدمنگ رأیینه‌تطبیق قیلوب قاراماسلر وآنی‌قبول خصوصنده هیچ بر موافق‌نگ‌موافقتینه‌طوقتالوب طورمازلر ایدی. مونه آنلره واجب‌اشبو ایدی. افندمز علیه السلام‌نگ دعوتی، اول‌حضرته‌معاصر والی‌یوم‌القیامة‌غیر معاصرهرکیم‌دن‌عام‌واصحابه لازم بعینه‌صوگغی‌لرده لازم اولغانلقدن الی‌یوم‌القیامه بزگه‌ده واجب اشبو ایدی. بدیهی‌در، که بو ایش آنلره مخصوص دگل وآنلردن‌صوگ منسوخ‌هم‌دگل‌ایدی، لکن‌سز بونلرگ هیچ‌برینی قاراماديگز!

الله هم رسولی واجب قیلغان یولدن چغوب باشمزی بوبلالره صوقدیگز! الله تعالی‌نگ: «وَلَوْكَانَ‌مِنْ‌عِنْدِ غَيْرِ اللّٰهِ لَوَجَدُوا فِيهِ اخْتِلَافًا كَثِيرًا» دیدیکی، واماملرگزگ متفقا: محل نزاع‌ده حق بر دیوب تصریح ایلدکلری کبی، بواقوال متناقضه همه‌سی دین الله بولمق‌لق ممکن دگل ایدی، سز مسلمانلری شول بری دیگرینی ابطال ایدن اختلافات ایچینه دین دیه‌رك آتدیگز! قرآن ایله سنتدن هم معقول صریح‌دن چقدیگز! دین‌نی آرای جهلاغه تابع بر اویانچاق کبی قیلدیگز! حال‌بوکه اسلام، کتاب ایله سنتده بیان ایدلگان، امر واحد، ومجتهد آگا اصابت ایتسه ایکی‌اجرلی، اگر خطا قیلسه بر اجرلی‌ایدی، بو حقیقت ایله‌وطلب حق وآگا وصول ایچون بقدر الامکان اجتهادنگ لزومی ایله وبقدر الاستطاعه تقوالق‌نگ هم وجوبی ایله سز اوزیگزده معترف‌ایدیگز، تقوالق‌نگ اوامر آلهیه‌نی طوتوونواهی الهیه‌دن طیولودن عبارت اولمق‌لغی وبرشی‌نی قیلو یاخود قویو ایچون بیلونگ معین لزومی

فلان و فلان نڭ رأيينه دگل، بلكه خير مطلق اولان كتاب الله ايله سنت رسول گه اوندار لر ايدى. مونه فلاح شو شنده‌در. سزگ تقليدلر گزده، بدعتلر گزده دگلدر. وامام‌لريكزگ حالينه‌ده خلاف‌در؛ چونكه آنلر اوزلرينه هم‌باشقه‌لره تقليددن، بك شدتلى منع قيلورلر وقورقوتورلر ايدى. بونلر الله‌تعالى‌نڭ: «يا ايها الرسل كلوا من الطيبات واعملوا صالحاً انى بما تعملون عليم وان هذه امتكم امة واحدة وانا ربكم فاتقون» ديگان سوزى بويونچه يورورلر: طيباتنى آشارلر، ايزگولكنى قيلورلر، ويالگز بر الله‌غه اطاعت ايدرلر، جزئياتده اختلافنى، دينده تفرق كه ودورلى شيعه‌لر يصاوغه وسيله ايتمازلر بلكه يالگز حقلقنى ايزلارلر، وآنى باشقه‌لرگ همه‌سينه تقديم ايدرلر، وحقنى طابديلرمى، حاضر اول خصوصده اتفاقه كلورلر ايدى. والحاصل: بونلرگ مقصدلرى بر، هم‌يوللريده‌بر ايدى. سزگ كبى، يتمش يولغه ويتمش فرقه گه آيرلمامشلر ايدى، هم‌بونلر كبى باشقه اهل علم‌ده اقوال علمانى تيكشرورلر وآنلرى كتاب الله ايله سنت رسول گه عرض قيلورلر؛ بس اگر موافق بولسه آلورلر، موافق بولماسه قويارلر ايدى. اگر موافقت، مخالفت ظاهر بولماسه، آنى مسائل اجتهاديه‌دن صانارلر وآگا متابعتنى هيچ كيم گه واجب ديمازلر وبو حق وبوندن باشقه همه‌سى باطل ديوب هيچ بر ايتمازلر ايدى. صگره بر زمان كلدى، مقلدلر دورى آچلدى، بونلر ايسكى يولنى طاشلاديلر، اوضاع دين نى اوزگارتديلر، كتاب الله ايله سنت رسول نى بر طرفغه طاشلاديلر، والله‌تعالى نڭ: «فتقطعوا امرهم بينهم زبراً، كل حزب بما لديهم فرحون» ديديكى كبى، ايشلرينى فقط، زبرگه يعنى كتب مصنفه‌غه سوياديلر. هر بر مسأله‌نى فقط صاحبلرينڭ سوزلرينه عرض ايلديلر. بس آره‌لر آيرلدى، فرقه‌لر كوبايدى، هر بر فرقه اوز صاحبى نڭ سوزينه خلاف آيتلرنى، حديثلرنى رد قيلورغه طوطوندى، وآنلرى رد

کرتودن باشقه هیچ بر توجیه ممکن توگلدر. بس مادامکه ایش بو کیفیتده‌در. سز بو تقلید و بو حکملریگزنی البته الله هم رسولی‌نڭ شریعتی دیه‌میه‌جك‌سڭز! چونکه شریعت، سزڭ صاحبکزنڭ قولی دگل، بلکه کتاب ایله سنت‌دن عبارتدر. و طبیعی سز بو حکملریگزنی خلاف مشروع دخی دیمیه‌جك‌سڭز! بس قالدی اوچونچی برشق، که آنسی مشروعمی دگلمی بیلمامکدن عبارتدر؛ حال‌بوکه حقوق ناس وامور شرعیه‌ده بیلمایونچه حکم قیلونڭ بك ناچار و بك بیوك گناه ایکانلگینی سز اوزیگزده بك گوزل بیله‌سڭز.

دخی ایته‌مز: سز تقلیدچی‌لر، الله و رسولینڭ امرینه و اصحاب کرامنڭ هدایتینه و امامل‌رکزڭ حالینه هم اهل علمنڭ طریقینه خلاف کیتدیگز! سزڭ ایشگز امر الله‌غه خلاف‌در: چونکه قرآن، مسلمانلر بر شی‌ده نزاع قیلشسه‌لر اول شی‌نی الله‌ایله رسولینه قایتاروغه قوشه‌در. حال بوکه سز آنی قول صاحبکزه قایتاراسز! و امر رسول‌گه خلاف‌در: چونکه افندمز علیه السلام بر مسأله‌ده اختلاف واقع بولسه اوزی هم خلفای راشدین سنتینه یابشمغه و آنی آزاو دیشلر ایله، دیشلرگه قوشدی. سز ایسه بر شی‌ده اختلاف بولدیمی، آنی یالگز صاحبگز قولینه قایتاروب باشقه سوزلرڭ همه‌سندن اعراض قیلاسز. حال بوکه، الله تعالی: «وَاِذَا قِيلَ لَهُمْ تَعَالَوْا اِلَى مَا اَنْزَلَ اللّٰهُ وَاِلَى الرَّسُولِ رَاَيْتَ الْمُنَافِقِينَ يَصُدُّونَ عَنْكَ صُدُودًا» دیوب، سزڭ کبی الله و رسولینڭ سوزینه راضی بولمایوب حکم غیرگه تبعیت ایدن آدملری منافق اسمی ایله تسمیه قیلوب ذم ایلمشدر. و هدایت اصحاب‌غه خلافدر: چونکه باشقه‌لرڭ همه‌سندن اعراض ایدوب، بر آدمڭ جمیع اقوالینی بوینینه طاغان، اصحاب آره‌سنده هیچ کیم یوق ایدی. بلکه آنلر الله تعالی‌نڭ: «وَلْتَكُنْ مِنْكُمْ اُمَّةٌ يَدْعُونَ اِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَاُولٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ» دیگان، سوزی ایله عمل قیلوب

بر آدمگه تقلید قیلامز » دیگان سوزیگزدەده کاذبسگز! سز قول صاحبگزه موافق اولان آیت وحدیثلرنی بك آڭلایسز، حتی مطلبگزی اثبات ایچون آنلره تمسكده قیلاسز! فقط، اگر قول صاحبگز مخالف حقیقت بولسه وآیتلر، حدیثلر ایله دورلی طرفدن قسلسه گز مونه شول وقتده سز آنلری آڭلامامشغه صالینەسز واوز اوزیگزنی تجهیل وتسفیه قیلورغه طوطوناسز!

مونه شوشلای سز اوزیگزه یای کیلگان یرده اڭ عالم واڭ فاضل کیسلا طوروب، بر آز یایسز کیلدیمی شوندوق قویروغگزنی بورەسز، وهیچ بر شی بیلمامش که صالینه باشلایسز! سز مجمع غرائب بر فرقەسگز! اڭ بلیغ وبناءً علیه اڭ آچق کلام الله ایله کلام رسولدن مقصدنی، آڭلامیوب خطالر ایله هم اختلاف وتناقض ایله طولی باشقه بر کشی سوزندن مقصد آڭلامقلغگز نه قدر بعید ونه قدر خلاف حقیقت اولمقلغینی آزراق ایسابلاب قاراسا گز! اوزیگزده بیلورسز! آڭا اتباعگڭ لزومینه وکلامینڭ صحتینه هیچ بر دلیل قایم اولمغان بر کشیگه اتباع قیلەمز دیوب، باشقه هر بر سوزدن اعراضگز وحتی اڭ قوتلی دلیل کلام الله ایله کلام رسولنی بیله ترك ایتمكلكگز سزڭ حمق وسفاهتگزه اڭ قوتلی دلیللردندر.

حال بوکه سز اوزگزده ابو حنیفەنڭ خطاسینی جایز کورەسز حتی فارسیچه قرآن اوقو درست دیگان سوز کبی، بعض مسألەلردە بالفعل خطا قیلوب صگره خطاسینی بیلەرك امامین سوزینه قایتمقلغینی‌ده اقرار ایدەسز! بس بك احتمال، که اگر ابو حنیفه حیاتده اوزاق تورسه ایدی، بلکه الیكدن حکم ایلدیکی دخی بك کوب ایشلرنده خطاسنی آڭلاب ایکنچی اماملرنڭ سوزلرینه قایتور ایدی. اما کلام الله ایله کلام رسولده اصلا خطا احتمالی یوق؛ بس سزڭ احتمال خطا ایله طولی بر سوزگه ایاروبده اصلا احتمال خطا اولمیان اڭ قطعی برسوزنی قویمقلغگزنی: « صُمٌّ بُكْمٌ عُمْيٌ فَهُمْ لَا يُبْصِرُونَ » قضیەسینه

حضورنده دیه‌میه‌جك‌سگز ! بس سز صوابمی خطامی بصیرت اوزرینه بیلمادیککز برشی ایله عباد الله بیننده حکم قیلدیغگز ایچون الله‌نڭ حکم‌و عذابینه اوغرایه‌جق‌سگز ! اماصاحبگز اوزی شافعی‌نڭ: «دلیلسز علم ایستیان آدم، قولنده فناری بولندیغی حالده یاندرمایونچه قارانغی‌ده جلان اوستینه باصوب اوزاوزینی چاقدرغان آدم کبی‌در» دیدیکی کبی، دلیلسز هیچ کیمه تقلید ایتمه‌گز دیوب ایتوب قویدیغندن سزه اوز حسناتندن بررشی‌نی ویروياخودسزڭ سیئاتگزدن برر نرسه‌نی آلو احتمالی یوقدر. سز مقلدلر ، بك عجایب بر طائفه‌سگز ! اگر کتاب الله‌دن یاخود احادیث مرسله‌دن صاحبگزنڭ رأیینه موافق برر سوز طاپسه‌گز آنی آلاسز وآنڭ بلن دلیل ایستای‌سز، اگر آیتلر، حدیثلر قول‌صاحبگزه مخالف اولسه اون آیت ویوز حدیث صحیح کورسه‌گزده آگا متابعت ایتمای‌سز، بلکه آیتلرنی تأویل قیلوب حدیثلرنی بتونلای التفاتسز قویاسز ! حتی بر حدیث‌نڭ ایچنده صاحبگزنڭ قولینه موافق بولغان حکم‌نی آلوب مخالف بولغانینی ترك ایده‌سز : «اذا استیقظ احدکم من نومه فلایغمس یده فی‌الاناء حتی یغسلها ثلثا» حدیثی ایله ملاقات سببلی‌صونڭ نجسلانووینه دلیل ایستای طوروب اوزیگز یومایونچه طقسه‌ده صونجسلانمای غسل ید واجب دگل‌دی‌سز !. «اذاولغ الکلب فی اناءاحدکم فلیغسله سبع مرات» حدیثی ایله، ات یالاغان صاوت‌نڭ نجسلانووینه دلیل ایستای طوروب اوزیگز اوچ مرتبه ییقامق کافی، یدی مرتبه لازم دگل‌دی‌سز ! «ابن قیم بوراده بوخصوص ایچون آلتمش التی شاهد کتورمش‌در، بز اختصار ایچون فقط ایکی‌سنی ترجمه قیلدق». دیمك که سزگچه عمده آیت حدیث دگل، بلکه قول صاحبگزدر. و بونلر فقط قول صاحبگزه موافق بولسه‌لر حجت، اگر موافق بولماسه‌لر، حجت دگل‌در. و بوندن هم آڭلاشلدی، که‌سز : «بز کلام‌الله ایله کلام رسول‌دن حقلق‌نی آڭلای آلمای‌مز وشونڭ ایچون عندمزده صدقی وقوة علمیه‌سی ثابت بولغان

اصحابه مخالفدر ، البتة اصحابه موافق بولغان سوزگه اتباع تیوشلی و لازمدر.

افندیلر! بر آز انصاف کیرالك، سزفقط اوزصاحبکزنک سوزینی ترویج قیلاسز! و آنک سوزینه خلاف بولغان اصحاب وتابعین قوللرینه اصلاالتفات ایتمایسز! و آنک کلامینه تطبیق ایده‌مز دیوب کتاب ایله سنتنی دورلی، دورلی تأویللر ایله ظاهرندن چغاره‌سز! حالبوکه قرآن کریم سزنگ متبوعکزنگ فکرینه اویدرمق ایچون دگل، بلکه آندن استنباط حکم ایچون تنزیل اولنمشدر. سز بو ایشکز ایله «اوزیکز بیلاسزمی یوقمی؟» کتاب اللهنی، وسنت رسول‌نی، هم اصحاب کرام وتابعین عظام حضرتلرینک همه‌سینی، حقارت و مستقل ایده‌سز! حال بوکه عندکزده بو صاحبکزنک اهل عصرینک اعلمی بولمقلغینه وآندن صوک آندن اعلمنک کیلمیه چگینه بیله دلیلکز یوقدر. بس سزنگ صاحبمزه تقلید دیه‌رك حقوق عباده‌غی حکملریکز وقانلرنی ومالللرنی حلال وحرام قیلمقلغکز، بك دهشتلی وبك قورقونوچلی برشیدر؛ چونکه سز بو حکملرکز ایچون، قیامت کوننده البتة سوءال اولنه‌چقسکز!

سز دنیاده آلداب قوتولاسز، اما آخرتده آلداو ممکن اولمغانلقدن، اولدار جزاده بو حکملرمز الله‌هم رسوللرینک امرینه موافق دیوب، صرف یالغان برسوزنی البتة سویلامیه‌جکسکز! بلکه بوحکملرمز الله هم رسولینک امرینه مخالف دیوب، اوزضرریکزه اوزیکز شهادت ایده‌جکسکز! اگر، بز آنی ابوحنیفه یاکه شافعی یاخود ابو یوسف سوزندن ویاخود متأخریندن بررسینک کتابندن آلدق دیسه‌گز، اول وقت سز آنی بنم امرم ایله‌می یاخود بنم امرمدن باشقه‌می آلدیکز؟ دیو سوءال اولناجقسکز! مونه شول وقت اگرسز، بز آنی سننگ هم رسولکنک امری ایله آلدق دیه بیلسه‌گز بك خوش بولور ایدی؛ لکن مادام که بونی اثبات ایچون کتاب ایله سنتدن هیچ بردلیلکز یوق؛ شونک ایچون سز، بوسوزنی اول باری تعالی

بوايشده‌سزنڭ صاحبڭزه‌مشارك دگل، ديسه‌ڭز! اوزيڭزنڭ حيواندن‌ده كيم‌بردرجه‌گه‌نزولڭزني اثبات‌قيلمش اولاچق‌سڭز!! اگر مشاركتلرينی اقرار ايتسه‌ڭز، نه‌ايچون سز، بووقت گوياصاحبڭز بتون‌صواب‌نی جيغانده بتون‌خطا باشقه‌لره‌قالغان كبی، صاحبڭزنڭ هر برسوزينی قبول وآنڭ كبی، بلكه آندن عالم، ديگرلرينڭ همه‌سوزلرينی‌رد قيلاسز؟ اگر بز تقليد ايدن‌ذاتنڭ علمی كوب ودينی‌قوتلی بولغانلقدن، اگر اسلاف صالحين‌غه خلاف‌كيتسه معين بك‌قوتلی بر دليل‌طابديغی ايچون بولورغه كيراك، ديسه‌ڭز! اول‌وقت‌بونڭ دليلی‌قوتلی؛ امابوندن افضل‌اولان اسلاف كرامنڭ؛ دليللری‌ضعيف‌ايكانلگينی قايدن‌بيله‌سز؟ اگر تقليدايله‌ديسه‌ڭز! صواب، ادنی‌غه دگل، بلكه افضل‌غه تقليدقيلودر، اگر دليل‌ايله‌ديسه‌ڭز! تقليددن‌چقوب‌نقيض‌مدعا ڭز، استدلال‌مسلكينه كره‌سز! اگر بزم صاحبمز بروجه‌خفی ايله ترجيح‌طابا ديسه‌ڭز! اول وقت‌سزنڭ صاحبڭزه‌نسبةواضع‌شريعت‌كه ياقنراق‌وبناءعليه‌شريعت‌نڭ خفاسی آزراق بولغان عمر، علی‌وابن‌مسعودكبی، اصحاب كرام بطريق اولی‌ترجيح طابارغه كيراك، كاشكی‌سز مفضول‌نڭ قولی‌ايله افضل واعلمه‌مخالفت‌نی تجويز قيلغانچی، اعلم‌وافضل‌نڭ سوزی‌ايله مفضوله مخالفت‌نی جايزكورسه‌ڭز ايدی؛ بلكه‌تقليدڭزكه، دهامناسب‌ايش‌قيلغان بولور ايديڭز! چونكه سزنڭ صاحبڭز ايله آڭاخلاف مجتهدنڭ برسی‌عمر ياكه علی‌سوزی‌ايله آلديغی‌حالده ديگری، ابن‌عباس‌ياخود عائشه سوزی‌ايله آلمقده‌در. بناءعليه مادامكه بونلر اصحاب سوزندن چقمغانلر. بس‌بزده آنلر مراجعت‌قيلغان‌اورونغه‌مراجعت‌قيلورغه‌تيوشلی ديه‌رك، اصحاب‌كرامه متابعت قيلمق‌لغڭز، دهامعقول ودها موافق‌در.

حال‌بوكه بعض‌مسأله‌لر واردركه سزنڭ صاحبڭز اول‌خصوصده عمر، علی وعائشه كبی اصحابڭ همه‌سينه مخالفت قيلديغی حالده آنڭ‌خلافی مجتهد آخر آنلره موافقت ايلمك‌ده‌در، بس‌مادامكه بوايكی بيوك عالمڭ برسی‌نڭ سوزی اصحابه‌موافق وديگرينڭ سوزی

تقلید ایده طورغان اماملر اوزلرینه هم باشقه‌لرغه تقلیددن متفقا منع قیلدیلر وخلافینه دلیل قائم بولغان سوزلرینی قویارغه قوشدیلر. شونک ایچون تقلیدک بطلان وحرمتی ایله اوز کتابلر گزده طوب طولی‌در. حتی مفتی ایله قاضی‌نک مجتهد بولمق‌لری شرط دیوب هر بر کتابگزده تصریح اولنمش‌در. بس مادامکه اوزیگز بو اماملرغه جمیع مذهبلرنده تقلیدنی دعوا قیلاسز !نیگه آنلرغه اصل واساس اولان بو سوزلرنده تقلیدنی ترك ایده‌سز !حتی آ گاپارقوتگز ایله قارشی طوره‌سز؟ حال بوکه سزده و بزده بدیهة بیله‌مز، که اصحاب وتابعین وتبع‌تابعین زماننده بر آدم‌نک هر بر سوزینه تقلید وباشقه‌لرنک سوزندن بتونلای اعراض ایدن، هیچ کیم بولنمامش وبو مذموم بدعت فقط افندمز علیه السلام،ذم ایدن قرن رابع‌ده چقمش‌در. مقلدلر ! سز بو سوزمنک بطلانینی دعوا قیلسه‌گز بوقرون فاضله‌دن تقلید خصوصنده بر مثال کورستگز !هر برمز بیله‌مزکه‌هیچ بر مثالگز یوق؛ بلکه‌بونلر کتاب ایله سنتدن باشقه‌غه ایپارمدیلر، الله ایله رسولینک قولینی آثار صحابه گه، آثار صحابه‌نی باشقه‌لره‌تقدیم قیلدیلر وفلان‌هم‌فلان‌نک‌سوزلرینه اصلا یناشمادیلر. مونه بو سزگ فلانلر گزدن مقدم کلوب کیچان عظمای امت البت هدایتده ایدیلر، بونلرنک طریقنی هدایت دگل ضلالت دیوب طبیعی سزده ایته‌جك دگل‌سگز! بس مادامکه بونلرنک طریقی هدایتدر، مادامکه هدایت‌نک ضدی‌ضلالت‌در؛ بس سزگ تقلید گزده ضلالت‌بولوب‌چغه‌در. حال‌بوکه‌سزگ‌متبوعلرگزدن‌ابو بکر، عمر، عثمان، علی، ابن مسعود، ابن عباس، ابن عمر وعائشه حضرتلری معین اعلم حتی سعید بن مسیب، شعبی، عطاء، طاوس کبیلرده افضل ایدیلر. بس نیگه‌سز دین، علم وادوات خبرنک همه‌سینی جامع بو بیوك‌لره ایپارمایسز وآنلرگ سوزلرندن یوز چویره‌سزده آنلردن کیم،دیگر آدملره کورکورینه تقلید ایده‌سز؟

احتمال‌سز ایتورسز! ذاتاهر بر مقلد ایته‌چك‌در، که‌بزم‌صاحبمز سلفلر یولندن‌یورگان‌وآنلرمسلکینه کرگان‌دیوب‌بوتقدیرده‌باشقه امامار

لکن نه قیلاسڭ؟ باشقه دینلر باشینه کیلگان قضا، اسلام باشینه ده کلدی، کوزلر صوقرایدی، اطرافنی تقلید ظلمتی باصدی، حتی قرن خامسدن صوڭ اجتهاد منقرض دیوگه قدر وارلدی. حالبوکه بوتاریخدن بك کوب صوڭ یعنی، هجرتدن یدی یوز اللی برنچی سنه ده وفات اولان ابن قیم مادام الشریعه، دوام اجتهاد ایله قایل اولمش و یالڭز بوخصوصده «اعلام الموقعین» اسمنده بر کتاب تألیف ایلمش در. مونه بنم بوراده مقصدم شول کتابنی ترجمه قیلوب ابنای ملتمه کورستمك و اجتهاد منقرض بولدی دیگان زماندن صوڭغی عالملر و بیوك آدملر، نه سویلاگانلر شونی میدانغه قویمق در؛ حتی زمان اجتهاد منقرض دگل دیگان سوزیاڭی سوزدگل، بلکه ایسکی سوز ایکانلك ظاهر بولسون!

مونه بنم مقصدم اشبودر. اگر تقلیدنڭ اسلام و مسلمانلر باشینه کتورگان بلالری بنم یورا کمنی، بوقدر یاندیروب قوورمسه ایدی، بن طوب طوغری، بو کتابنڭ ترجمه سینه کرشور و دورلی کتابلردن خاطرمده قالغان بواوزون مقدمه نی، یازوب ماطاشماز ایدم. مونه شول حسرتلر، مونه شول آچی حقیقتلر بنم قلممنی بو سوزلری یازارغه مجبور ایلدی. ایمدی مقصده کیله لم ده ابن قیمنڭ سوزلرینی ترجمه گه طوطونه لم:

مقلدلرگه ایته م: اگر سز! تقلیدڭزگه دلیل ایله وارسه ڭز، مقلد دگل مستدل بولاسڭز! اگر دلیلسز بطریق الاتفاق وارسه ڭز، سزڭ تقلیدلهنده قایم قیلدیغڭز دلیللرڭزنڭ معناسی قالمای در. بونڭ اوستینه مادامکه سز دلیل، برهان بیلمازسز، سزڭ تقلیدڭزده فقط ظن و تخمین درجه سنده قالادر. دیمك که سزده تقلیدنڭ حقیتینی دعوا قیلورغه ده اقتدار یوق؛ اما سزدن باشقه هر بر طائفه حقلق، بزده دیوب دعوا قیلمقده درلر. بس سز، نه یوز بله ن اوزڭزنڭ ظن درجه سندن اوزمغان فکرڭزگه اعتقادلرنده قطع ایدن آدملری دعوت ایده سڭز؟ حال بوکه سزڭ متبوعڭزگه تقلیدڭز اوزی تقلیدنی حرام قیلادر؛ چونکه سز

راشدین‌دن برلی بر محرابده‌بر امام آرتونده اوقولوب کیلگان‌نمازنی، دورت محرابده دورت امام آرتونده، قیلوب جیبارولری وحرم‌ایچنده دورت‌مقام‌ودورت محراب‌یصاوغه قدر،جسارت ایتولری، نه‌قدر محل تعجب‌ایسه‌بو دورت‌مقام‌ودورت‌محراب‌نی‌فقط‌دورت‌امام‌ایچون‌یصاب آنلردن بیوك‌وآنلردن حرمتلی‌خلفای راشدین‌وفقهای اصحاب‌ایچون یصامازسزلق‌لریده‌شول‌قدر تعجب اولنه‌چق‌برقضیه‌در. دینده‌تلاعب، تلفیق‌دگل بلکه‌مونه‌بوتفریق‌در.

حـال‌بوکه تلفیقنـگ ضرورتی، فقهانـگ تجویز ایلدکلری وبالحقیقت اسلامه، بك‌بیوك‌عارلك‌اولدیغی‌حیله‌ء شرعیه‌نـگ‌ضرورتندن مهم‌رك‌در. بونلر: الله‌تعالی‌نـگ حضرت‌ایوب حقنده‌یمیننده‌بر ایچون «وَخُذْبِيَدِكَ ضِغْثًافَاضْرِبْ بِهِوَلَاتَحْنَثْ» دیگان، سوزی بلن‌دلیل‌ایستاب تجویزربا‌واسقاط زکوة‌غه‌قدر،حیله‌ءشرعیه‌نی جایز کوره‌لر وشوشلای ایتوب ابطال‌شریعت‌که قدر‌واره‌لر؛ حال‌بوکه عین‌بر شخص‌غه‌متعلق اولان‌حنث‌ایله‌عمومه متعلق برشریعت‌نی ابطال آره‌سنده قیاس، قیاس مع الفارق‌در. الله‌تعالی یهودلرگ حیله‌ایله شنبه‌کون بالق‌طوطولرینه شول‌قدر آچولاندیغی‌حالده بزم‌فقهانـگ بونـگـکبی بیگ‌حیله‌نی تجویزلری بك زیاده محل‌تعجب‌در. کاشکی‌اگربوبوزوق تقلید اورنینه‌صحیح تلفیق‌اختیار قیلنسه، ومعاملات‌که‌متعلق‌احکام‌اجتهادیه‌ده هربرزمان وهربرحالنـگ مقتضاسینه قاراب‌اجتهاد درست‌کورلسه، واکثریت آراء وامضای‌سلطان‌ایله برمعین‌حکم قبول ایدلسه، وایکنچی زمان‌ایکنچی حکم‌مصلحت ایکان آنـگ ایچون دخی‌اشبوشریعت‌که هم‌حکمت که موافق‌تدبیرگه مراجعت‌اولنسه‌ایدی، هربرمذهب مساوی قارالوب‌فقها آره‌سنده، بوتعصب وبوافتراق‌لر بولنماز، وحیله‌ءشرعیه اسمنده‌گی بوتلاعب فی‌الدین‌لرگه حاجت‌توشماز، وشریعت مقدسه‌مز بوتضاربلرغه وقضاایله افتاده‌بوقدر نفسانیت‌که ایپارتیلولرگه معروض بولماز ایدی.

امام مالك گه اویودن، وجعفرگ ذبیحه‌سینی آشاودن صاقلانور، وشوشنداین تعصب جاهلانه گه قابلانور ایدی دیوب ایتمگه کیم جسارت قیلور؟ حال بوکه بو مذهبلردن هر بر مذهب‌ده مرجحین اسمی ایله معروف بك کوب فقها واردر، که آنلرگ هر بری مجتهد وهیچ بری تماما اوز امامینگ مذهبی ایله متقیدد گل وآزمی کوبمی حکملرده آگا خلافلق قیلوب، ایکنچی مجتهدنگ دلیلی، یاخود اوز امامی طابمغان بر دلیل ایله، اخذ قیلور ایدی. چونکه اسلام، هر بر مسأله‌ده امامغه دگل، مشارعغه متابعت وموقع اجتهادده اوزندن افضل بولسه‌ده باشقه‌نگ اجتهادی ایله دگل، اوز اجتهادی ایله عمل گه قوشه‌درشونگ ایچون ابوحنیفه‌ده‌و باشقه همه فقهاده، ابوبکر وعمر کبی اصحاب عظامگ زورلق وفضیلتلرینی معین بیله‌واقرار قیلاطوروب اوزلری آنلره‌بك کوب احکام اجتهادیه‌ده‌خلاف کیتمشلردر؛ حال بوکه‌هر بر مذهبده اولان فقها، بوکونه‌قدر و بوکون، بیله بعض حکملرده امام‌نگ «مثلا ابوحنیفه‌نگ» اوزسوزی وبعض برلرنده اول امامنگ اصحابی «مثلا ابو یوسف یا که محمد» سوزی ایله آلونی درست کورمك‌ده هم آلمقده‌درلر. مونه بوندن آرتق طاغی نیندااین تلفیق کیراك؟ بس، مادامکه سزنگچه بوتلفیق درست، مادامکه سز اوزیگزده اصحاب ابوحنیفه‌نی، شافعی‌لر وامام مالك‌لر وابن عباسلردن افضل دیوب ایتمای‌سز! بس ابوحنیفه، شافعی، امام مالك وابن عباس سوزلری آره‌سنده بطریق اولی تلفیق درست بولورغه کیراك. عرض صحیح ایله بولغان وقتده‌تلفیق‌ده نینداین ضرر بولسون؟ حال بوکه تلفیق فلان حرام دیه‌رك دینده‌تشدید وجاهل تعصب سببلی مسلمانلر آره‌سنده‌تفریق، حتی حرم مکه‌ده، دورت امامغه‌دورت مقام وحرم مدینه‌ده، دورت محراب یصاب مجسم تفریق علامتلری قویمقلق الله‌تعالی‌نگ:

«اَقیمُوا الدّینَ وَلاَتتفرّقوا» دیدیکی کبی، سوزلرینه خلاف بك بیوك گناه‌در. صاچ ومیوق کبی، بك جزئی واهمیتسز ایشلرده‌هر بر دورلی تدقیقاتغه، کریشان علمای اسلامگ، حضرت رسولدن وخلفای

وتلفیق‌نی‌ده تلاعب‌فی‌الدین معناسنده حرام‌دیدیلر. بونلر آکثلامدیلر، که دلیللرنی نظر دقت‌دن کچوروب ومنافع‌عامه‌نی ملاحظه‌قیلارق دورلی مذهبدن،دورلی حکم، آلوبرده‌تلاعب فی‌الدین‌دگل‌بلکه‌عین‌صوابدر؛ حال بوکه بونلرگ تلفیق دیگان شیلری، من کل الوجوه عین تقلید ایدی بر آدم مقلد بولدیمی ملفق بولمایونچه ممکن‌دگل‌در، چونکه‌هر بر مسلمان،که بر مسأله‌ٔ دینیه‌ده اوزی‌هدایت طابودن‌عاجز بولدیمی آنی اهل‌ذکردن صورمق‌لغی، یعنی‌اول‌خصوصده‌بر مجتهد که تقلیدقیلمق‌لغی واجب‌در طبیعی هیچ بر مقلد یوق،که مجتهدلرگ بر سینی دیگرینه ترجیح که، قادر بولسون بناءً علیه هر بر مقلداوزی بیلمادیکی بر مسأله‌ٔ دینیه خصوصنده نینداین‌مجتهدطوغری کلسه شوگه تقلید قیلورغه مجبوردر.

اگر بر مقلد، عالم مالکی دیدیکنچه ایکی قله‌دن کیم‌و بر طامچی خمر توشکان‌صونی، طازادیوب‌شونگ ایله‌قویونسه وعالم‌حنفی‌دیدیکنچه دلك‌قیلماسه‌وعالم شافعی‌دیدیکنچه طهارتی‌بوزولغاندن‌صوگ باشینگ بعض شعراتینه، مسح ایلسه وعالم حنبلی دیدیکنچه بر آزقان چقغاندن صوگ، ایرته نمازینی اوقوسه وعالم زیدی دیدیکنچه بونمازنی، طلوع شمس صوگنده قیلسه وعالم جعفری دیدیکنچه اولگی فرض‌دن چقمایونچه، ایکنچی نمازغه وصل ایلسه، بومقلدنگ نمازی عند الله جائز دگل دیوب کیم اثبات قیلور؟ هیچ کیم قیلا آلماز. حتی بو نمازنگ خلاف اولی بولمق‌لغینه‌ده دلیل طابمق‌لق مشکل‌در؛ چونکه هیچ‌بر مقلدامور دینیه‌سی‌نگ همه‌سینی معین بر عالم‌دن آلورغه شرعا اصلا مجبور دگل‌در، اصحاب کرام‌ده اجتهاد واحکام‌ده اختلاف قیلدیلر وشولای بولا طوروب برسی دیگرینه اویوب نماز اوقودیلر؛ حال بوکه بونلر اوز اجتهادلرینه بناءً امام‌نگ نمازی درست دگل وآنگ درستلگی صلوة مأموم‌نگ صحتینه شرط دیوب حاکم‌ایدیلر. بس اصحاب عظام عموما بویله قیلدقلرندن‌صوگ ابو حنیفه،

هر بر جهالت تقلید و تسلیم ایله اوْرتولدی، هر بر فرقه اوْزینگ ایسکی شیخی چغارغان کتابلرغه ظاهر نص‌غه خلاف بولسه بیله تعصب قیلا باشلادی، وخلافیات‌نی هوالرینه تطبیق‌غه مدار ایتدی، هیچ برسی آدملره دین بابنده یصادقلری آغرلق‌لرنی بوینینه آلودن قورقمادی. بونلر: اختلاف امت، رحمت دیدیلر. درست رحمت؛ لکن اگر حسن استعمال قیلنسه؛ اما اگر بوکون قزان وبخاری اهالی‌سی ایله ایران اهالی‌سی آراسنده بولندیغی کبی، دینده تفرق وتباعض‌غه سبب قیلنسه اول وقت قایه رحمت که، سبب اولسون بالعکس سبب لعنت وهلاکت‌در. بونلر هر برسی اوزلرینی فرقهٔ ناجیه وباشقه‌لرنی مبتدع دیوب جدال‌غینه دگل حتی محاربه‌لر قیلشدیلر. بس الله تعالی کلام کریمنده هر براورنده اتحاد ایله قوشه وقلوب اصحابک الفتینی الله‌نک رحمتندن عد قیلا طوروب قایسی عاقل بوتفرق‌نی رحمت دیوب ایتور؟.

درست، ایسکی‌ده‌گی اختلاف، هیچ بر تعصبسز وکتاب ایله سنته غیری، هیچ برشی‌گه باغلانوسز بولغانلقدن، بك فایده‌لی وامت‌که، بك بیوك رحمت ایدی. چونکه هر بر فقیه اوزینگ اطرافندغی خلق‌نگ احوال ومصالحینه قاراب حکم یورتور ایدی. هیچ کیم بر مذهب‌که باغلانوب، اول مذهب‌نگ احکامی بر قومنگ اخلاقینه، یاکه احوال معاشیه‌سینه یاخود طبایع بلادینه موافق وملایم کلسون، کلماسون حکم ویرماز ایدی. هر بر فقیه هر بر مذهب‌نگ ادله‌سنده نظر وتدقیق قیلور وقایسی‌سی‌نگ دلیلی قوتلی بولسه شونگ ایله حکم ویرور ایدی. صکره بر زمان کلدی هر بر قوم یاترجیح یاکه وارثت یاخود مجرد تعصب ایله معلوم مذهبلردن بر مذهبنی اختیار وشول مذهب‌نگ هر بر حکمینه دیلاسه ملایم، دیلاسه غیر ملایم اولسون صوقور تقلید ایلدیلر. بر حکم اوزلرینه ضرر وآنی یوکلاو بك آغر بولسه ده وایکنچی مذهبده آنگ خلافینه، بك آچق دلیللر کورنسه ده بر مذهب که، مقلدنگ ایکنچی مذهبدن بعض احکام آلووینی تلفیق

قالمادی. بو مذهبلرده تألیف وتصنیفلر کوبایدی، هر بر آدم بن دقایق شرعیه‌نی استنباط وعله‌لرنی،مذهبلرنی تقریر قیله‌م دیوب ایش باشلادی، هر بر مؤلف اوز فضیلتینی ظاهر قیلورغه دوروشدی. جداللر تناقضلر کوبایدی؛ حتی عالم،صالحلردنده بعضلری او زلری سیزمایوب بونلره قاطشقالادی. بو مسکین‌لر توزوکلك شونده دیدیلر ؛لکن آنگ عین فساد ایکانلگندن غفلت ایلدیلرده الله‌تعالی‌نگ: «وَاِذَا قِیلَ لَهُمْ لَا تُفْسِدُوا فِی الْاَرْضِ قَالُوا اِنَّمَا نَحْنُ مُصْلِحُونَ؛اَلَاۤ اِنَّهُمْ هُمُ الْمُفْسِدُونَ وَلٰکِنْ لَا یَشْعُرُونَ» دیگان سوزینه مصداق بولوب کیتدیلر .در واقع بونلر: «قُلْ هَلْ نُنَبِّئُکُمْ بِالْاَخْسَرِینَ اَعْمَالًا اَلَّذِینَ ضَلَّ سَعْیُهُمْ فِی الْحَیٰوةِ الدُّنْیَا وَهُمْ یَحْسَبُونَ اَنَّهُمْ یُحْسِنُونَ صُنْعًا» دیگان آیة کریمه دلالت قیلدیغی کبی، عمللری ایله اوزلرینه گینه دگل، بلکه بتون اهل اسلامه ضرر وخسران کتورمش آدملردر.

مونه شوشلای احکام شرعیه‌نگ دائره‌سی دورلی خیالات ایله کیگایتلدی‌ده صوکغی‌لر قایه اصول‌غه مراجعت، حتی‌فروغ‌نی التقاطدن بیله عاجز قالدیلر. بس امت تقلیدکه قرار لاندی، عالم اسمنده گیلر شول دین اسمنده گی خیالات‌ده‌تعمق که‌یابشدی.هیچ کیم‌دن دلیل طلب قیلمغانلق‌دن مفسرلر تفسیر کتابلرینی عجیب واقعه‌لر وجن حکایه‌لری ایله طوطوردی.سند صوراو عادتی کیسلگانلك‌دن محدثلر،دیلسه موضوعه بولسون، هر بر نوادر اخبارنی جمع قیلورغه طوطوندی.وجه استنباطنی صوراو فورمه‌سی کوبدن بیتکانــلك‌دن فقیه‌لرده دورلی دورلی شبهه‌لر ایله استنباط حکم گه‌قالقشدی. بس همتلر کیمودی، بیتدی. شول قدر،که حتی ایمان ایله کفر آره‌سنی فارق واساس اسلام اولان توحید مسأله سنده‌بیله تقلید اختیارقیلندی.ظلمت نوردن،حق باطل‌دن آیرلمادی. کتابلر قاطرغه‌سی آره‌سنده نه کورنسه شونی استحسان قیلنه باشلادی.

تمام آکلاشیله‌چق‌در . مونه قرآن‌نک هر بر زمان معجز بولووینک سری أشبودر . درواقع حکماء یونان تقریر ایلدکلری،وعقول‌بشرک بیکلرچه یل تصدیق قیلدقلری، وحقیقت دیوب بیلدکلری قواعدک بك کوبسی‌نک خرافات ایکانلکی بوکون تمامیله میدانه چیقدیغی حالده قرآن وسنتک، کون بکون کشف اولنان حقایق ثابته‌گه موافق بولوب بارووی؛ البتة اک بیوك وعلماء عندنده بك مقبول، علمی اولان معجزه‌لردندر. ایسکی ویاگی حکمادن اک حکیم بر آدمک حکمته دائر سوزلرندن فقط بارماق ایله صانارلق بك آزی حقیقت بولدیغی‌حالده، اخلاق وتشریعه هم سیاست وتعلیمه وبوندن باشقه‌لره دائر، تعدادی مشکل قواعد قرآنیه وسنیه‌نک هر برسی‌نک موافق علم وعرفان بولوب چقمق‌لغی؛ البتة عقول حکمانی شاشیرته‌چق و آنلر عندنده قرآن ایله سنت‌نک قدر وحرمتینی بك آرتدیره‌چق حاللردندر؛ لکن بو حقیقتلر وبو معجزه‌لر تقلید بلن دگل؛ فقط اجتهاد بلن میدانه‌چغه‌چق‌لر،ومدرسه‌لر طولی اوقی‌طورغان شاکردلرمزنک مسلمانلق‌لری‌ده تقلید بلن دگل، بلکه اول اسلامه خلاف خرافات، بدعت وتشدیدلری بترو ایله محافظه اولنه‌چق‌لردر. اویله خرافات‌که، خلفای عباسیه زماننده باشلانوب بوکونه قدر آرته آرته کیلمشلردر.

نه وقت‌که، خلفای عباسیه علم کلام‌ده تعمیق نظر قیلا باشلادیلر وبوخصوصده علمای اعاجم‌ده بك کوب خدمتلر ایتدیلر؛ مونه شول وقت قیل‌قال‌لر کوبایدی، کلام‌ده باشلانغان مناظره‌لر،جداللر فقه‌گه‌ده سرایت ایتدی، قایسی مذهب اولی؟ شوندن بحث‌که طوطونولدی. ابوحنیفه ایله شافعی آره‌سنده‌غی خلافیات خصوصنده جداللر باشلاندی، فتنه‌لر قوبارلدی، صوغوشلر آچلدی، هرکیم اوز مذهبینی ترویج وباشقه‌لرنی ابطال اجتهادینه کرشدی؛ حتی جزیرهٔ عربده زید ایله احمد،غربده مالك، بخاری وترکستانده حنفی‌مذهبلرندن باشقه مذهبلر

مونه الله تعالی سزه اولان خیرنی تعلیم قیلدی. وزمان ایله مکاننک اختلافی سببلی، مختلف اولان حکملرنی سزنک تدقیق و اختیارکزه قویدی، حتی انسان اعمال حیوایه‌سنی مباح دیوب بیلوب ایشلاسون! تقلید تقدیرنده‌گی کبی، امرالله‌غه اصابت قیلدممی یوقمی دیوب مضطرب بولماسون! وهر برزمان وهر بر مکان‌غه مناسب بولغان حکملر قیلوب شدت وطارلقلردن قوتلسون! لکن سز بولای قیلمادیکز! بلکه بتونلای امرالله‌غه خلاف، تقلید سببلی خراب بولدیکز! بعینه یهود ونصاری یوللرینی تعقیب ایلدیکز! بونلرکده احبار وراهبلری دین اسمندن تورلی شدتلر قیلدیلرده، اهالی‌نی ایزوب حیواندن کیم بردرجه‌گه دوشوردیلر، بونلر نه‌ایتسه‌لر شوکا متابعت، عوام‌اوزرینه فرض وکتب آلهیه‌نی قاراو، حرام وتثلیث‌معنالرینی‌ایسابلاو، کفر ایدی قاچان‌که آوروپاغه اندلس‌مسلمانلری آرقولی‌علم، معرفت کیره‌باشلادی؛ علم ایله اجتماعسی ممکن اولمغان نصرانیت‌ننک خواص یاننده قدری بیتدی، انصارعلم ایله انصار نصرانیت آره‌سنده بك دهشتلی قانلی واقعه‌لر اوزدی وبالاخیر علم‌ننک نصرانیت‌که غلبه‌سی ایله ختام‌بولدی. مونه حضرت عیسی علیه السلام‌ننک دینی، تحریف قیلنوب علم‌گه مخالف بر خیانت‌که صوغولدیغی ایچون شوشی تأسفلی حال‌گه اوغرادی. سز! مونه بونلرنی‌بیلورگه وتقلیددن هم اسلام‌علم‌گه مخالف دیوب ایتودن توبه قیلورغه کیراك‌ایدی؛ لکن مع التأسف‌سز، شول یولده همان دوام قیلاسز، سز! شوشی طریق مستقیم ایله اسلامیت‌نی محافظه قیلمقچی بولاسز، اگرسز بوطریق‌ده دوام‌ایتسا کز نصرانیت باشینه کیلگان بلانی«الله کورساتماسون»اسلام‌باشینه کتوره‌چك‌سکز! اساس اسلام‌ده علم‌گه مناقض هیچ برسوز یوق بلکه اسلام هروقت عقل‌غه خطاب قیلدیغندن وبوکون مدققلرننک آکلادقلری کبی، کشف قیلنغان علم حقیقی هر برسی قرآنده صراحة یااشارة ذکر اولندیغندن علم آرتقان صایون اسلام قوتلانه‌جك، وآکا ایمان آرطاجق وقرآن‌ننک مخلوق ایشی دگل بلکه کلام الله ایکانلگی

عبادات ومعاملاتده بر مذهبده بولماسه دورت مذهب آره‌سنده غیر خلافیه بر مسأله کز یوق که، حتی تقلید کزده انتظام فلان متصور اولسون. اگر اجتهادوحریت یولینی طوتسه ایدیکز ادلهٔ شرعیه‌نی قارار واحوال‌زمان و طبیعت مکان‌غه‌موافق بولغان‌شق‌نی اختیار قیلورده بو عدم انتظام‌دن قوتولورایدیکز. درست ایکی او چ آدم‌نک اقوالینه‌توفیق عمل غیرمخصور آدملرک اقوالینه‌توفیق عملدن آسانراق توسلی کورینه‌درحال بوکه حقیقتده ایکی ضدبولغان قول آره‌سینی جمع بعینه اقوال متضاده آره‌سینی جمع کبی ممکن دگل‌در. حال بوکه سزگچه‌ده زمان اجتهاد قرن خامس آخرینه قدر منقرض‌اولمغانلقدن سز متابعت‌نی تجویز ایدن مجتهدلرده غیر مخصوردرلر. حال بوکه بو امرخصوصنده هیچ کیمرأی مجردی ایله تصرفی ممکن‌دگل، بلکه کتاب ایله سنت‌که هم مصالح ناس‌غه مراجعت‌قیلورغه کیراك. بو وقتده مجتهدلر بر اورنده‌جیولوب اکثریت آراء ایله حکم و قرار و یرد کلرنده، قایا اقوال متضاده بلکه قولین متضادین چغارغه‌ده ممکن‌دگل‌در. مونه بو وقتده اون‌قرن‌مقدم اوزغان کشیلرنک ایسابلری ایله یوروا حمقلغی‌اختیار قیلنماز وعوام‌هم‌خواص نظرنده شرع مقدس‌نک قدر وحرمتی کیتماز وبخارا صاردلری کبی محکمهٔ شرعیه‌دن قاچوب ایوان حکمینه وارلماز.

سز الله تکلیف قیلمغان شیلر ایله اوزیکزنی تکلیف قیلوب ماتاشاسز! اگر اسلام‌ده معلوم بو تکالیف‌دن‌زیاده‌سی خیرلی بولسه ایدی الله تعالی آنی مهمل قویماز وسزی آندن منع ایلماز ایدی. حال بوکه الله تعالی بر اورنده دین که متعلق ایشلر خصوصنده «مَا فَرَّطْنَا فِي الْكِتَابِ مِنْ شَيْءٍ» ودیگر بر اورنده «اَلْيَوْمَ اَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَاَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْاِسْلَامَ دِينًا» دیوب امور دینیه‌نی تمام قیلدیغنی سویلادیکی حالده دخی بر اورنده «تِلْكَ حُدُودُ اللهِ فَلَا تَعْتَدُوهَا وَمَنْ يَتَعَدَّ حُدُودَ اللهِ فَاُولٰئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ» دیوب الله تکلیف قیلمغان شی‌نی تکلیف‌دن منع ایلمشدر.

قیلوب قارامغه آنسی نه طور روشو هر برطبیب غه لازم در بزم امام لرمز ایسه بک زیاده اختلاف قیلشمشلر، طهارت و ستر عورت مسأله لرنده بیله بر اتفاق غه کیله مامشلر؛ حتی اصحاب شافعی نڭ «شافعی ایسکی مذهبینی قویوب یاڭی مذهب گه قایتدی» دیدکلری و حنفیه نڭ ابو حنیفه دن بر مسأله خصوصنده اقوال متناقضه نقل ایلدکلری کبی بو امام لرنڭ هر برسی بر وقتده بر حکم نی، قیلوب ایکنچی وقتده آڭا بتونلای باشقه ایکنچی حکم نی و یرمشلردر. دیمك که بو نلرنڭ حکملری قلب قرارلانورلق قطعیت درجه سینه اصلا یاقین کیلمامش در.

بناءً علیه احکام دینیه ده متحری اولان هر بر اهل فهم ادلهٔ شرعیه دن اوزی استنباط قیلورغه تیوشلی در. صواب غه ایرشسه ایکی ثوابلی خطا قیلسه بر ثوابلی اولور بس انسان نڭ حریت و اختیار حکمتلرینی محافظه ایدرك استنباط ایله شغللانوی اوز اوزینی خطانی محتمل گه اسیر قیلودان خیرلی رك در. بس مقلدلرنڭ «زمان یراق کیتکان تفتیش قیلورغه بزم قدرتمز یوق؛ شونڭ ایچون غیر صوابنی بزدن آرتق بیلان و خطاسی بزدان آزراق اولان ایسکی بر امام غه تقلید اقرب الی الصواب در» دیدکلری سوز باطل و بطلانی ده اوز اوزینه معلوم در. چونکه قدما اختلاف قیلشقان شی ده بر طرفنی، سزنڭ دیدیککز چه دلیلسز حتی ظاهر نص غه خلاف بولسه ده اخذ قیلمقلق ترجیح بلا مرجح حتی ترجیح مرجوح و الله تکلیف قیلمغان شی نی تکلیف در.

احتمال سز مقلدلر دخی ایتورسز «اگر بز کتاب، سنت و اجماع دن دلیلینی طابمادیغمز بر شی نی شریعتمزدن صانامسه ق عباداتمزده ده معاملاتمزده ده احکام شرعیه بك طارایورغه و قضالرمزده ایجابات شرعیه ایله مقید بولمایوب هر بریمز عبادات و معاملات دقایقنده رأیمز ایله عمل گه مجبور اولورغه تیوشلی بولادر، حال بو که انتظام معاملات عدم انتظام دن خیرلی رك در» دیوب، لکن سز اوزیککزده بلکه اڭلارسز که، انتظام، تقلید و رقیت ده دگل بلکه اجتهاد و حریتده در

دیوب ایتوب طورەسز ! حتی قرن خامس صوڭنده بیله بك کوب علمانڭ اجتهادلری بدیهة درجه‌سنده ثابت بولغان شیلردندر: تفتازانی حاشیهٔ عضدی‌ده‌دیمش‌درکه، کلام‌قوم‌دن‌فقیه، مجتهداولمایونچه‌ومجتهد، فقیه اولمایونچه متصورد گل‌لك آڭلاشیلادر مفتی، فقیه‌اولمق‌لازم‌ایدی بس‌مجتهد اولمق‌لغی‌ده‌لازم اولورغه کیراك. حتی‌شافعیه قـاضی‌ده‌ده مجتهدبولونی شرط ایلمشلردر، حنفیه‌ده‌اهل اجتهاددن‌بولمغان‌قاضی‌نی اهل‌اجتهاددن‌بولغان‌مفتی‌قول آستونده بولسه‌غینه نصب جائز دیمشلردر، هدایه‌قاضی‌نڭ اهل اجتهاددن بولمق‌لغینی شرط‌قیلغان. شرح‌هدایه، مختصر الوقایه هم‌ملتقی‌الابحر اجتهادنی فقط‌شرط‌اولویت دیسه‌لرده فتح‌القدیر: «غیرمجتهدگه‌تقلیدقضا شافعی، مالك، احمدهم‌بزم‌علمامزدن محمدعندنده درست‌دگل‌در» دیوب‌تصریح‌ایلمش‌در. ومجمع الانهر فتح‌دن: «استقر رأی الاصولیین‌علی‌ان‌المفتی‌هوالمجتهد» دیگان‌سوزنی نقل‌قیلمش‌در. دیمك‌که‌غیر مجتهدقاضی‌نی نصب‌نڭ جوازنده اختلاف بولسه‌ده غیر مجتهد، مفتی‌نی‌نصب بالاتفاق جائزدگل‌در. بس‌مادامکه مفتیلرو قاضیلرنی نصب‌زمانی هیچ‌بر وقت منقرض‌دگل‌ایدی. بناءً‌علیه زمان‌اجتهادده هیچ‌بروقت منقرض‌بولماسقه کیراك. شونڭ ایچونده فتح‌القدیر «فقه‌نی‌عالم وصاحب‌الکتاب والحدیث، هم‌قریحه‌سی صحیح وعادات ناس‌نی‌عارف بولغان آدم‌نڭ اجتهادی‌واجب هیچ کیم گه‌تقلیدی درست دگل» دیوب قطع ایلمش‌در.

سزمقلدلر! «ائمهٔ اربعه، بك‌ایسکی واوزلرینه تابعلر، بك کوب بس آنلرڭ سوزلرینه اعتمـادلازم» دیوب کثرت‌وقدم‌ایله دلیل ایستای‌سز! حال‌بوکه‌اگر صوابلق کثرت‌وقدم ایله‌اولسه ایدی، نصرانیت وآندن زیاده‌وثنیت صواب بولورغه کیراك‌ایدی‌احتمال‌سز ایتورسز «طبیب‌طبایع مفردات‌نی‌تجربه‌ایله مکلف‌بولمادیغی‌کبی بزده‌احکام‌جزئیه‌ده اجتهادایله‌مکلف دگل‌مز» دیوب‌لکن؛طبیب تمام آڭلاشلغان واتفاق اطباحاصل بولغان‌شیلرنی گینه. یا گادن تجربه‌ایله مکلف‌دگل؛ اماتمام آڭلاشیلوب جیتمگان شیلرنی‌حق‌لق‌غه وصول‌ایچون تکرار تجربه

رسول ظاهر بولسه اول سنتنی هیچ کیمنڭ سوزی ایله قویو
درست دگل» دیه‌رك حدیث مقابلنده اوز سوزینی ترك ایله توصیه،
واوزشا کردلرینی اوزینه تقلیددن نهی قیلور ایدی. هم‌امام احمدده
اوزینڭ فتوی‌لرینی یازو وتدوین قیلوغه انکار ایتار ایدی بونلر
اوزلرینڭ بعض احکام‌ده خطا قیلاچقلرینی بك آچیق بیلورلر وبك
صریح اقرار قیلورلر ایدی، بونلر هیچ بر وقت اوز فتوی‌لرینی
«مونه بو حکم، قطعا الله ایله رسولینڭ حکمی‌در» دیوب ایتمازلر ایدی.
اگر ابو حنیفه‌نڭ حکمی معین حکم الله بولنسه ایدی آڭا شافعی‌ده،
محمدده، ابو یوسف‌ده هم‌باشقه‌لرده هیچ برسی مخالفت قیلمازلر ایدی.
اگر متأخرین ظن قیلدیغی کبی استاذنی تعظیم دیمك آنڭ هر بر
سوزینی وهر بر فعلینی دلیلسز حتی دلیل‌گه خلاف بولنسه بیله
تقلیددن‌عبارت بولسه ایدی، ایڭ ایلك صوقور تقلید ایدنلر محمد
ایله ابو یوسف بولورلر ایدی. سز مقلدلر! استاذڭزنی تعظیم‌ده علو
ایدرك «صالح اول خطا قیلماز» دی سزده ایڭ جاهل بر احمق‌غه
صوقور تقلید قیلاسز وانبیادن باشقه هیچ بر صالحنڭ خطادن معصوم
دگل‌لکینی خاطرڭزدن چیغاره‌سز وقبله‌نی کوزی کورگان وقتده‌ده
کوزینه اوشانمایوب یولدیز ایله استدلال قیلغان آدم کبی قیلاناسز.
بصیرة کوزیڭز ایله براهین شرعیه‌نی کوره طوروب آندن اعراض
وقول فقهاغه تقلید ایده‌سز! حال بوکه قول فقهانی کورنده شول
کوزیڭزنڭ عینی ایدی، سز اوشانا طورغان کلام کتابلرینڭ هر
برسنده عقل‌نی اسباب علم‌دن صانای طوروب سز براهین شرعیه‌نی
آڭلاو طوغری‌سنده عقل‌نڭ، سبب علم بولووینه انکار قیلاسز!
واشبو سببدن اوزڭز دعوا قیلدیغڭز بوکتابلره وبو خطاسز آدملره
تقلیددن چغه سز، سز اوزیڭز بواماملره تقلید لازم دی‌سز؛ حال بوکه بونلرڭ
اسلاف صالحین‌نڭ هیچ کیمه تقلید هم درست دگل دیوب اتفاق واجماعلرینه
قارشی کیده‌سز! اوزیڭز اشبو درت مذهبدن، چغو درست دگل دی‌سز
اوزیڭز ایسه آنلردن صوڭ قرن خامس آخرینه‌قدر اجتهادوار ایدی

ممكن والله‌تعالی‌نڭ قدرتینه وسنتینه بك موافق‌در. شونڭ ایچون افندمز علیه‌السلام «من احدث فی امرنا هذا مالیس منه فهورد» دیوب دین بابنده الله ایله رسولندن باشقه‌غه انابت یوقلق‌نی آڭلاتدیغی کبی ائمهٔ اربعه اوزلرینه تقلیددن نهی‌ایلمشلردر. ابوحنیفه ایله اصحابی «لایحل لاحد ان یفتن بقولنا مالم یعلم من این قلنا» دیدکلری کبی ایکنچی براورنده ابوحنیفه دخی «اگر بنم سوزم کتاب وسنت که مخالف ایسه‌سز آنی ترك ایدیڭز!» دیوب تصریح ایلمش‌در. مالك بن انس ایتکان «بن آدم اولدیغمدن صوابم‌ده یا گڭشم‌ده بولنور، شونڭ ایچون سز بنم رأیم‌ده تفکر ایدیڭز! اگر کتاب ایله سنته موافق ایسه طوطارسز یوقسه ترك ایدرسز» دیوب. دخی برمرتبه امام مالك حرم نبوی‌ده حدیث سویلادیکی وقتنده روضهٔ مطهره‌غه اشارت قیلوب «فقط‌بو قبر صاحبی‌نڭ سوزی ردقیلنماز. باشقه‌لرڭ همه‌سی‌نڭ سوزی ردقیلنه بیلور» دیمش‌در. امام‌شافعی هم «حضرت رسول‌دن باشقه هیچ کیم‌گه دلیل‌سز اتباع درست دگل» دیدیکی کبی، امام‌احمدده «دینڭ‌ده هیچ کم‌گه تقلیدقیلمه! رسولمز ایله اصحابندن روایت قیلنغان شیلرنی گنه‌طوت!» دیمش ودخی براورنده «بڭاده، مالك گه‌ده، شافعی گه‌ده‌اوزاعی گه‌ده‌هم‌ثوری گه‌ده تقلیدایتمه‌ڭز، بلکه آنلر آلغان یردن (دلیل‌دن) آلیڭز!» دیوب‌تصریح ایلمش‌در.

مونه ائمهٔ‌اربعه‌اوزلرینه‌تقلیدنڭ‌عدم جوازینه اتفاق‌ایلمش‌لردر. بونلر اجتهاد قیلورلر ورأیمز شوشی دیوب بیان ایدرلر ولکن هیچ کم‌گه بونی اخذ لازم دیوب‌ایتمازلر ایدی. ایستگان کشی آلور ایستمگان کشی یوق هرکیم اختیارلی‌ایدی. ابوحنیفه «بو، بنم‌رأیم‌در اگربر ادم بوندن خیرنی کتورور ایسه بن آنی قبول قیلاچقمن» دیدیکی کبی امام مالك‌ده، هارون الرشید آدملرنی «الموطأ» ایله عمل‌گه کوچلاو طوغروسنده استشاره ایلدیکنده «اصحاب رسول مملکتلرده طارالدیلر، هربرقوم عندنده باشقه‌لر ایشتمگان حدیثلر وار» دیه‌رەك آندن منع ایلدی. امام شافعی‌ده «اگر بر آدم‌گه سنت

دعوت ایدوب حریت فکرگه خلاف توشمازلر. بلکه هر کیم کتاب الله سنت رسولگه رجوع قصدنده بولنور، ایسکی امامرلرنگ سوزنی اساس طوطولوب قرآن ایله حدیث تورلی تأویللر ایله آنلره تطبیق قیلنماز، بلکه آنلرنگ سوزی کتاب ایله سنتگه موافق بولسه قبول یوقسه رداولنور واصحاب ایله تابعین هم ائمهٔ مجتهدیننگ «مسائل خلافیه واجتهادیه‌ده هر کیمگه حریت‌در» دیگان سوزلری بلن‌ده عمل بولور. درست بو وقتده احتمال، مذاهب‌واختلافات کوبایور، لکن‌عصر اول مجتهدلری کبی تعصب‌سز بولغان وقتده نزاع وتقاطعغه اصلا مؤدی بولماز، بس بر آدم اهل فهم‌دن بولدیمی مسائل اجتهادیه‌ده اوزفکری‌ایله عمل قیلور، قرآن وسنتگه دعوت ایدن آدملردن نفرتلانوب قاچماز وآنی فسق وکفر ایله سوکماز فقط ممکن قدر هربرشی‌نی آڭلارغه اجتهاد واستفراغ وسع ایدر وادلهٔ شرعیه‌دن احکام شرعیه‌نی ظن ایچون قدرتینی صرف‌قیلور. ایسکی‌لری تعظیم وصوڭغی‌لری تسفیه‌ده غلو ایلماز. علم تفسیر وعلم حدیث‌ده قدماء ایرشکان درجه‌گه ایرشو ممکن دگل دیماز وبیلورکه بعضیلر مجتهد بولو ایچون علم تفسیر وعلم حدیثده هم بونلر توقف ایدن علوم عربیه‌ده یدطولا صاحبی بولنمق‌لق‌نی هم عادات ناس‌دن خبردار اولنمق‌لق‌نی شرط دیسه‌لرده، مختار شاطبی‌نڭ مواقفات‌ده دیدیکی کبی علوم عربیه‌نی متنا واسلوبا آڭلاب مقاصدشریعت‌نی علم کافی‌در. شونڭ‌ایچونده مجتهدنڭ برحدیث‌نڭ صحیح وضعیف بولمق‌لغی کبی مبدأ اجتهاد اولان فنلرده بیله غیرمجتهدگه اتباعسی‌نی درست کورمشلردر. حتی امام ابوحنیفه بیله بالاتفاق مجتهد بولا طوروب آننگ زماننده خصوصا عراقده روایت حدیث کوب اولماغانلقدن احادیث‌دن بك آزینی‌غینه علم‌گه موفق اولمش‌در. الله تعالی‌نڭ مخلوقاتده اولان سنتی کون بکون ترقی‌ده وشونڭ ایچونده دینلرنڭ آخری اولان اسلام اکمل ادیان بولغانلقدن بو زمانده‌ده قدماء درجه‌سنده بلکه آنلردن عالم کشیلرنڭ وجودی بك

وقت اوزغانلقدن، سز بونلری آکلایامزسز! شونک ایچون سز قرآن ایله حدیثکه معارض بولسه‌ده فقها سوزینی آلاچق وزمانکز مصالحینه موافق‌می دگل‌می برده‌قارامیوب شونک ایله عمل‌قیلاچق‌سکز! مونه‌سزک‌مسلمانلقکزشوشنده‌وضلالتکز بونک‌خلافنده‌در» دیوب ایتسه‌ك بونلرک اسلامه محبتلری توشارمی؟ بونلر اوز عقل وفکرلرینی اوتوروب ایسکی فقها سوزینه باش اویارگه واوزلرینی احمق وسفیه دیورگه راضی بولورلرمی؟ بونلرنی قهستانی‌لر، ولوالجیه‌لرگه نچک اوشاندرمق کیراك؟ یوق بونلر، ایسکی فقها سوزی بلن دگل بلکه طریق معقول ایله یورویه‌چکلردر. اگر دینمزنی اهل‌تقلید ظن قیلدیغی کبی، بولای طاربر (رام) ایچنده کورساتسه‌ك اول‌وقت‌قایامتمدن ملل اجنبیه‌نی اوزمز، اسلامه یاقنلاشدیرو؛ بالعکس اوز آره‌مزدن معرفتلی آدملرمزنی‌ده «الله کورساتماسون» اسلامدن بیزدره‌جکز واوز آیاغمزه اوزمز بالطه اوره‌چغز. بس بونلری دائرهٔ اسلامده جمع، وشوکت ملیه‌مزنی قوتلاو ایچون، بزه لازم اولان‌شی، اسلامنی تفتیش ایدوب اصلنده‌کی ساده‌لکینه قایتارمق وهرکیم‌گه اوزعقلنچه آکلامیه رخصت ویرمك‌در. مونه بو وقتده اهل اسلام الله‌تعالی‌نک: «اَلَّذِینَ آتَیْنَاهُمُ الْكِتَابَ یَتْلُونَهُ حَقَّ تِلَاوَتِهِ اُولٰئِكَ یُؤْمِنُونَ بِهِ» دیوب مدح ایلدیکی کبی ظاهرگه قاتمازلر، تقالیدگه یابشمازلر، امانی وظنون ایله کفایه‌لنمازلر، اسرار قرآن‌نی آکلارلر، فائده تکلیف وحکمت تشریعنی بیلدررلر، ایسکی فکرلرنی تقدیس قیلمازلر. بس بونلرک ایمانلری قوتلانوب دنیا وآخرت مسعود بولورلر، بونلر الله‌تعالی‌نک «وَمَنْ یَكْفُرْ بِهِ فَاُولٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ» دیوب ذم قیلدیغی کبی دینلرینی آکلامایونچه دورلی تقالید ومخترعات ایله ایزماسلر وانواع بدعت وعادتلر توتاشدیروب بوزماسلر اوزلری تفکر ایدرلر لکن باشقه‌لرنی اوزفکرلرینه

وافندمز عليه السلام نـڭ: « لتتبعن سنن من قبلکم شبرا بشبر و ذراعا بذراع »
دیگان سوزینه مصداق بولوومز نی برده سیزمای مز؛ بو آیتلرڭ بطلان
تقلیدگه دلالتلرینی و صدر اولنـڭ شوکا، اجماعسنی و اول وقت جاهل،
عالمدن اعتقادنی فقط برهان ایله احکامنی فقط روایت ایله آلولرینی و بینه سز
برهانسز دیلسه نچك هیچ بر تقلید ایتماد کلرینی اصلا عقلمزه کتورمای مز.
درست شریعت: عاقل مهتدی گه تبعیت دن منع ایتمای در؛ لکن متبوعنـڭ
دلیلینی بیلمایونچه طوروب آنـڭ عاقل مهتدی ایکانلـگینی قایدن بیلورگه
کیراك؟ شونـڭ ایچونده الله تعالی حضرتلری یوغارغی آیتلرده آتاو بابالرینه
دلیلسز اتباع ایدن آدملرنی ذم و تقبیح صوکنده: « وَمَثَلُ الَّذِينَ كَفَرُوا
كَمَثَلِ الَّذِي يَنْعِقُ بِمَا لَا يَسْمَعُ إِلَّا دُعَاءً وَنِدَاءً صُمٌّ بُكْمٌ عُمْيٌ فَهُمْ لَا يَعْقِلُونَ »
دیو بو تمثیلنی کتورمشدر.

یعنی بو مقلدلرڭ حالی قوی ایله کتوچی حالی کبی در. کتوچی
بر لفظ و بر صدا و یرسه قویلر کلدیکی ودیگر بر صدا ایله کتدیکی و بو
صدالردن هیچ برشی آڭلامدقلری واقبال هم ادبار سببلرینی اصلا
بیلمادکلری کبی، دلیلسز بر اعتقادنی تسلیم و تعلیلسز بر فقه ئی قبول قیلان
آدملرده اقبال هم ادباردن برشی ده آڭلامازلر. بو آیت بك آچق
کورساتادرکه عقلسز تقلید کافرلر ایشی در؛ دینینی دلیل ایله بیلمیان
بلکه مجرد تسلیم ایله تلقی ایدن آدم بو آیت بویونچه مؤمن دگلدر؛
ایماندن مقصد حیوان باغلاغان کبی آدمنی بر باغانا، بر مذهب گه باغلاب
قویو دگل بلکه عقول بشریه نی علم و معرفت درجه لرندن یوغاری
مینگزودر. بس مونه بو آدم خیرنی، خیر دیوب بیلوب قیلور و شرنی
شر دیوب سوء عاقبتینی بیلوب ترك ایدر.

بس بو وقتده بزگه ملل متمدن نی اسلامه دعوت قیلمقده ممکن
اولور. اگر بز بوکون ملل متمدن گه: «مونه بزم شریعتمز اشبودر:
مجتهدلر طرفندن توزولوب بیتمشدر، قرآن ایله حدیثنی آڭلار

قایتووی بك احتمال قریب‌در. شونك ایچون عقللی آدم هیچ برسی یالغان عذرلر کورسته‌رك الله ایندرگان شیلرنی طاشلاب باشقه برکشیگه عقلی نه‌قدر کامل بولسه‌ده تقلید وصوقور اتباعنی جائز کورماز وبك آچق بیلورکه آدم نه‌قدر عقللی ونه قدر حسن السیره بولسه‌ده بر وقت فکرنده خطا قیلمایونچه قالماز. شونك ایچون قائل‌گه روحسز تقلید قیلورغه دگل بلکه دلیل‌گه قاراب قول‌گه اتباع قیلورغه تیوشلی‌در.

«انظر الی ما قال ولاتنظر الی من‌قال» شونك ایچونده الله‌تعالی کلام کریمنده «فَبَشِّرْ عِبَادِیَ الَّذِینَ یَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَیَتَّبِعُونَ اَحْسَنَهُ اُولَئِكَ الَّذِینَ هَدَاهُمُ اللهُ وَاُولَئِكَ هُمْ اُولُوا الاَلْبَابِ» دیمش‌در. شونك ایچونده امام غزالی تقلیددن چغوب هر بر مذهبدن دلیلینه قاراب سوز آلونی مقلدلرنك تلفیق دیولرینه رغما «منقد من الضلال» اسملی کتابنده تقلید توبانچیلکندن استبصار دروه‌سینه بینووینی بك شادلانوب تشکر قیلوب یازمش‌در. درست بك معلوم مقلدلر تلفیق‌نی حرام دیلر. لکن آننك حرمتینه نیندایی دلیل وار؟ اگر برکشی دعوا قیلاچق ایسه‌رحیم ایتسون! بزه کورساتوب‌قاراسون. بونلرنك هیچ‌بر دلیللری یوق، فقط‌بونلر الله تعالی‌نك «وَمِنْهُمْ اُمِّیُّونَ لَایَعْلَمُونَ الْكِتَابَ اِلَّا اَمَانِیَّ وَاِنْ هُمْ اِلَّا یَظُنُّونَ» دیدیکی کبی آدملردر. علمای اهل کتاب‌ده کتابلرینی اوزگارتدیلر دورلی تأویللر ایله احکام‌الهیه‌دن چقدیلر. اوزخیاللرینه وجود ویروب شونی کتابلری قارشوسنده اعتبار قیلدیلر. هدایت‌وقتنده‌غی سلفلری ایله ماقطاندیلر وشونی‌اوز سعادتلرینه کافی‌دیوب حساب‌ایلدیلر. شول سببدن آنلرنك دینلری اساسندن‌چقدی بوزولوب بتدی. بزمونه‌بوخبرلرنی‌اوقیمز، آنلری مسقل‌ایتوب کولامز، بیك‌عجبلانامز؛ اما اوزمزنك آنلره‌تماما‌ایپاردیکمزنی

بیتروب ادلــه وبراهین‌گه قایتارو ایچون بعث قیلنمش
و «اذ تبرأ الذین اتبعوا من الذین اتبعوا» دیوب دلیلسز تابعلری
ذم وتقبیح ایلمش‌در. الله‌تعالی حضرتلری «ولا تتبعوا خطوات الشیطان
انه لکم عدو مبین انما یأمرکم بالسوء والفحشاء وان تقولوا علی الله
مالا تعلمون» دیه‌رك دلیل سز وعلم سز سویلیان آدملری یعنی
مقلدلری شیطان‌تابعلری دیه ذم‌قیلاطوروب متأخرین‌نڭ قرآن
وحدیث‌دن اعراض‌قیلولری وبر مذهب‌گه کردیلرمی قارشی‌لرنده‌طاغ
کبی‌دلیللرکتورلسه‌ده فکرلرنده همان‌ثباتلری‌بك‌زیاده تعجب‌اولنه‌چق
برحالدر. بونلر کمال حماقتلرندن تقلیدایله‌دین صاقلایمز دیوب ظن
قیلالر. حال‌بوکه اگر تقلید ایله والله‌ایله‌قول آره‌سنده واسطه‌یاصاب
آیت وحدیثلردن اعراض‌وعبادك قلبلرینی‌اول‌ارحم الراحمین‌دن
صوووتو ایله‌محافظهٔ‌دین حاصل‌بولسه‌ایدی الله‌تعالی حضرتلری
«واذا قیل لهم اتبعوا ما انزل الله قالوا بل نتبع ما الفینا علیه آباءنا» دیوب
تقلیدنڭ بطلانینی‌ومذهب‌تقلیدنڭ‌فسادینی‌سویلاماز و بوندن‌صوڭ
(اولوکان آباؤهم لایعقلون شیئا ولا یهتدون) دیه‌رك‌خطاب آڭلامغان
ودلیللره قاراماغان آدملری‌حیوان منزلینه‌ایندرماز ایدی. اگرمقلدلرڭ
آڭلای طورغان‌قلبلری بولسه‌مونه بوآیت‌براوزیده‌تقلیددن‌وایسکی
عادتلرنی مقدس صاناودن‌نفرتلاندیروده وکتاب‌الله‌ایله سنت‌رسول‌دن
اعراض‌نڭ حرام‌لغنده کافی‌در.

بو آیت آڭلاتادرکه بونلرڭ تقلید ایلدکلری ذاتلری
حقلق‌غه وصول ایچون هیچ بر دلیل‌ده نظر قیلمادقلرندن همه‌سی
خطاده‌درلر. حقلق‌نی معرفت ایچون دلیل‌ده نظر قیلا تورغان آدم
بر وقت خطاغه توشسه‌ده ایکنچی وقت دخی تفکر ایدوب صواب‌غه

دیه‌طوروب شریعت اسلامیه‌نی ایستادکلری قدر طارایتدیلر واجتهاد تقدیرنده بیك کوب مشکل مسأله خصوصنده کتاب‌الله‌ایله سنت رسول‌ده طابیله‌چق کیک ایشك‌لرنی‌قارانغی تقلید، پرده‌سی‌ایله‌قاپادیلر. بونلر هیچ بر عقل یورتماد کلرندن و هر بر دلیل‌گه جهالتلری ایله‌مقابله ایله‌دکلرندن، آنلر ایله‌سویلاشورگه‌ده‌ممکن‌دگل‌بلکه آنلری طوطوب طوب‌طوری بیمارستان‌غه جیبارملی‌در. چونکه‌بونلر یوزندن‌اهل‌اسلام باشینه کیلگان ضرر، فایده‌لرندن دفعاتله کوبرك‌در. فقط‌بونلرگ ظالم‌سلطان‌وامراغه فایده‌لری‌تیمش‌در.

چونکه ظالملر هر وقت جهالتدن استفاده ایدرلر و بولغانچق صوده بالق طوتمق ایستارلر. ظالملرنگ دنیاده ایک قورقدقلری شی‌لری علم‌ومعرفت‌در؛ تقلید کبی علم ومعرفت‌نی باطیرن باشقه هیچ برشی یوق؛ عوام نی طونار وایستادیکی ظلم‌نی یورتو ایچون ایک برنچی‌وسیله اجتهادوحریت فکرنی‌بیترودر. شونک‌ایچونده ظالملر: «زمان اجتهاد منقرض» دیگان فتوی نی اوز زمانلرنده‌غی علمادن یاقورقوتوب، یاصاتوب آلمشلردر.

بوکون اشبوتقلید بلاسی شول قدر عمومی لاشمش وشول قدر طامور جایمش‌در که، اگر بر آدم قرآن ایله سنته قایتوغه دعوت قیلدیمی، آندن نفرتلانه‌لر، قاچالر ودورلی کفرلر ایله رمی قیلالر. حال‌بوکه‌الله‌تعالی‌حضرتلری«اَم تقولون اَنَّ اَبراهیم واَسماعیل واَسحق ویعقوب والاَسباط کانوا هوداً اَونصاری» دیوب آگلاتمش درکه، انبیای کرامنگ هیچ بری تقلید بویوندرغینه کرمامشلر بلکه یالگز دلیلدن آگلاشلغان حق‌غه اتباع ایلمشلردر. تقالید، اتباع وبر کشی‌دن ایشتکان یاخود برکتابده کورگان شیلرنی فوتوغراف قیلندن سویلاب طورمقلق همه‌سی انبیاء علیهم السلام صوکنده‌حادث بولمش بدعتلردر. مونه افندمز صلی الله علیه وسلم شول بدعتلرنی

مقتدابه طوطوب تعصب فی المذهب قوتلاندی. هر بر فریق اوز مذهبینه خلاف، دیگر فریق که دوشمانلق قیلا باشلادی، هیچ بر فریق دیگرینک دلیلینی بیلماز وحققغه وصولنی ایستماز بر حالگه دوشلدی، هر بر فرقه دیگرینی سوگوب، وحقارت قیلوب مجرد ایبداش کوبایتو ایسابینه کرلدی، نفسانیت کوبایدی، ازغوش طالاش زورایدی، هیچ برینک مقصدی حققغه وصول و باطلدن قوتولود گل بلکه مجرد خصمینه غالب اولمق وکشی آره سنده عالم اسمینی چغارمق ایدی، بس بو اختلاف ملت اسلامیه گه قایه رحمت بالعکس لعنت بولوب کیتدی. گویه الله تعالی نک «وما اختلف الّذین اوتوا الکتاب الّا من بعد ما جائهم العلم بغیا بینهم» دیگان سوزی بونلر حققنده نازل اولدی. الله تعالی هر بر اورنده عقلغه خطاب قیلدیغندن اسلامچه فکر، مستقل وتقلید ایله اسلام متضاداندی. اگر ایش شول حالنچه وارسه عقللر قوتلانور، حق باطلدن آیریلور وتقلیددن هم قاچیلور ایدی؛ لکن مع التأسف ایش اول حالنچه وارمدی. قرآن کریم: اهل کتابی کتابلرینی اوزگارتدیلر، قویدیلر وروٴسای دین اسمنده گی کشیلرینک سوزلرینه صوقور تقلید قیلوب حرامنی حلال وحلالنی حرام ایلدیلر دیه طوروب بزمده صوکغی روٴسای دین اسمنده اولان کشیلرمز، اوز شیخلرینک سوزلرینه صوقور تقلید ایلدیلر. بونلرنک اقوال ائمه گه تقلید واجب و آنلرنک فتوی لرینی نصوص شرعیه گه تقدیم تیوشلی، دیگان سوزلری ایله عمل قیلدیلر. حال بو که اوزلری دیگر طرفدن اقوال ائمه گه خلاف بولسه ده بوشیخلرنک سوزلرینه تقلید ایده لر وایته لرکه: «بونلر بزه نسبة کلام شارعنی و اقوال ائمه نی عالمرك، شونک ایچون بونلر سوزینک کلام شارع واقوال ائمه گه مخالف توسلی کورنوی بزم اوز فهممزنک نقصانندندر.» مونه شوشلای هر بر فرقه نک اتباعی فقط شیخلری تجویز قیلغان حکملرده گینه امامرینه تقلید ایلدیلر وبالاجماع باطل اولان مقلدکه تقلیدنی اختیار قیلدیلر والله تعالی «مَا يُرِيدُ اللَّهُ لِيَجْعَلَ عَلَيْكُمْ فِي الدِّينِ مِنْ حَرَجٍ - يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ»

بر ایشلادکلرینی حتی هلاك لك گه مفضی اولان حكملرینی بیله کور کام صاناب تقلید واتباع گه طروشمازلر ایدی. لکن بك بیوك تأسف که ایش اول درجه‌ده گینه قالمامش. بلکه مقلد لك بلاسی دهشتلی صورتده میدانه چیقمش؛ بناءً اسلامنی صارصیمش، شریعت مقدسه‌نی اساسندن چیغارمش و بو مقلدلرگ ظلم قامچی‌لری آستونده نوراسلام بتونلای انطفایه یاقنلاشمش‌در. صوگغی فقهانگ قرآنده یوق حیض نفاس حکملرینه متعلق یوزلرچه صحیفه یازدقلری حالده قرآنگ ایچی طولی احکام خلیقه‌ده نظر قیلمازسزلقلرینه سبب‌ده مونه اشبو تقلیددر. کاشکی بونلر احکام فقهیه گه صرف ایلدکلری زمانلرینگ اوندن برینی قرآن کریمگ بك کوب یرده امر ایلدیکی احکام خلیقه‌ده نظر خصوصینه صرف قیلسه‌لر ایدی، بلکه اهل اسلام بوقدر جهالت وسفالت که‌دوشمازلر ایدی. اگر بونلر عصر اول بحثلری کبی فقط حقلقغه وصولنی طلب قیلسه‌لر ایدی معین بو تضلیل تکفیرلر ونفرت لغتلر هیچ برسی بولماز ایدی. اللهنگ رحمتینی شیطانغینه قزغانادر. سزه اللهنگ جنتی طار بولوکبك تیه، مینی که اهل قبله‌دن اولان قرداشگزنی یالگز سزه یاخود ایسکی‌لردن بر کشی گه بر فکرده خلافلق قیلدیغی ایچون آنی تضلیل وتکفیر گه طوطونه‌سز؟ اصحاب کرام وائمهٔ عظامده اجتهادده اختلاف قیلشورلر ایدی، لکن هیچ بری‌دیگرینی تضلیل، تکفیر ایلماز و آنی دوشمان صاناماز ایدی. شونگ ایچون ابوحنیفه ایله شافعی آره‌سنده‌غی اختلافدن ابو حنیفه ایله ایکی شاکردی ابو یوسف ومحمد آره‌سنده‌غی اختلافنی کوبراك دیمشلردر.

مونه بونلرگ اختلافی حریت فکر وحریت کلام معناسنده اولغانلقدن امهٔ محمد (صلعم) گه رحمت ایدی. اما صگره بر زمان کیلدی الله‌تعالی‌نگ قرآن کریمده یهود ونصاری‌نی ذم‌مقامنده «اَتَّخَذُوا اَحْبَارَهُمْ وَرُهْبَانَهُمْ اَرْبَابًا مِنْ دُونِ اللّٰه» دیگان‌سوزینه رغما براهین شرعیه‌نی قویوب ایسکی کشیلرنگ سوزینه دلیلسز تقلید قیلنه باشلانوی، هر بر فرقه بر امامنی

بسم الله الرحمن الرحيم

## زمان اجتهاد منقرضمی دگلمی؟

عقول بشر کون بکون ترقی طاپقان وبو ترقی‌نک آثاری‌ده ایک جاهل وایک احمق آدملرنک بیله کوزلرینی قاماشدیرور درجه‌ده کورنوب طورغان بر زمانده بو سؤالنی صورمقلق و «قرآن‌نی فهم فقط ایسکی کشیلره مخصوصدر، آنلر منقرض بولدیلر، زمان، قیامته قدر بونداین آدملری یاکاادان طودرماز» دیمکلك نه قدر سفالت ایسه، آکا جواب ویرو قصدیله آلتوندن قیمتلی عمرنی ضایع قیلمق‌لقده حقیقتده شول قدر سفاهتدر. لکن ایش‌نک نه‌وقت حقیقت کوبونچه طورغانی وار؟ کاشکی اگر حقیقت دورلی خیاللر آره‌سینه کروب غایب بولماسه ایدی، علم اسمندن بو قدر وهملر یازلماز وبزده بو رساله‌نی قارالاماغه مجبوریت کورماز ایدك. اساسی عقل ایله فکردن عبارت اولان وهر بر حکمنده عقل ایله فکرگه خطاب ایدن اسلام‌نی اجتهاد حریتندن تقلید بویوندریغنه آطارلر وکتاب ایله سنت بتونلای جیمریلوب بونلر اورنینه فلان وفلاننک سوزی قائم بولور دیوب کیم‌نک خاطرینه کلور؟ کاشکی اگر ایش خاطره کلور درجه‌سنده گینه قالسه ایدی، اول وقت برده قایغرماز ومسلمانلر باشینه بو بلالرده کلماز وصبی‌لر آتالرینک حتی راقی ایچوگه قدر هر بر قباحتلرینی کورکام صانادقلری کبی بزمده صوکغی‌لریمز ایسکی‌لرنک، مقصد وغایه‌لرینی برده آکلامایونچه هر

عبدالله بوبی

# زمان اجتهاد منقرضمی دگلمی؟

ناشری:
ملّت کتبخانه‌سی

**Казань**
ЭЛЕКТРО – ТИПОГРАФІЯ
Миллятъ
1909.